

Роберт Әхмәтҗан



# Татар иртәсе

Шигырьләр

Казан
Татарстан китап нәшрияты
2004

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2Рос=Тат)-5
Ә 86

**Әхмәтҗан Роберт**

Ә 86 Татар иртәсе: Шигырьләр.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. —287б.

Күренекле шагыйрь, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Роберт Әхмәтҗанның яңа китабында милли шигърияткә, татар тарихына, аның милли үзаңы уянуга багышланган шигырьләре урын алды. Барыннан да бигрәк әлеге китапка кергән әсәрләрне авторның шигъри биографиясе, чорның поэтик сурәте буларак кабул итәргә кирәк.

ISBN 5-298-01409-7 © Татарстан китап нәшрияты, 2004

# *Автордан*

Китапны язуга караганда, аны төзү, әсәрләрне үз урынына кую, образлы итеп әйткәндә, «җеген җеккә» китерү, аның «эчке интерьерын» җиһазлау кыенрак икәнлеген яхшы беләм. Чөнки китап үзе дә җанлы, кешеле йорт шикелле, аның да үзенә күрә «түре», «тәрәзәләре» була. Уйланып төзелгән китап әйбәт җиһазландырылган, пөхтә җыештырылган йорт шикелле үзенә дәшеп тора!

Укучы хозурына тапшырган ошбу китабымны мин «Татар иртәсе» дип исемләдем. Нигә шулай икәнлеген аңлар өчен андагы шул исемдәге шигырьне уку да җитәр кебек. Соңгы берничә дистә ел эчендә иҗтимагый-сәяси тормышыбызда үзенә бер рухи яңарыш, милли хисләргә, тарихи тамырларыбызны барлауга йөз тоту ныграк сизелә. Чыннан да, бүгенге көннәребезнең, бигрәк тә татар иҗтимагый тормышының күпмедер дәрәҗәдә Тукайлы Бишенче еллар чоры белән уртак яклары барлыгына гаҗәпләнерсең дә! (Шул ук милли үзаң күтәрелеше, Думадагы маңкортлык хәлләре, халыкның катлауланыуы, беренче татар байлары, төрки кыйбла һ.б., һ.б.!)

Әлеге китапны образлы чагыштырып, «бер йорт» дип атасак, әлеге йортта ике «бүлмә» (бүлек) булыр. «Татар иртәсе» дип тулаем китапка исем биргән төп бүлек, әйткәнемчә, милли шигъриятькә, татар тарихына, аның милли үзаңы уянуга багышлана. Анда, асылда, хөрлек-азатлык, мөстәкыйльлек темасын күтәргән шигырьләр тупланды. Бер бүлегендә исә төрле елларда язылган шигырьләр урын алды. Әлеге әсәрләр укучыга үзләренең язылышлары, форма төрлелекләре белән дә кызыклы булыр дип уйлыйм. Һәр бүлек — шагыйрьнең остаханәсе бит ул. Шигырьләр бер шагыйрьнең гомер елъязмасы гына түгел, ә бәлки ул яшәгән чорның, мохитнең тарихи елъязмасы да бит. Биредә укучы яңа формалар, аһәңнәр төрлелеге белән бергә шул чорның ритмнарын, рухын тояр дип ышанам. Әсәрләргә нигез итеп алынган вакыйгалар минем буынның — Сугыш елы балалары буынының шигъри биографиясен тәшкил итә.

Барыннан да бигрәк әлеге китапка кергән әсәрләрне авторның шигъри биографиясе, чорның поэтик сурәте буларак кабул итәргә кирәк. Шул чагында бөек Тукаебызның: «Без тарихта эзлебез!» — дигән мәгърур расламасы яңа куәткә ия булыр.



*26 июль, 2003*

## «Татар иртәсе»нә кереш

...Белсен каумем үз тамырын,
Белсен дәрәҗәсен! —
Шуңа таңнан кагам бүген
Татар тәрәзәсен!..

Коелып төшмәс, сыналган ул,
Ничә гасыр кагам, —
Тукай әйтмешли, әллә ул
Мәңгегә... йоклаган?..

Коелып төшмәс, төшсен әйдә, —
Йокламасын, түзәр.
Заман шундый: йокыда да
Ачык булсын күзләр!

«Күзләрем күрмәсен!» — дип, күзен
Йома бәхетсезләр...
Ишекләрен дөбердәтәм:
«Уян, бар әйтәсе сүзләр!..»

Барыбыз да йоклап китсәк,
Таңнар безсез атар...
Урысчалап укымасын
Намазын да татар!..

Имеш, безнең түбә — ябык, —
Татар башы такыр...
Тор, Миңлебай, киңәшергә
Вөҗданыңны чакыр!..

*Февраль, 2004*

# *ТАТАР ИРТӘСЕ*



## Ак өметләр ява...

Җир тынып калган шикелле,
түремдә — ак таң гына...
Яңа ел!
Язарлык сиңа
шигырьне актан гына!

Ел саен бер шигырь көткән
син генәдер бу җирдә:
ел да — кияү, ки яңасын,
гел яңа син — гомергә!

Бүген тагын актан гына
дөньяның иңе-җиңе!
Каян коела? Әллә җирнең
йолдызга башы тиде?

Әллә күккә орынып үтте
бихисап күп торналар?..
Җиремне урап-чорнаган
ап-ак меридианнар!..

Алар галәм шары — җирне
күтәргән җепләр кебек.
Җир дә, Яңа ел шарыдай,
галәмдә җем-җем килә!

Ул бит йолдызлар катында
уенчык чаклы гына!
Бирергә тиеш без аны
яңага ватмый гына...

Шунда... бер йомарлам карны
алмадай аттым төреп,
яңа елга барып төште,
үткән ел аша кереп!

Яңа сүзем барып төште
туар ел итәгенә!..
Иске ел китми, яңасы
өлгереп җитә генә...

Иске ел — күзәнәк,
бер бөҗра — тирәкләрдә,
сабакларда — бер буын ул,
бер җөй ул — йөрәкләрдә.

Бусага да күрмим, елым,
юк синең бусагалар:
ак өметләр ил түренә
агалар да агалар!..

*1973*

## Фараз

Яңа елның яңа таңы
кесә ямаудан башланды.
Яңа ел хәерле булыр —
җил дә таңда юашланды!

## Корсак

Яңа елга иң беренче
килеп керде Корсак.
Без дә алдан булыр идек,
бераз алда булсак.

Корсактан да иң элгәре
килеп керде Борын.
Борын алдан булмас иде —
югарыдан урын!

Борын сизә (кешедән алда!),
Борын — сәясәтче.
Барысын да йота Корсак,
Корсак — хыянәтче!

Йотты иске бюджетларны,
яңасын да йотты...
Корсак — алда!

Төште Борын:
барысын
Корсак упты!..

*1999*

* * *

Ошбу елда
Кояш тотыла икән,
кемнәр тотыла икән, кемнәр котыла.
Мәскәү, Казаннарда — казинолар,
кемнәр ота анда, кемнәр — йота...

Байлар калка, ярлы халык — бата,
баткан халык саламга тотына.
Салым арта, бурыч арттан тарта,
Үзәк калка —
«регионнар»га тотына!..

* * *

Гаҗәпләнмим бер дә ошбу
Яңа ел килүенә;
гаҗәпләнмим үткәненнән
яңасы көлүенә;
гаҗәпләнмим инсаннарның
әйбәт ел көтүенә.
Гаҗәпләнәм
хайваннарның,
чыбыркылап,
адәмнәр көтүенә!

*1999*

## *Кыш ява...*

Кар ява тышта,
    кар ява —
кыш ява,
    оеп-оеп!..
Үзенә дигән вакытның
шулкадәр тәмен тоеп!..

Ходай Тәгалә яныннан —
күкләрдән килә ясак...
Куйды кыш
    һәрбер чүплекне
укалы-чуклы ясап!..

Күмелде канау, карьерлар, —
кыш буе каерасы!
Күмелде шул карьерларга
кемнәрнең карьерасы!..
Инде хәзер, калган эшкә
үч итеп,
    кар ерасы!..
Барыр юлыңа тау өя, —
куанма, димен, дурак.
Минем калган эшләргә дә
кар ява
    бурап-бурап!..
Вакыты җитеп китәрме,
соңгы болытын савып,
вакытсыз эреп бетәрме,
болганчык суга калып,
ашыгып,
оятка калып?..
Ә бүген... күккә хуҗа
ул, —

бәхетле бүген —
явып!

Картларның мазасы шулдыр:
«Тиз көннән язлар җитәр...
Насыйп булса, быел да, дим,
кыш миннән
алдан китәр.
Гомерем җебен тагын да
бер язга ялгап үтәр.
Быел да, димен, ярабби,
кыш... миннән
алдан китәр!..»

*2003*

* * *

Иртәнге кар якты булып ятты,
яктырып ла китте сүрән көн!
Бу иртәдә ак, тын Мәңгелекнең
күрдем гүя бөек сурәтен!..

Йа Илаһым, чагылгандай булды
Чиксезлекнең серле чатлары!
Якынайган Ай өсләре! Гүя
Агыйнешнең аргы яклары!..

Хәтер экранында кабынып китте
ерак калган яздан бер рәсем:
мәгарәдә пыскып янган шәмдәй,
онытыла язган... сурәтең!..

*2003*

* * *

Алмагачтан яңа өзгән
багалмадай шигырьләр,
кемгә ләззәт китерерләр,
әллә шиңеп кибәрләр?!

Кемнең күңел шәмдәленең
шәмнәрен кабызырлар?
Кем йөрәгенә шифалы
бәлзәмне тамызырлар?..

Аның шул... бер тамчысына...
түлисе гомер белән!
Дөнья малларына тиңсез
талантлы Шигырь генә!..

Байларның буе җитмәслек
Илаһи Шигыреңә,
ышанмыйм, бер җәүһәрнең дә
тәңгәлгә килеренә!..

Картаеп, ерак киткәч тә,
күз алдыңа килерләр:
үрелеп тә буй җитмәгән,
бездән киткән шигырьләр!..

*2003*

* * *

Ялгыз калып: «Рәхмәт, Раббым,— дидем,—
яшәвемә шушы көнгәчә!..»
Янәшәмдә кемдер: «Рәхмәт! — диде,—
Рәхмәт, рәхмәт! Тагын мең яшә!..»

Кайдан килә тавыш? Кайтавазмы?
Кемдер керде, ахры, ишектән?
«Рәхмәт!» диеп, кем ул кабатлады,
әлләме, дим, ялгыш ишетәм?..

Ние гаҗәп?
Бар бит адәмнәрнең,
игелек игеп, рәхмәт урганы...
Бер рәхмәттән туып, баш очымда
шаулап куйды рәхмәт урманы!..

Юк, ышанмыйм юк-бар юрауларга —
могҗизага шуны иш иттем:
«Рәхмәт!» диеп, урман шаулаганын
ишеттем шул, өндә ишеттем!..
Үземне мин күктә хис иттем...

*2003*

* * *

Дөньясы аның — салкын мич,
якмаган. Җылынмадым.
Мин китмим. Килдем генә бит,
кайтырга җыенмадым...

Үзәннәр буйлап тезелеп,
тирәкләр тора чират, —
тармак-кулларын сузганнар,
әйтерсең Айны сорап!

...Искәртте Айлы сукмакта
бер чиләк чылтыравы.
Әйтерсең «Кайт!» дип чылтырый
яшьлекнең кыңгыравы...

Мин ерак Гомер тавында,
соң инде кайту, мотлак.
Ак Бәрән йолдызлыгында,
шигырьдә йөрим «утлап»...

Мин инде чиксез киңлектә
яшимен, Алла колы...
Юлыма чыгып көтәдер
мине дә «кошлар юлы»...

*2003*

* * *

Кайдан кунган —
юк җилдән дә өрелеп кенә
мамык тора иң өстемдә?
Дөнья тынган...
Тычкан уты — өмет кенә
сүнәр-сүнмәс янып тора
Ил өстендә!..

* * *

Урыс яулап алган җирләр,
урыс яулап алган күкләр...
Искән җилдән хәл сорашып,
гаҗәпләнә әле күпләр,
икеләнә әле күпләр...
Үз телендә... ыңгырашып.

* * *

Шәмемне еккан җилләрнең
артыннан калам дәшеп:
Тикшерербез! Дөньялыкта
бөтен җилләр очрашып!..

*2003*

* * *

Кара көздә күкрәп коя,
        юкса
җәйләр безгә кире кайтамы?
Кайтсын иде июнь күкрәүләре,
юкә шаулап чәчәк атканы…

Бар табигать салкын душ астында,
Ниләр уйлый икән игенче?
Болыт явы әллә безнең якны
Атлантида ясап китмәкче?..

И ургылып, урдаланып килә,
актарылып, тонып, әйләнеп…
Әллә шунда гигант шул бүрәнкә
суырып алган бөтен җәйләрен?..

Балачагым. Җирнең бер бозавын
бастырыктай елан чорнаган…
Аждаһаны суырып алган болыт
Башбай дигән тирән елгадан!..

Инде, болыт, бер дә юкка гына
диңгез иттең елга-суларны…
Аждаһалар җирдә үрчи ләса,
суырып алчы, зинһар, шуларны!..

*2000*

* * *

О вы дубы Камские!

*Г.Р.Державин*

Минем дә шул шигырь язганым бар,
бераз тирләп имән кискәнем...
Шигыренә керткән чал Державин
имәннәрен Имән Кискәнең!

Сөзәк ярда леп-леп килә Чулман,
шигырь сөйли бугай Чулман да?..
Туган якта ачы баллар күперә,
какланадыр казлар чоланда!..

Мин сезнеке! Торсын Державиның,
ул морзага бездә кем тигән?!
Үзе әйткәч, «татар» дисәң, ярый, —
онытмыйбыз: кемне кем дигән...

Бу якларда түбә саламнарын
тузгытканда комлы давыллар,
Патшабикәләргә дастан язып,
Ул яшәгән Патша Авылында!..

Державаның Державины булу
үзе тота алтын утарда!
Бөек шагыйрь аннан гомер буена
«Бакыр бабай» булган татарга...

Бу якларда бөек хатирәләр
тора балкып кояш утыннан.
Шаулый җилдә татар имәннәре,
җырлап туймый
Шагыйрь тупыллар!..

*2000*

* * *

Көз һавасы шундый җиңел, биек!
Бал кортлары оча чүнниккә.
Күз алдында очты алтын богыл
Рәшәләнгән зәңгәр киңлеккә!..

Өнемме соң болар, туган җирдә, —
Барысы да безгә дигәнме?
Илһамланып көзге утлар яна,
Көз ялкыны ялый имәнне.

Сихерләде тоташ! Җирдән ашты,
Көз адашты китеп яланга...
Чиксезлектә очам сихерләнеп,
Авазларым калды, мине эзләп,
Авазларым йөри аланда...

*2000*

## Юату

Ул көннәр-төтеннәр үтсеннәр-китсеннәр, —
көткәнгә җитсеннәр — үкенмә!
Бүген дә үкенмә, мең рәхмәт бу көнгә, —
үкенгән итенмә төтенгә!..

Ул ярлар читендә, шул таулар битендә
көтүләр бигрәкләр читен лә!
Бүгенгә, бу көндә беркемнән үтенмә,
теркәлеп тернәксез төркемгә!

Йөримен иркендә, дөньяның читендә, —
ялынмыйм беркемгә бу көндә:
Үзенең иркендә кирәктер һәркемгә
яшәве бүген дә, һәр көн дә!..

*2003*

## *Тор, күтәрел, Шигырем!*

Кулга каләм алмас та идем лә, —
Нигә тиккә күзем талдырыйм? —
Заманыма бар бер үпкә сүзем,
Ничек аны әйтми калдырыйм?

Ак кәгазьдә көйрәделәр сүзләр,
Бар сүземнән бусы — иң кайнар.
Бу үпкәне бездән шәбрәк итеп
Әйтер иде мәшһүр Тукайлар.

Әйтер иде, бәгырьләрен көйдереп,
Кимсетелгән шәхес хакында;
Сорыкорттай җанга үрмәләгән
Данга туймас нәфес хакында;

Әйтер иде изге минутларны
Артка тарткан сәгать турында;
Үз халкының үги баласыдай
Тибәрелгән сәнгать турында!

Син үзең дә моңа гаеплесең,
Булган, халкым, шундый хаталар:
«Атказанган» аты белән генә
Китеп барган
Зифа апалар...
Бакчы, бүген бар да «халык»ныкы.
Эстрада кайный,
Мыж килә!

Күпсенмәгез, яшьли тиешле ул —
Күпләренә, хәер,
Буш килә.
«Академик» кавем үрчегәндә

(Күпләр инкубатор затыннан!),
Тау-тау энҗе өеп,
Нәкый агай
Китеп барды
Ишек катыннан...

«Академик» исеме бөек, әмма
Һәркем үзен күрә бит инде!
Ә Исәнбәт аңа «үсалмады»,
Бу да үзенә күрә бит инде!..

Шигъриятем бүген мәэюс кыздай,
Сукбай кебек
Юллар чатында...
Ник торасың, Шагыйрь, бусагада,
Ник торасың
Ишек катында?!

Тор, күтәрел, Шигырем, саф башына,
Таян безгә,
Таян халкыңа.
Тор, күтәрел, якла үз-үзеңне
Яктылык вә игелек хакына!

Тор, күтәрел, Шигырем,
Шундый чор бу —
Изгеләрне изгән вәхшилек...
Бер тиенгә уптым сата сине
Базар фәхишләре,
Мәш килеп!

Тәхет өчен илдә ызгыш бара,
Хак сүзләрдән бүген ялган күп.
Неврастеникларга көн юк бүген,
Тиреҥ булсын калын —
Калкан күк!

Тор, күтәрел, Шигырем,
Җәй канатың,
Җан канатып булсын —
Алга бар!
Өмет белән баккан Киләчәккә
Кол Галиләр рухын ялга, бар!

Бирешмә Син җыен алыпсатар,
Җанын сатар татар явына, —
Йөрәгеңне кабыз чыраг итеп,
Күтәрел син
Олимп тавына!

Син, Шигърият, нинди горур идең,
Базарга Син «йомшак» кермәдең.
Хәйрияләр ишек төпләрендә
Ипи-чәйлек сорап йөрмәдең...
Нәшриятлар диварында һәрчак
Балкый иде Синең үрнәгең!

Яу кырында һәрчак алда булдың,
Үлем көткән чакта,
Җәлилчеләр Сине җырлады!..
Зинданнарга Кояш булып кердең,
Байрак булды Шагыйрь җырлары!

Поэзия, син ваемсыз бүген,
Син дистоник бүген, астматик!
И Шигърият,
Исемең һаман шул да,
Җисемең генә бүген башка тик.

Вак җаннардан өркеп, Син, Шигырем,
Безне ташлап китмәк шикелле?..
Китмә, Иҗат, зинһар, бу тормышта

Син бит безгә
Икмәк шикелле!
Өметсезгә — өмет, күңелләргә
Ачылмаган хикмәт шикелле!
Хыял пыяладай ватылмый да,
Көпә-көндез
Йолдыз
Атылмый...

Базарлардан кача чын Шигърият,
Толчокларда намус сатылмый!
Мөтәшагыйрь шигырь сырлаганда
Халтуралап,
Онытып оятын да,
Ник торасың, Иҗат, бусагада,
Урыныңмы ишек катында?

Күтәр безне рухи инкыйлабка,
Гүзәллек һәм Хаклык хакына!

*1999*

## *Хәтерләр аша...*

...Кайларда калдың син, Яшьлек,
Кай тугайлар куенында?
Сурәтең тора елмаеп,
Үткән гасыр фонында!

Гаугалы яңа гасырда
Елларым үрне менә...
Сурәтең, томаннар кичеп,
Бүгенгә керде менә...

Син дә чакырма, әнкәем,
Кире кайт, балам, димә.
Бер чыккач, аны юллардан
Аерып алам, димә!..

Давыллар каршына киттем, —
Белмәдем кадерләрең...
Сүзләрең юл тузанына
Күмелмәс, бәгырьләрем!..

...Абына-түнә бара йөрәк,
Үткәнен җан юксына...
Барасың — хәтерләр аша, —
Кайда ул...
          йокы сиңа?!

Офык артында — офыклар,
Әрнүле юллар гына...
Каршыңа җилләр исә дә,
Күк тулы...
          моңнар гына!..

Уба еллар,
          өерә давыл, —
Тапмассың каберләрен...
Ул көннәр...
          егылып елыйдыр
Юлларда, бәгырьләрем?!

*28 февраль, 2004*

# *Иске самавырга*

## 1

Гомер иткән, агы беткән,
чыккан инде сарысы.
Самавырны пенсиягә
озаталар, ахрысы…
Яшел чирәм, күрше-күлән —
җыелганнар барысы…

Җырлады иске самавыр,
шаулатып ишегалдын.
Ә хуҗалар үзләре дә
җырлар хәлгә җиткән иде,
кушылып иске самавырга.
Моңнарын отып алдым:
«Самавыр чәе бик тәмле,
эчендә пары булса.
Мин дә «уф» дип әйтмәс идем,
янымда ярым булса!..
Ишегалдым яшел чирәм,
кодам, чәй ясап бирәм…»
Ничек җырлый кодагый да,
сәбәп бардыр җырларга, —
карынына ут төшмәсә,
җырламый самавыр да…

…Хәтердән чыкмый шул җәйнең
гөрләшеп эчкән чәе…
Балачак. Иске самавыр…
Ничекләр кайтарыйм сине,
гомернең ерак җәе?
Их, самавырның кайнавы, —
еллар артында —
шавы!..

## 2

...Җырлый ла иске самавыр:
килә яңа заманнар,
юыналар, яманалар,
юргалый атсыз арбалар.

Кеше инде менде Айга,
мин шулай да
самавыр булып калам:
утлар алам утлыгыма,
кайнап чыгам,
            бөркеп парым,
күршеләрнең бүлешәм зарын.

Кайнар каным, утлы җаным —
кешеләргә бирәм барын!
Төннәремдә төшләремдә
ут тоямын эчләремдә!

Утлыгыма төшә күмерем...
Кайнап үтәдер гомерем...
— Нихәл, дустым, самавыр?..
— Электрлы яшьләр килде,—
күмерем бетә, хәл авыр...

## *Карлы мизгел*

*Клара Булатовага*

…Паркта кыш,
оеп-оеп,
рәхәтләнеп ява!..
Клара,
бүтән шундый,
Ай үзәне сыман
карлы елгаларны күрмәдем,
тезләремә тикле ак бәхеттә
бата-чума атлап
йөрмәдем!..
Синең белән икәү
утырабыз,
аякларны салындырып
ак елгага,
күпереп торган мамык карга…
Акырын-акырын
күмә безне,
йота безне
күк түреннән килгән яулар.
Парк утларының яктысында
җем-җем итә ярлар,
ничек бии карлар!..
Шунда калды
яңа сауган сөт шикелле
күпереп яуган
ап-ак карлар!..
Әллә карга,
әллә карлы ярга,
әлләме ерак елларга
күмелә бара…
карлы кичле
Клараралар!..

*2000*

## *Көзге-кичке кояш*

*Мансур ага Мозаффаров ядкяре*

Кичке Идел өсләренә сибелә
болыт артларыннан
нур көлтәсе...
Иделен, болытларын, офыкларын
килә тоташ
бер җыр итәсе!
(Шундый якты нурлар төшә иде
балачагым киноэкранына!)
Кеше, туктап, бер яктыра җирдә
гомер кояшы баер алдыннан.
Бер тукталып
яктыра ул — шундый! —
фанатик ул —
хәтта җыр яза!..
«Яз!» дип, тупыл кышын
яфрак ярса,
көзен кайтса, «Яз!» дип,
кыр казы, —
чагыштыру мөмкин шуның белән, —
миндә, ди ул,
яшьлек уртасы!
Ә бит юкса, аяк очына тиеп,
уелып ага
Әҗәл елгасы...
Язды ул җыр Идел өсләрендә,
калды моңы янып күңелдә;
шәфәкъ булып балкый кичләремдә,
Кояш җыры —
талгын Иделдә!..
Калды ул җыр...

Йөри чиктән чиккә,
офыклардан күчә офыкка!..
Идел өсләрендә,
          тынга калып,
аны сагына
кичке болытлар!..

*1979*

## *Сәйдәшкә*

...Флигельдән чыга. Тора карап
нур туфаны тулы дөньяга...
Зәңгәр күзләр бага зәңгәр күккә:
ак болытлар булып
          моң ага...
И киң дә соң!
          Күзгә күренми дә
моңнар диңгезенең ярлары!..
Шул диңгездә язмыш дулкыннары
актарыла...
Гарасаты каплый җаннарны!
Әдрән моңы! Гүя симфоник көз!
Алтынланган каен чуклары...
Өнме соң бу — кочак җәеп килә
татарның бар наемщиклары!..
Бәхет түгелме бу? Мажор аккорд!
Җирне юып чапкан ташкыннар...
Хөрлек җырын күккә күтәрә бит
кара урманнарда качкыннар!
Җыелып әнә сөрген төпләреннән
җирнең барлык каторжаннары
килә сиңа, Сәйдәш,
          котлый сине
Гөлйөземнәр, Батырҗаннарың!..

Бу — син, Сәйдәш,
синең кайтып килеш
йөз яшеңә җиткән көннәргә.
Безгә кызык:
иң беренче булып
кул бирерсең икән кемнәргә?
Килче, бәгырь,
Йөрәк мәйданында
тиңең дә юк,
            юктыр көндәшең.
Һәйкәлең дип тарткалашкан ара
килеп җиткән,
узып киткән әллә
            йөз яшең?!
Тарткалаша татар, өзә алмый
үтерә ул хәтта... яратып...
Ярата ул, син дип үлә!.. Әмма
бердәмлеге җитми
            һәрвакыт...
Серем сөйләп, сүз кушасым килсә
якындагы якын кардәшкә,
ут алырга өмет чырагыма
мин Сәйдәшкә киләм,
Сәй-дәш-кә!..
Аңа булган Халык Мәхәббәте
сыярмыни шигъри тәлгәшкә?
Татарымда миллион йөрәк булса,
һәркайсында —
            һәйкәл
                        Сәйдәшкә!..

*2001*

## Гасырларда яшәр Юксыну

*Әмирхан Еники ядкяре*

Бүген иртүк, нәзкәй генә үксеп,
«Ени…и…ки!..» дип исте таң җиле…
Җылы яңгыр кебек салмак иде,
И Әмирхан…
 изге җан инде!..

Китүеңмени?
Үткән чорның соңгы могиканы,
Йә, бәхил бул, әдип,
Хуш инде!..
Мең кодрәтле бөек Табигатьнең
Соңгы мөмкинлеге
Шушы инде!..

Соңгы мәҗелес… Матәм җыенында
Бер догалый җаннар иң башта.
Гомереңне дәвамларбыз, Остаз,
Һәрбер җанга
 әле күп-күп еллар
Җылы килер
 Синең Кояштан!

«Кояш баер алдыннан» дип язып,
Ябып куйдың «Соңгы китап»ны…
Шул китапның җаны — хаклык сүзе
Һәр йөрәккә
 якын юл тапты!

Шытып чыгып күңел нурларыңнан,
Яшь бөреләр ачар керфеген:
Мулдан иктең Иҗат кырларыңа

Игелекнең алмаз бөртеген!..
Шулай укмы, югалттыкмы инде
Ил-илкәйнең соңгы морзасын?!
Дүрт кул булса,
            дүрт шәм тотып эзлә
Гасырга бер туар ир затын!

Битен ачсаң, меңгә тапкырланыр
«Соңгы китап», —
            аның юк соңы...
Җәсәд китә —
            кала олуг Мирас,
Гасырларда яшәр
            Юксыну...

*18 февраль, 2000*

## Самих Батталның китүе

Тормыш шау-шуыннан арып-талып,
Баш куюга йомшак ястыкка,
Гүли башлый иде
Яшьлегендә үзе очкан самолеты,
Алып китә иде төштә
            Тын океанга,
                        Владивостокка!..

Ымсыныла... Күпме еллар инде
Ул якларга юллар ябык та...
Тын океандай чиксез хыяллары
Китапларына да сыялмады...
Сыеп бетте беркөн...
            табутка...

Уйлангандыр шагыйрь милләтен дә
Гел канатлы итү хакында...
«Батый ханга нигә хат яздың?» — дип
Кыздырдылар үзен
обкомда!..

Сугыш янгыннарын очып үтте.
Алып китте күләгәдәй картны,
Башына җитте! —
Нәзек кенә
электропровод та!..
Шулай диеп сөйләделәр соңрак —
Юкка! —
Аның йөрәге тоташ иде
Иң югары токка:
Исән чакта
Дан-хөрмәтләр үтте читләп...
Йөрәгенең
магистраль тамыры
янды гөлтләп! —
Китте нәүмиз
Ишек төбеннән,
Дөньясында
гаделлек юкка...
Дәрвиш сурәтле
олуг шагыйрь,
Ятим бер кортка...

*1999*

# Китте ул Ак Болыт шикелле

*М.Хәсәнов ядкяре*

...Сөрсегән буага сыймады,
чорында сыймады
күп вакыт...
Зур Балык иде ул!
Китте ул,
тирәнлек дөньясын болгатып!

Зур Кеше иде ул — Алыптай,
сыймады бернинди калыпка...
Зур балык иде шул, кит иде, —
үзе дә табынды
балыкка!..
Борчакны күп сипте ул Ыкка!..
Кармагын куакка саплаган...
Яшәп тә карады, җилфердәп
җил купты
ул килгән яклардан!..

Җиленнән
тын торган тупыллар
шаулашып калдылар,
ул үтсә!..
Сагына хатын-кыз: кайнар шул, —
бер елга җитәрлек,
бер үпсә!..
Ул көлсә, яктыра тирәлек,
бөгелгән — күз ача, тураеп.
Килгәнен
ишекләр ишетә —
калалар ишекләр
зураеп!

Ачыла күңелләр киңәеп,
кайгылар китәләр таралып...
Тәгәри тыгыз сүз, ядрәдәй,
амбардай күкрәктә
яралып!..
Яшәде яшеннәр яшьнәтеп,
күкләрдәй күкрәде авазы...
Дөньяда бер данә иде ул! —
Алмашка
туармы яңасы?!
Алыпны салмагыз калыпка, —
кәрләләр,
Алыпның колы сез...
Ул китте
Ак Болыт шикелле,
күкләрдә калдырып якты эз.
Китте Ул, үзенә алмашка
дөньяда яндырып
Олы Сүз!..

*2001*

## Мөслим шагыйрьләре

*Зөлфәт илә Наиска*

Кем соң анда? —
радиоданмы,
әллә болыннанмы
тугайлатып сыза
тальянны?
Җилкендереп якты өметләргә
һәр бөҗәген җирнең,
һәр җанны,
агыла моңнар!

җәйге тымызык таңнар
Ык буйларын иңләп
　　　　йөзгән күк,
и кистерә, и өздерә җанны,
йөрәгеңне
　　　　тартып
　　　　өзгән күк!..
Сандугачлар оча, моңнар коча,
әрәмәдә очар сүзләр күп!..
Җыелганнар
　　　　Мөслим шагыйрьләре, —
Ык буеннан килә җырлашып...
Алар киткәч, шунда атна буе
сандугачлар йөрде
　　　　җыр ташып!..
Чишмәләре — күккә агып ята,
болытлары —
　　　　җиргә түшәлгән...
Табигатьнең җаны
　　　　бу якларда
моң басымы белән
　　　　үлчәнгән!
Җыр басымы каен басмаларны
сыгылдырып уза аръякка —
җыр җанлылар
　　　　моңны басма иткән,
киләчәккә илткән
　　　　тарафка!

*Июнь, 2003*

## Җанның сабан туе

*Мәшһүр музыкант Рифгать Гомәр истәлегенә*

Сабантуйлары да ерак әле,
Бүген бездә бәйрәм, диергә…
Рифгать Гомәр кулына баян алган,
Шуңа чыккан яшьләр биергә!
Рифгатьнең бер бию көе җитә
Бар татарын әйләндерергә!..
Тулгандыра,
Тулгак тоткан сыман,
Кичке болыннарда
дәртле моң!..
Ай яктысы акты үзәннәрдән,
Моң
Сөюгә җанны чакырды!
Әйтерсең лә канатланды йөрәк,
Син дә, җаным, шунда тартылдың!
Бер сылуның күңеле тулып бугай
Түгәрәктән читкә атылды…
Булыр икән җанның сабан туе!..
Син төннәрен
моңнан яктырдың!..

*2000*

## Былбылга мәрсия

*Вафирә Гыйззәтуллина ядкяре*

Син һаман тересең, карыйсың мөлдерәп,
сүтелә торганда җиһанда Ил-терәк…
Син — йолдыз, җанкаем, юатып безләрне,
иң соңгы куышыңнан балкыйсың җетерәк!..

Тикмәгә түгелдер, тикмәгә бу күңел —
чайкалып убылды без баскан Җир, тетрәп;
и садә моңнарың сыйдырган саф күкрәк
аһларын чыгарды соңгы кат, җан күкрәп!..

...Бу җанлы рәсемең, бу соңгы сурәтең:
карыйсың мөлдерәп, хет сөйләш-сөйләшмә.
Моңдашын яд итеп, анда да, ичмасам,
бер былбыл йөриме янында киңәшкә?..

*2003*

* * *

*Фәннур ядкяре*

Киткәнеңә инде ничә еллар.
Балконыңа карап
Үтеп китәм, әмма буш шул
Күңел дигән тараф!..

Нәрсә сорыйм, сине көн-төн көтеп
Эче пошкан җилдән?..
Карлы бусагаңда кош эзләре,
Кошлар гына килгән...

Ап-ак бәскә урап, салкын кышның
Ап-ак сулышы тора...
Ничә күрмим, тәрәзәңә карап,
Тик бер кош утыра.

Эзләреңне күмеп,
Кыш котыра!..

*2000*



## *Чорым — иркен!*

Иркем — иркен,
күңелләр киң, бигайбә,
теләгәнчә очын, җилкен —
беркем чикли алмас иркең!

Мондый чор ул
тарихларда кабатланмас һәр көн!
Сүз ирке бар,
шәхес ирке!

Килешмәсәң ни беләндер,
мәйданга чык —
игълан ит ачлык!
Бар галәм алдында ачык!

Хәер, ачлык игълан итмәсәң дә,
бу хәл ачык:
ачыкканнар тора авызын ачып!
Оештыр төрле фиркаләр
(шаккатсыннар Америкалар)!

И гаугалы чор!
Бар дөньясын үзгәртеп кор,
Сессиядән съездларга атыл!
Микрофонны болгап,
                    төй өстәлне!
(Куе фикер, сыек гакыл.)
Хөрриятккә юлыктык бит, афәрин!
Ыштаның юк,
Ә Иркең — бар!

Йә чукын син, укын-төртен,
Йә чалма чал, йә тот тәре,

Йөр гипнозга.
(Кашпировскийлар — хисапсыз!)
Экран тулы хур кызлары, Ходаем,
Шәрә!
(Кемнән булыр бәхетләре?)
Чит илләрдән чакыр сексопатологны
(ул өйрәтер),
Моңа каршы килмәс беркем,
Элемтәләр — иркен!

Инде, иншалла,
Без мөселман бәндәләргә
Мәсҗетләр дә бардыр имди.
Әмма менә
Иман гына...
Иман гына үчте бездән,
Иман гына бетте беркөн!..

Яздым —
Көнем өчен түгел, денем өчен.
Рифма түгел, азык түгел,
Чор рәвеше — иркен!
... Күк читендә ут-шар
Эленеп тора,
НЛО бугай (ахыр заман!).
«Кайнар нокта»ларга
Газраилләр оча төркем-төркем!

*1991*

## *Шигъриятне яклап*

Үкенәм, мәлгунь, китап язып биреп,
күршем, диеп, сәрхуш ирләргә,
милләттәш, дип, ярымтатарларга,
ярымурысларга (чирләргә)!
Үз телен дә белмәс урыска да...
И үкенеч шагыйрь кешегә, —
рәхмәтләре ләгънәт булып кайткач,
ачыгавыз — минем ишегә!..

Алардан бит шигырь үзе кача,
икенчедән, ярым аңлап та,
ярым сәрхуш, тулы надан килеш,
оратордай,
хут бирәләр элек — бармакка!
Ә аннан соң, шигъри маньяк сыман,
тулы «кайф» баштан
елмаеп,
китаптагы синең сурәтеңә
төртәләр дә,
аннан, акаеп:
«Ай, прастуй, салмыш иде, — диләр, —
Күргән идем беркөн
экранда...
әллә кайда исемен атадылар, —
әллә җырда,
әллә... урманда,
гөмбәлеккә кереп барганда?
Ябалакмы, әллә саесканмы
элгән иде аның исемен
карамага, әллә... нараткамы,
исеменме, әллә... җисемен?..»
...Үкенәм, мәлгунь, шундый «укучы»ны
саташтырган өчен, чурт вәзми;
мондыйлар бит, Туфан әйткән сыман,

булган почти…
        маңкорт Шаһгали!..
Жәлме китап, ул бит — гөмбә түгел,
өстәлеңә хәмер куйгачтын,
табындагы закуска да түгел!..
Шул фикергә киләм аннан соң:
шигырь язу кемгә тоела җиңел,—
айныр, үзе…
        язып карасын!
Укыр диеп биргән идем юкса,
үкенеп лә бетмим һаман да —
        Гомер Китабымны
биргән ләса
гөмбәдән дә арзан наданга.
Иң зур үкенеч: шигъриятме калды
гөмбәдән дә арзан заманга?!

*2002*

## Илһамсыз чак

Йөрәк, шулмы синең карурманың,
Кергән юлым кайда калдырганмын,
Адаштырдың бугай ешлыкта?..
Яшәрәләр анда абагалар,
Куакларга кунган ябагалар
Бүреләрдән калган кышлыкка…

Йөрәк, кая ижат карурманың?
Хыялларым, сезне яндырганмын,
Эчем пошып болай эш юкка…
Ник бер шигырь кунсын каләмемә,
Кабул итеп кысыр сәлам генә,
Карап торам
        тып-тын
            бушлыкка…

*2002*

## Соңлап

...Әкрен-әкрен сәдәф чишүләре,
еш-еш сулап,
ак мендәргә сыгылып төшүләре,
көлеп-елап!
Үтәр бу да, калыр язылып
җанда-канда,
сүтелербез — кинотасма сымак!..
Аһ, җанкаем, калды синең оҗмах,
кайтыр идем, калдың инде ерак...
Эшләнгәнме гамәлләрем уйлап? —
Җилбәзәк җан
күбәләктәй
очты уйнап!
Ярып бардым кебек үзем гел дөрестән,
учмаларны җыйдым ашыгып, —
өстән-өстән...
Исәп-хисап чоры җиткән...
түлисе бар, —
күпме еллар яшәгәнем
чыкты өстән!..
Яшәлмичә үткән еллар бит, дөрестән...

*2003*

## Гомер юлы

Гомер тирәгемнең ябалдашын
Җитмеш еллар җиле шаулатты!
Аңлатты ул күкләр төпсезлеген,
Еллар чиксезлеген аңлатты.

Шунда белдем, тиңсез гомерләр дә
Чиксезлектә — төтен,
бер тузан,
Чәчрәп очкан йолдыз кыйпылчыгы,
Чәрдәкләнгән Айдай, фаразан!..
Кыйблаларын җуйган кәрванмыни —
Болытларым йөрде каңгырып.
Әле дә булса газиз башларыма
Пыскып тора салкын яңгыры...

Кешни анда җилләр, елый болыт,
Көлә Кояш, укшый гамьсезлек.
Мәнсезлекләр тулы игелекләр,
Изгелекләр катнаш мәнсезлек!..

Гомер тирәгемнең һәр яфрагы
Вакыт узуларга бик сизгер.
Мизгелләре кайчак — тулы гасыр,
Гасырлары — тулмас бер мизгел!..

Дөньягызга килеп бәхетле мин,
Йа Ходаем, килеп шаккаттым! —
Гасырларын сабыр кичтем кебек,
Мизгеленә —
бетте тәкатем!..

Дөньяларга килеп яшәүләрнең
Бер ядкяре әле ярады:
Болыннарда үскән яшьлегемне
Урлап очты
Энә карагы!..

Мизгел булса, гасыр — яшәр иде, —
Бер гасырга — мизгел сыймады...
Узып китте бер гасырлык мизгел,
Бер гасырлык! —
беркем тоймады!..

*2002*

* * *

Елганың борылган төшендә...

*С. Хәким*

Карадым борылып елларга
Борылган төшендә елганың...
Елга да, минем күк, борылып
Карыймы үтелгән юлларын?..

Елганың борылган төшендә
Кычкырып әйләнә тәкәрлек...
Аккан су, искән җил — мәңгелек,
Гомерләр — бер генә сәфәрлек!..

Елганың борылган төшендә
Карт тупыл сөйләшә җил белән.
Бу җиргә ябышып үскәнгә,
Аларның телләрен бик беләм!

Яшәгән еллары билгесе —
Карт тупыл тәнендә — мугыллар...
Елганың борылган төшендә
Уйланып торадыр ул еллар?..

Үзем дә шауладым гомеремдә,
Ил буйлап үткәндә күп юллар...
Үзем дә карт тупыл шикелле, —
Йөрәктә ишәя... мугыллар.

Ел саен ачыла тамырлар, —
Карт тупыл текә яр өстендә...
Минем дә
Яшәвем, эшем дә
Елганың борылган төшендә.
Яшим тик, туп-туры, үч итеп,
Үзем һәм бүтәннәр өчен дә.
Борылмыйм әле мин,
        төз яшим,
Елганың —
Язмышның борылган төшендә!..

*2002*

## *Урман аша*

Төн күзендә барам — урман ярып,
йолдыз яктысында — юл җиңел.
Чыгам-чыгам —
          урман чиксез сыман,
әлләме, дим,
          юлы ул түгел?!
Тәгәрмәч эзеннән, бата-чума,
и ашыгам, узган яңгырдан
тулган күлдәвекне төнге урман
йолдыз белән
          туглап калдырган.
Ә мин барам,
          йолдызларны ерып,
сизеп гүя якын хәвефне...
Куеныма керә урман җиле,
күтәрмәкче гүя кәефне...
Шул йолдызлы күлдәвекләр чәчри,
пошкыргандай поши артымда...

Йөгереп килеп, куак... йөзгә бәрә,
үксегәндәй кемдер якында...
Төнге җилдә шомлы яфраклары
сөйләшәләр нәрсә хакында?..
Куак ешлыгында ут-бөҗәкләр,
аһ-ух килеп елый ябалак...
Кемдер... мышный,
          якын борылышта
тора кебек кемдер сагалап...
Нигә шүрлим,— кемнәр сагаласын,
бай түгелмен,
          тишек кесәле.
Юлыма чыгып, мине
          бу урманның

сынап карау гүя исәбе?..
Урман авызыннанмы
          миңа каршы
җылы һава узды
          бер катлам...
Туа өмет: гомер буе барган
максатыма гүя
          бер атлам!..
Урман җиле,
          яфрак шавы аша
ишетелде арттан
          кем сүзе:
«Бик ашыкма,
          чапма,
                    чыгып җитмә, —
Урман түгел,
Гомер бу... Үзе!..»

*2003*

## *Сирень йолдызлангач...*

Йөзә Сирень — бөтен киңлекләрдә,
әрәмәне кошлар шаулата!..
Бакчаларда —
ал-шәмәхә төтен!..
Соң мизгелен, һәлакәтен көтеп
бәргәләнә
Сирень канаты!..

Сиреньлектә Сирень йолдызлангач,
төпләренә йолдыз сибелгән...
Сайравыннан тотлыктылар
кошлар,
исерделәр, ахры,
Сиреньнән?!

Сирень сиреньләнгән шушы айда
җан борчулы: Аем кителгән...
Әллә шуңа: кошлар исергәндә,
чор җилендә
артыгынмы айнып кителгән?..

Күңел шуңа сизгер: әче таңнан
сындыралар салкын Сиреньне!
Сындырырга яратылдыңмы Син,
таланырга туган идеңме?..

Ботарланды йолдыз куаклары,
канатымы сынды Сиреньнең?..
Сибелделәр өзелеп... мәрҗәннәре!..
Бу — погромга,
яуга тиң инде! —
Мең мародер, нәфес киң иде!..

...Җәй юлында офык күтәрелгәч,
дулкынланды Сирень, иң башлап...
карар кылып, чибәр диссиденты,
Үги кызы җирнең булмаска
талпынды да...
　　　　　　канатланды Сирень,
канатланып талпынды да беркөн,
очып
　　　китте...
　　　　　　Сирень
　　　　　　　　　кыйгачлап!..

Очып китте...
Кемнең исе китте?
Калалмадым, сеңелем, йолып та...
Сәламедәй гүя
　　　　　　сызылып калды...
Сирень төтеннәре...
　　　　　　офыкта!..
Шәмәхәсе төшкән болытка...

*2003*

## Төнге яңгыр

...Өй түрендә шаулый төнге яңгыр,
тоташ яңгыр!..
Шушы шау аша
ара-тирә ишетелеп куя
ниндидер бер
ят кош тавышы:
— Фьит! Фьит!..
Без тыңлыйбыз, гүя шау диңгездә,
йөрәк белән калып
бергә-бер,
ялварамы ул кош,
чакырамы,
эндәшәме әллә кемгәдер?..
Яшен яшьнәп,
күк чатырдап китә,
шушы шауга
күкләр җыры гөрләп кушыла!..
Ә җырчысы...
яңгыр асларында
ялгыз калып,
шул күшеккән
ялгыз кош кына!..
Фортепьяно моңы... ташкыннарга
клавишлар
йөгереп
кушыла!..
Күк катыннан
җиргә иңә гүя
и илаһи серле догалар...
Күз алдында гүя шаулагандай
күктән агып яткан
елгалар!..

Сокландым мин Ходай кодрәтенә,
биеклектә... килеп һушыма.
Күкләр тынып калды,
тынды кош та...
Ни булгандыр
моңлы кошыма?..
Күкрәүләргә кушылып сайрады ул,
күрде галәм аның сәләтен.
Мин чын шагыйрь булыр идем,
әгәр,
төнге гарасаттан табып гамьнәр,
әйтә алсам
кошның
халәтен!
Яки бирсә... шул кош
сәләтен!..

*2003*

## Килгән идем...

Килгән идем...
шаулап көлгән идем,
кергән идем сезнең бакчага...
Кайтып булмас кире, чакырмагыз,
сулар кинәт үргә акса да...

Ераклашам сездән,
китеп барам...
Киттем инде сездән
яртылаш...
Кайтаваздай йөри ярты җаным,
Эңгер-Күлгә иңде
ярты баш!..

Шуны тану — әллә батырлыкмы,
Әллә шоммы гомер итүләр?
Батырлык та түгел,
түгел шом да, —
бу — гадәти
          килеп
                    китүләр...
...Тәрәзәңә килеп бәргәләнсәм,
канатларның калыр укасы...
Тәрәзәңне ачып чыгар мине, —
күбәләктән әллә куркасың?!

Ак дөньяның кайсы почмагында,
сине кайда күргән идем бер?..
Син елмаеп калдың өлгеләрдә!..
Бер күрүем булган —
                    бер гомер!..
Гадәтенчә тормыш дәвам итәр, —
     кем шатланыр анда,
                    кем елар...
     Син гафу ит,
                    сынды канатларым,
     Җиталмадым сиңа...
                    мең еллар!..

*2003*

# Борынгы көйгә ике җыру

**1**

Ак тегермәннең ташына
арпа белән богдай бушаттык.
Өйдән өйләргә генә кереп йөри
бер хәсрәте белән бер шатлык...

Гөлдер-гөлдер килә кара болыт
урман өсләреннән, кыйбладан...
Килгән икән, яшәп китми булмас
ганимәтләр тулы дөньядан.

Рәхмәт инде сиңа, рәхмәт, әнкәй,
барыбызны да дәштең табынга.
Капкан ризыклары аш була шул
барыбыз да бергә чагында...

Офык арты — офык, катлы-катлы,
күк томаннар арты — күк томан...
Барасы юл, шөкер, безгә булыр, —
яшиселәр әле күп сыман...

**2**

Чәчтек тә без богдай, бирде Ходай,
вак иләкләр кирәк иләргә.
Заманалар авыр, булыйк сабыр, —
уйланып ла кирәк сөйләргә.

Кыл күпердән ары чыгасы бар, —
кичәселәр бардыр Сиратны.
Чор болгавыр. Әмма бозмый беркем
Сиратларга барыр чиратны!

*2003*

* * *

Салкынча җил китте кагылып кына,
тупылларга гүя җан иңде:
яфракларда — яшел клавишларда —
симфония башлый таң җиле!

* * *

Күрше бакчада кем сайрый,
тавышы бик күтәренке?
Песнәк көмеш игәү белән
иги язгы күгәрекне!

* * *

Кай илләрдән килә идең,
Күрдем куләгәңне дә...
Син күбәләкмени, җаныем?
Шул көнгә калдым мин дә...

## Алмагач кызы

### (Сынчы монологы)

*Миргазиян Юныска*

И ямьле дә бер алмагач идең, —
таң җилендә калды буй-сының!..
...Минем кулда бүген син бары — Сын,
син Сын миңа, —
яшә буйсынып!..
Шау алмагач идең, —
сукты яшен! —
авып төштең
беркөн үләнгә...
Хуҗаларың сине кызгандылар,
турадылар аннан...
пүләнгә...
Син — бер пүлән,
минем кулга күчкәч,
иркәләдем сине азмы соң?..
Син — Сын миңа, бүген минем кулда
киләчәгең,
бөтен язмышың!..
Гади түгел,
син — Алмагач кызы,
шул агачтан сине яраттым.
Син бер агач идең,
мин бар иттем! —
Күзләр уйдым,
үземә караттым...
Мин рух өрдем сиңа!
Яшәү суты...
Типте! Типте... Гүя йөрәгең!..
Елмайгандай булдың!
Шул мизгелдән

кулдан-кулга күчеп йөдәдең...
Яраттылар сине, сыйпадылар...
Калкып чыкты... хәтта...
                    күкрәгең!..
И Ходайның гаҗәп бирмеш көне, —
нинди язмыш кемгә кайчакта?!
Бала-чага сиңа гашыйк сыман, —
тарткалыйлар сине як-якка,
сөйрәгәндәй кызны аулакка!..
Шулай көлә язмыш кайчакта...
Шаулап торган бер алмагач идең,
әверелдең бүген...
                    курчакка!..

*2001*

## *Эше беткән...*

...Эше беткән,
                    иртә караңгыдан
кабаланып чыгып чабасы юк...
Эше беткән,
аласылар — алда,
бирәсе күп...
Кайный өйдә —
                    тары өйрәсе күк!
Көнне тарый —
                    тәрәш кабасы күк,
инде янда бала-чагасы юк —
бар да очты! —
          кузгалмаган савыт-сабасы күп!..
Югалту күп,
                    алда табылыр күк,
Күк капусы
                    ачылып-ябылыр күк.
Бар куаныч —
                    таңнар тишегеннән
ишегеннән чыгып чабасы юк!
Аш — ашалып,
яше гүя яшәлмәгән.
Өс-баш бөтен, шөкер, тамагы тук...
Мәшәкать күп,
                    алда — гомерлек ял!
Пенсиягә бүтән чыгасы юк.
Чамаларның алда чамасы юк!
Тик...
гомернең алда
                    яңасы юк!

*2002*

# *Ант*

*Татарстанның Беренче Президенты*
*М.Ш.Шәймиевкә*

Ант суын эчкәннәр — дуслыкка,
иң изге, мөкатдәс гамәлгә...
Ант итми бер Кояш:
                    ул сүзсез
нур сибеп җан өрә Галәмгә!..

Тын яна! Гаугалы бу чорда
кыендыр тын гына янулар...
Тәвәккәл Игенче юлы ул
Беренче Буразна ярулар!

Гомерлек ялчы син, и халкым, —
Азатлык килерме сиңа бер?..
Шау Кояш каршында
                    халкына
Ант итә Президент
                    Минтимер!

*Август, 1991*

* * *

Шушында гына кеше мин,
тик шунда гына — кеше.
Әрем-әрекмән илендә
кеше юк
минем ише!..
Картайган ишәк шикелле,
далага мине җибәр, —
шундый чиксезлек каршында
тәгәрәп үләм, юләр!..
Ташбаш балык — бары шушы
инештә генә балык.
Үлеп чыгар —
кара аны
Кара диңгезгә салып!..

*2003*

## Татар иртәсе

Әле татар чукындырылмаган,
Җимерелмәгән Казан диварлары,
Кол Шәрифне кылыч чапмаган,
Сөембикә әле үсмер бала...
Кара яла ягып ак дөньяга,
Шаһгали дә денен сатмаган.

Милләтемнең таза, үсмер чагы,
Итил-йортның дөрли үз учагы, —
Иман бөтен әле безләрдә...
Үт агызып кяфер бушанмаган,
Әле беркем җирдә ышанмаган
«Татар — батар!» дигән сүзләргә.

Офыкта юк хәвеф күләгәсе, —
Итил-суда очкан кош шәүләсе,
Атларыбыз утлый чабында...
Олы юлда күтәрелми тузан,
Корган талга кунган бала козгын
Өмет итә нидер табынга?..

Әле татар чукындырылмаган,
Дию бәйдән ычкындырылмаган,
Хыял — дәрья, каерып иш кенә!..
Тарихыбыз өчен бу — бер мизгел,
Ыруларым өчен керсез, изге
Сабыйлыкта күргән төш кенә!

*1993*

## *Тузга язган хатлар*

Тузга язмаганны сөйләмә.
*Халык сүзе*

Язган алар,
ыруларым язган
таш китаплар,
камыш китаплар да...
Язмышлар да безнең тузга язган, —
катлам булып калган
хитапларга...
Килә һаман тузга язган хатлар,
катлам-катлам Тарих төпләреннән.
Ничә гасыр элек ыруым язган, —
җан әрнүе булып күтәрелгән!..
Катламнарда — биш гасырга күпме
таркалгандыр татар атомнары?!

Ыруларым катламында яшим, —
җирне җылыта зәңгәр ялкыннары!..
Йолдыз булып күккә тезелгәнме
күккә ашкан гаярь җаннарыбыз?
Кара алтын булып кайта мәллә
Казансуга койган
          каннарыбыз?!
Милләтемнең яшел курпыларын
Колшәрифләр каны хак ашлаган.
Тузга язган ыруым хатларында
сәфәремә Дога багышланган!..
И милләтем, әле таза-ныкмы,
көтәмсең син кемнән Азатлыкны?..
Гомер бакый эчеп явызлыкны,
Мәскәү суза синә
          авызлыкны!..
Үрчи бара маңкорт, азынганнар,
Тарих бозып «шөһрәт» казанганнар...
Халкымның бу «чынкый» Тарихында
күбәйгәндә
          «тузга язмаганнар»!..
Тузмый алар —
          тузга язган хатлар.
Узмый алар —
          тузга язмаганнар!..

*2002*

# Төнге поезд

...Хөр мәмләкәт,
Хөр Русия!..

*Г.Тукай*

Төнге поезд алып китте безне, —
ниләр көтә төнге поездны?..
Әллә соң бу коллар шалунымы —
җиде төндә вагоннарны айкап
кем узды?..
Ниләр көтә төнге поездны?..
Оча поезд йолдызлы чатлардан,
йоклый вагон —
чалып аткандай!
Кая бара бу Ил — йоклап-күшәп,
«хөр мәмләкәт», ишәк угылы Күсәк
халыкларны сарыклатканда,
милләтләрен
ваклап сатканда?!
Көтәме дим алда изге сәфәр,
чатта тора зәһәр угылы Каһәр
«һич бүленмәс»
уртак ватанда,
Русиядә — үги атаңда?!
Изге юлга чыкканмы бу халык,
«барып чыкканнардан» үрнәк алып,
ничек көтә алда Киләчәк?
Аһ-зарларга төрелеп, вокзалларга,
шәүлә булып,
үзебездән алда
күрәчәкләр
килеп керәчәк!..
Ә хәзергә... Хорга җырлау кебек
гырлау тора бөтен купеда!

Хөр мәмләкәт әллә безне хөрде,
Өфеләрдән безне
кем өферде, —
барасылар юкмы Өфегә?..
Төнге поезд әллә үзе микән —
Ил эчендә — туган илсезлек?
Төнге поезд — шыплап тулган йокы! —
милләтсезлек гүя,
телсезлек!..
Хәтерсезлек иле, кадерсезлек, —
калганнарын инде...
белгән юк!..
Төнге поезд алып китте безне,
юлсыз юллар вәйран итте безне, —
шуннан бирле...
кайтып
кергән юк!
Хөр мәмләкәт йөзен күргән юк.

*2001*

# Арбачы

Мәгърифәтне, аң-белемне
Ник, энем, эстәмәдең?
Максатыңа барыр юлга
Дәртеңне өстәмәдең...

И сөйкемле тай идең син,
Нигә «солы»га кердең?
Ганимәткә илткән юлдан
Фетнәле юлга кердең...

Китмәк идең җиңел юлдан...
Арбаңны сөйрә инде.
Аңа да Тормыш төялә, —
Үзенә күрә инде!..

Тарт инде, олан, арбаңны,
Булса да йөгең авыр.
Кемгә дә дөнья нужасын
Җигелеп тартыргадыр?!

Тарт, әйдә, милләт газизе,
«Бахбаең» арганмыни?
Көн дә сине көтәчәк ул, —
Тартмаган арбаңмыни?!

Ике тәртә арасында
«Ломовой»дай, тартылып,
Арлы-бирле йөгерә арбаң,
Тагын булыр... «ярты»лык!..

Әле сине, бичаралар,
Уйлыйлардыр «тегендә» —
Уйлы каен төбендә —
«Улыбыз кеше булды!» дип,
Әниең, әтиең дә...

*2004*

## Сөннең ике ягы

...Сезнең якка карап торам,
ерак түгел ара.
Ике дәүләт чиге бу Сөн —
йөрәкләргә кага!..

Мин бу яктан торам карап,
аргы якта — Илеш.
Кем гайбәте: кайсыбыздыр
чикне боза, имеш?!

Гадел калеб, кирәк икән,
ят чикләрне ватар.
Уртак суга кармак сала
башкорт илә татар.

Һәркем тонык Сөнгә баккан —
үз ярында — солтан!..
Йә мунчала эләгеп чыга,
йә... сәяси олтан!..

Ят уйлардан арыныйм дисәм,
суга кармак салып,
чү, эләккән кармагыма...
«башкорт» дигән балык!..

Син акула тоттың бугай
сай гына шул судан:
эче аның татарыңа
коткы белән тулган!
Бу ни, башкорт туган?

Шул «акула» суга сыймый,
йота балыкларны!
Балык түгел, «татар» атлы
«чит-ят» халыкларны...

Әле матур килә идек
бер үк такыр юлдан.
Инде «дошман» тотыйкмыни
шул болганчык судан?!

Күңелем киң — җилпеп аттым
киңлек — кармагыма!
Бер селтәндем — барып төште
Сөннең... аръягына!

Бусы — нәфес! Кемнең дә бит
үзенә карый бармак:
гафу, димен, сезгә төште,
чикне бозды кармак!..

Бозса тагын дәүләт чиген
бозар казлар гына...
Сезнең бака йөзеп чыгар
Актаныш ярына...

Сөн генә тик демократик —
аермый ярларын:
ике яры да бик якын,
кадерле шул аның!..

*2001*

## Уникe кысыр калэм

*Айдар Хәлимгә*

Мәскәүдә узган юбилее кичәсендә
шагыйрьгә милләттәшләре 12 алтын
каләм бүләк итәләр.
Иясенең әйтүенчә, шуларның
берсе дә язмаган, имеш…

Безгә Мәскәү бүләгедер —
унике алтын каләм!
Язам аерым каләм белән,
язам —
берьеллык сәлам, —
вәгаләйкем әссәлам!..
Каләм алдым — юк карасы!
Ничараның бичарасы, —
мине ничек коткарасы?
Шаккатып тора галәм! —
Унике алтын каләмнең
ник берсе язсын сәлам, —
вәгаләйкем әссәлам!..
Рәхмәт инде, милләттәшләр —
Мәскәү татарларына!
Сәлам язмыйм мин аларның
күңеле тарларына…
Унике алтын каләмем
керешә зарларына:
уникедән беребез дә
бер хәреф язмый гына…
Татар язмый! Ул — акыра!..
Ул яңа азды гына!..
Безләргә җитми ихласлык,
каләмнең карасыдай.
Бушлармы без?
Кем җан өрер

без татар баласына?!
Язмасын дип биргән гүя —
унике кысыр каләм.
Алтыннарга манылганчы,
булсачы ялкын адәм!
Язмыйсың, газиз угылым, син,
нигә язмыйсың, бәндәм?..
Әллә, буш каләм шикелле,
рухсыз калганмы гәүдәң?
«Хөрлек җыры»н язмак идең,
оныттың? Кайда вәгъдәң?..
Беттеме, халкым, базарың,
базарым, диеп язарың,
киттеме әллә
сәүдәң?!
Вәгаләйкем әссәлам!..

*2002*

## *Казанга мәдхия*

Балкыта җирне мәңгелек язың,
дәртле көйләрне уйныйдыр сазың...
Ак диварларың
хәтерли барын,
мең яшьлек Казан,
мең яшәр Казан!

Иркәли җанны Идел һавасы,
ишетәм синдә әнкәм авазын.
Мәхәббәтем син,
бәхетем каласы,
мең яшьлек Казан,
мең яшәр Казан!

Сиңа, ак калам, безнең язмышта
изге йортыбыз булырга язган.
Дастаннар җире,
яугирләр иле,
мең яшьлек Казан,
мең яшәр Казан!..

Һәр ташың синең җанлы, хәтерле,
сиңа мәдхия Тукайлар язган...
Милләтемнең син
алтын бишеге,
мең яшьлек Казан,
мең яшәр Казан!..

Кайталар сиңа Сөембикәләр,
Колшәрифләрең калка яңадан.
Бәйсезлек рухы яшәр мәңгегә,
яшәр мәңгегә,
мең яшә, Казан!..

*2002*

## Әманәт

### I

Безне сулардан куганнар,
«бөек милләт» булганнар,
уттан алып, бозга салып,
чукындырмак булганнар.
Уттан алып, суга салып,
бары чыныктырганнар!..

Итил-суларга ятып,
бер батып та, бер калкып,
түләгәндер бу халкым
җирдә яшәүнең хакын?!

Безне бозлы Казансуга
кылыч айкап куганнар
«бөек урыс туганнар».
Баткан-чумган, чукынмаган,
иман-имин, туганнар.
Үлсәк — үлгән, иман — бар!
Килсә килсен Идел-йортка
күпме Явыз Иваннар,
сер бирмикче, оланнар!

Безне сулардан куганнар,
үзебезнең сулардан...
Ыруым кабер ташлары
кан-яшькә чыланган!

### II

Биш йөз ел элек батканнар
калкабыз сулардан.

Чыгабыз төптән ишелеп
азатлык суларга!
Яшәвебез-дәшмәвебез
кыйммәт соң һаман да,
маңкортлар баш түбәбездә
биегән заманда!..
Үз кадереңне белмәгәч,
кем безне кадерләр?
Бөтен суларны буйлатып,
изге дулкыннарга ятып,
Чулманнан Хәзәргә чаклы
чайкала тәреләр,
чайкала тәреләр!

Җыйналыйк, милләт рухына
бер дога кылганнар.
Әманәт: чынкый тарихны
укысын оланнар!

*1999*

## *Азатлыкка кереш*

Азатлыкның бер йотымын гына
татып карар өчен... үлә халык!..
Чапаланып ята ярда балык,
саңаклары белән сулыш алып,
күккә багып ята,
«хәйран калып!..»
Аяз күктә азат кояш балкый! —
...Ә ул йөзә алмас
гомер бакый!..
Су буенда ята
суга сусап...

Тик бер йотым азатлыкка сусап,
тыны беткән
балык мисле халык...
Балык дәшә алмый,
халык — ләм-мим —
шул балыктан әллә
үрнәк алып?!

Житте, вакыт!
Ятма оеп-талып,
азатлыкмы сиңа
бер йотарлык?

Вакыт инде, татар,
Ил-байталның
дилбегәсен үзең
нык тотарлык!
Нидән өркеп калдың?
Әллә инде
кылган гамәлләрең
җир йотарлык?

Ант-шигареӊ җирдә ятарлыкмы,
әллә юлдан тибеп атарлыкмы?
Күрсә иде гавам: җирдә ныклы
сан
    сыйфатка
        үскән
            татарлыкны!

Азатлыкмы сиӊа бер йотарлык,
урыс бәлзәмеме — үт сытарлык?..
Иле белән чүккәнме
        татарлык? —
Нинди тарлык!..
Түгел инде җирдә бу тарлыкны
бүтән тарлык белән
һич бутарлык!..

*2002*

# *Чакыру!*

*Кайбер татар маңкортларының Мәскәүдән*
*Казанга наместник соравы уңаеннан*

Җаным өшеп тыңлыйм: милләт, сиңа
кайдан килә мондый маңкортлык?!
Күз дә йоммый сөйли: без Казанга,
тәртип өчен,
                кизү чакыртыйк!
Мәскәү, сиңа дәшәм,
                кизү җибәр, —
күреп торсын татар гамәлен.
Азды татар, узганнарын оныта,
һич калмады түзәр әмәлем...
Һәр таң туса, торып: «Азатлык!» — ди,
уйлап тапты гимнын,
                әләмен!..
Оныткан ул,
                киндер алъяпкычтан,
чабатадан, тула оектан,
гөбернәнең ат абзарын себереп
яшәгәнен, карап ярыктан...

Гомер буе татар Миңлебае
йомышчы бит,
чапкан йомышка...
Шулай уйлый, татар, маңкортларың,
йөз чөереп
                синең язмышка!..
Күпсенә бер йотым азатлыгың:
сез наместник бирегез Мәскәүдән...
Телен белми...
                Урыс сүзе шуңа
ягымлырак татар дәшкәннән...

Мәскәү, имеш, куйсын наместниклар,
надзиратель кирәк Казанга!
«Мөстәкыйльлек!» диеп,
    ничә гасыр
лаф ора ул,
Мәскәүләргә каршы казгана!..
Онытмасын:
    бар ул «лобное место» —
баш бүкәне...
Балта үтәр сезнең муенга!
Кызыл чөгендердәй канлы башлар
кайсыгызның,
    татар,
        уенда?
Гәүдәсеннән
    баш мөстәкыйль булыр,
җаның биер
    гареш туенда!..
Йә, кайсыгыз тели мөс-тә-кыйль-лек?
Ә син, маңкорт, шунысын танып кал.
Төчкермичә,
    тып-тын ята мышнап
мари урманында
танклар...
Мәскәү, имеш, куйсын наместниклар,
надзиратель кирәк Казанга!
Каезларга кирәк,
    «Азатлык!» дип,
татар дигән
милләт азганда,
Явыз Иваннардан булса — шәбрәк! —
бугазыннан шунсыз
    аш үтми.
Шунсыз аңа, имеш,
язы да юк,

тамчы тамуларын ишетми!
Каян килгән теленә ут вә агу,
милләт аңа — «нәҗес татарва».
Ул иманын саткан,
                    анасын да,
сатылыр өчен
                    әзер сатарга!
Ана башына җиткән,
                    мөмкин аның
дәүләтнең дә башына җитүе.
Тарихта бер инде булган, дисәк,
татар җирлегендә утлап йөри
яңа Шаһгалиләр
        көтүе!
И татарым,
тамырыңа төшә,
астан кисә алар,
                    акыртын...
Мөнбәреңә үреләшовинистлар,
ә иң алда —
синең маңкортың!..

*1999*

## Без — бергә!

*Татар конгрессына*

Җир сөрдек тә, таулар күчердек без, —
Күнекмәгән яшәп кадердә...
Сибелгәнбез бөтен кыйтгаларга,
Хәвеф килгән чакта
Без — бергә,
Без — бергә!

Әйтте дошман: «Татар ишәймәсен», —
Сөрелдек без салкын Себергә...
Җир төбенә җитеп күмер чаптык,
Сүнмәс утлар яктык
Без бергә,
Без — бергә!

Муеннарга көчләп тәре асып,
Бастырдылар утлы тимергә...
Төпсез упкын, кара зинданнар да
Аералмады безне,
Без — бергә,
Без — бергә!

Күп тырышты алар, кертер өчен
Тере килеш безне кабергә.
Инкыйразлык йотты язмышларны,
Җаннарыбыз кайтты, —
Без — бергә,
Без — бергә!

Безнең өмет бары бердәмлектә,
Бердәмлек ул — маяк гомергә.
Идел-йортны туар гасырларда
Кыйбла итеп яшик
Без бергә,
Без — бергә!..

# Тайгак ватан

## 1

Олы Ватан...
Зәмһәрир җил исә чаттан.
Җилле-бозлы тайгакта
егылды Ат... һәм сузды
дүрт аягын дүрт якка!

Уза халык — усаллык! —
карамый да ул якка,
бозда яткан бу затка:
«Яхшы ята, кузгатма...»

Салкын бозда... Күз агы
карап тынган еракка —
солылар үскән якка!..

Инде ниләр кыласы —
хәерсездер йоласы:
егылып үлсә йөк аты,
аяк сузар — ил аты...

Кызганганы кызгана,
күпләренең — эше юк.
Офыккача — тайгак кичү!..
Халык күп ул! Кеше — юк!

Җил аралаш ниткән җыр бу?
Ятимнәр, толлар җыры...
Офыклар салкын, соры...
Әллә илнең бәгыренә
кайтамы бозлык чоры?!

**2**

Син, Русия!
Тайгак ватан —
сөремле җил исә чаттан,
миллион сукыр тәрәзәләр
тәмугка баккан яктан,
илбасар адәм канына
тубыктан баткан яктан!..

Бозлы ватан,
ике башлы козгын-ватан,
башкисәр, азгын ватан…
Вөҗдан,
сине Илдән сөрде
Русия — үги атаң!..

Үз илем — Татар Иле дип,
тик үземне юатам!..

*2003*

## *Ана өмете*

И дөньяда Ана булу бәхете!
Таң эңгере аша юраулар!
И теләкләр: өмет гөлемне, дип,
Шиңдермәсен, берүк, кыраулар...

Ул карында әле, сулый шунда,
И тибенә, йөгерә шикелле!
Исән генә тусын... Миңа барлык
Йөклеләрнең йөзе — сөйкемле!..

И тибенә! Нәнкәй тәпиләрең
Кая чаба шулай, нарасый?..
Ашыгасың җиргә басар өчен —
Алда юлың кая барасы?..
Җирдә кемнәр кочак җәер сиңа,
Син кемнәрнең көткән иркәсе?
Сине миннән суырып алмас микән
Соры көннең салкын иртәсе?..

Туа уллар...
Сугыш министры
Яу кырына куа барын да...
Потенциал җәллад йөртсәм әгәр —
Җаны чыксын минем
карында!..

*2001*

* * *

Кайсы стансадыр, белмим, җаным, —
платформаның аргы ягында
сагындырган йөзең чагылып китте,
«Менә — кавышу!» дигән чагында.

Араларга, шаулап, җилдәй очып,
озынлыгы чакырымнар белән түгел,
еллар белән исәпләнгән
по-езд ки-леп кер-де!..

Калдык шулай
гомерләрнең ике ярында...
Эшелондай озын еллар уза,
синең урының... кайсы вагонда?!

*1987*

## *Кузгалдык!..*

*(Вөҗдан манифесты)*

...Инде узган яу-чирүләр. Явыз Иваннар, дисәң,
Диварлар артыннан яшерен уклары юнәлтелгән.
Сизәмсең үзең, кандашым, ул вәхшәт сафта, исән —
Халкымның янган Дәүләте, кузлары көйрәтелгән...

Иелгән башны кылыч һич чапмый, дип, башың исәң,
Ялгышасың, башың очар, урынында калыр күчән!
Тәҗрибәле арасында ул фәнне белә ничәң?
Тумыштан безнең каныбыз ул фәнгә өйрәтелгән.

Тының бетеп, киң дөньяга, йә, бер эндәшим, дисәң,
Эндәшмибез, ләм-мим, гүя без — балык милләтеннән!
Узды изеп явыз кавем, шулай да яшим, исән, —
Суласын дип без балык — су төпләре җилләтелгән!..

Яктырып торсын мәсләгем көндезен-кичен, дисәм,
Күз чагыла «демократик оҗмах»ның зиннәтеннән.
Рухым чын татар рухы, дип, инде күкләргә күчәм.
Ташлама, и көрәш рухы, тәҗрибәң өммәтеннән!..

Килмәсә, туры килмәсен Мәскәүгә безнең үлчәм, —
Милләтең исемен оныт, дип, мең кабат төнәтелгән!
Җанымны кысадыр тарлык, инде Мәйданга күчәм —
«Ул була калса...» дип, безгә богау да... юнәтелгән.

Курыкма, куркып сулама, и Татар, яшим дисәң, —
Яшәргә хакың — үзеңнән — мең кәррә түләтелгән!
Вөҗданым имин булсынга, ут вә суларын кичәм,
Яңа гасырга сау чыктык, әмма Тел... имгәтелгән!

Саркыган хөрлек чишмәсен Кәүсәргә тиңләп эчәм.
Бар да бар, тик юк бердәмлек, ни сорыйм милләтемнән?!
Юлыбыз ерак — чорлар аша — барсын ал жәлләмичә,
Дәрман җитмәсә, ал — яңа байларның келәтеннән...

Дөньяда алганның барын булмас бер түләмичә, —
Тупла Мәгърифәт нигъмәтен, һич торма кыйммәтеннән!
Булмас Азатлык кәрванын хак юлга әйдәмичә,
Аермасын безне гомер хаклык вәкаләтеннән!..

Хөррият юлына чыгып, борылдык әллә ничә, —
Кузгалдык, татарлар! Ходам, ташлама кодрәтеңнән!!!

*2003*

# Тышаулы ат

Тышаулы ат идең, Татарстан,
Татар Иле, изге ватаным.
Төшләремә кереп куандыра
Тышауларың өзеп чапканың!

Тупырдадың кысан Ил-абзарда,
Гомер буе йокың сак булды.
Буразнаңда үлгән бабамнарның
Бар хыялы туры ат булды.

Катмарлымы, әллә кантарлымы —
Барыр юлың һәрчак хак булды.
Тышаулы ат, кемгә охшаулы ат,
Синең атың яманат булды!

Томырылып чапкан тояклардан
Чакма утлар чәчүең хак булды.
Улак төбең такыр чакларында
Өметләрең актыйн ак булды.

Яу кырына кереп, маңгаеңа
Йолдыз уеп чапкан чак булды.
Җайдакларың Әҗәл суын кичте,
Вөҗданнары гомер пакь булды.
Офыкларга җәелә көр кешнәвең, —
Тышавыңны өзәр чак туды!

*2000*

# Хәтер көне

Уян, уйлан элек, ихлас җаным, —
Бөек Хәтер көне килеп җиткән.
Уяндыкмы соңлап — язмышларда
Татарның бу хәтәр көне икән.

Булмаган да гүя ул кыямәт —
Хәтерсезләр бирә алмас җавап.
Хәтерлеләр хәтта мәрткә киткән,
Әллә безне хәтерсезгә санап?..

Килде ул Көн, шакый диварларга,
Йөрәкләргә шакый, хәтерләргә.
Шәһит җаннар кайткан мәйданнарга.
Мәдәт бирче барын хәтерләргә!

Без ул чакта булган туфрак кына,
Үстергән лә безне Хәтер, тартып:
Тез чүккәнче Иблис тәресенә,
Кылычлардан чапкалану артык!..

Туфрак биргән, күкләр үзенә алган
Кол Шәрифтәй фида җанлы ирне.
Бугазлардан сызылып аккан каннар,
Кан ашлаган без шытасы җирне.

Туфан булып калыккан ул җирдә
Яугирләрен сагынып сыза Казан...
Хәтерсезләр саткан Татар Илен,
Сатлык язмышлары безгә калган!

Диварларга сеңгән җаһилләрнең
Намазларын буган ят авазы.
Таңнан таңга йөри офыкларда
Сөембикәләрнең кайтавазы!..

Җан яфрагың дәшә оныкларга, —
Моны, кандаш, һич тә син онытма:
Яшел курпы булып тишелгәнбез,
Шытып чыккан — офыктан офыкка!

Инде, торып, бил турайтыр өчен,
Җитсен, ыруым, олуг көчең генә.
Бу туфракта бер шытсаң да ярый,
«Хәтер» сүзен әйтер өчен генә!

Үткәннәрең өчен үкенсәк тә,
Киләчәгең барсын бик еракка...
Ошбу көздә очкан хәтер-яфрак
Тәһлил әйтеп төшсен
Бу туфракка!

*1999*

# Мөсафир

Илеңнән киткәндә карадың каерылып
Ярларга, судагы камышка.
Җилләргә бирелгән җилкәндәй аерылып
Киттең син баш иеп язмышка.

Илеңнән киткәндә, кычкырды акчарлак,
Каядыр бер карга эндәште...
Каркылдап, сулкылдап, күкләрне акшарлап
Озаттылар борлыккан илдәшне.

Туган йорт кыегы күмелгән шул мизгел
Әйтерсең ашуың гарешкә!
Син идең ул чакны, мөсафир, иң изге
Күкләрдән сөрелгән фәрештә...

Илеңнән киткәндә карадың бер якка —
Судагы ямь-яшел кыякка.
Кояшка табынып китсәң дә көньякка,
Карарсың илеңә,
Бу якка!

Күкрәгең тотарсың,
Сагынып еларсың —
Илеңне табарсың сул якта,
Ватаның хәлләрен җилләрдән сорарсың,
Шау күмер сүрелер,
Көлләргә төренер учакта.

Сагынудан янтаер туган йорт нигезе —
Кем булыр,
Кем булмас ул чакта.
Гөл сулыр суынган кочакта.

*1993*

* * *

И Туган ил, кем каргады сине,
тургай эзләп йөрим далаңнан?..
Таланган йорт бит син, Туган илем, —
каракларың хәтта таланган!

Синдә бүген гүя ау фасылы, —
тыелмаган кеше аулары...
Бөлгенлеккә төшмәс идең болай,
узсалар да магыл яулары!..

Күзләреңә канлы шәфәкъ төшкән,
и билчәннәр баскан багыңны...
Дөньякүләм янгыннар да болай
яндырмаслар иде җаныңны!..

...Таң алдыннан гөлләр сагынып елый
ерак калган җиләс таңыңны...
Синдә минем җаным елый,
сагынып
пәйгамбәргә ышанган чагымны!

*1991*

## Дәрвиш

*(Соңгы чатыр)*

Актардым да күңел дәфтәремне,
Өйдем бергә дәрвиш елларымны...
Чакрымнардан чакырып алдым, чакырып,
Чакрымнары чикле юлларымны...

Барган саен килде тәҗрибә дә,
Вакытларны сорап ай-кояштан,
Кыйблам иде Казык йолдыз ягы,
Акты судай,
Исте җилдәй гомерем бертоташтан!

Далаларда, япан сахраларда
Кылган-акчәч сипте җыруларын...
Күрдем: кунган очар кошларның гел
Җилгә каршы карап торуларын.

Акты юлым җилгә, комга каршы,
Күк чатыры җирне тоташ япкан.
Алышынып торды ике шәмем:
Аем чыккан чакта Кояш баткан!

Изгелекләр кылмасам да җирдә,
Булмаса да иткән савапларым,
Юк канымда аккан хәрам ризык,
Ятмый җанда адәм газаплары!..

Аңлар микән юлым адәм, гавам, —
Юрауларның инде юк кирәге...
Чүктем төбеңә. Соңгы тукталышым,
Чатырым булчы,
Ефәк тут тирәге!

*1993*

## Кинэ

Тип, әйдә, заман, оятсыз,
Тулпарым калды тояксыз,
Юл хәвефле, Ил җыйнаксыз,
Кунак булганнар — тыйнаксыз...
Әтрәк-әләм менде түргә,
Даһиларың
күчә
гүргә...
Сук, әйдә, заман, оятсыз,
Кыр — күзсез, урман — колаксыз.

Чыгу юктыр инкыйлабсыз!..

*2000*

## Татар дулкыны

Бөтен дулкыннарны айкап эзлим, —
Килмәс икән татар, килмәсә!..
Бөтен дулкыннарда көне-төне,
Эфир ярып,
ятлар сөйләшә?!

Юк, сөйләми татар,
Ул гел җырлый,
Әллә шыңшый, әллә елавы?
Эзоп кебек, моң теленә күчеп,
Шулдыр аның, бәлки, уйлавы?..

Үз телеңдә ярып әйталмыйсың,
Үз илеңдә тотык шикелле...
Үткән гасырда да әйталмадың,
«Яңа гасыр»да да
икеле?!

*2003*

## *Сиреньгә мәрсия*

Хуш, Сирень, гафу ит, җаный,
Мин сине өзгәнемә.
Утыра идең охшап язның
Күк күзле гүзәленә!

Утыра идең, и бәгырь,
Җилләрдә уйнап, көлеп!
Сыгылып ла төштең вазамда
Тол калган килен кебек!

Иелдең, матәм байрагы,
Кайгылы байрак сыман...
Өзелеп лә төшкән каурыйдай
Фәрештәм канатыннан!..

Бу җиргә килер күп язлар,
Дәрьялар ташар тулып...
Сиреньнәр шаулар! Җанымда
Калырсың
Прима-Сирень булып.
Күк җыры булып агарсың,
Күңел дәрьяма тулып!

*Июнь, 2003*

## *Юаньч*

Көнен-төнен, алга карап,
Җилләрдә оча Байрак!
Җилгә каршы бара Байрак,
Болытларны аралап!..

Җилнең боргаланган чагы,
Байраклар белән уйнап...
Үзең очардай буласың,
Алсу офыклар буйлап.
Иркәләнеп һич туймассың, —
Җилләре шундый уйнак!

Сырпалана, йөзен төртә
Йә Британ байрагына,
Дүрт ягым — кыйбла дигәндәй,
Иссәм дә кайда гына!..

Истем, ди, тузан туздырып,
Гасырлар итәгендә.
Капшадым инде тевтоннар,
Чыңгызлар ефәген дә!..

Хөр җилләр иркендә йөзгән
Бары ул — Байрак кына!
Иле дә юана, очкан
Байракка карап кына!..

Азатлык кыйбласына ул
Карасын хәйран калып:
«Байрагым оча хет!» — дисен
Канаты сынган халык!..

*15 апрель, 2003*

## Төсле төш

Сабый чакны күрдем төшемдә...
Шул төсле төш
һәрчак исемдә...

Имеш, безнең урам — Өчиледән
төшеп килә мичче Мөбарәк.
И бабам яшь, әле исән икән,
үзе көләч, йөзе түгәрәк.

Ә артыннан төшә безнең Мохтар,
әллә чабып, әллә тәгәрәп,
ара-тирә җилгә өргәләп...

— Син авылны, ахры, оныттың, — дим, —
сукмыйсың син безне санга да.
— Эшләр тыгыз, кызыл балчык мулдан,
мич чыгарам, олан, анда да...

Вак яңгыр тора сибәләп,
тамак кырып мичче Мөбарәк
яшьлегенә кайткан кебек уза
авыл урамына, түргәрәк.

Ул кызмача, имеш, мич чыгарып
кайта керәшеннән, марҗалардан...
Аның хөрмәтенә авылымда
төтен чыга бөтен морҗалардан!

*1998*

# *Елан туе*

...Мич авызы сыман кайнар дала,
селкенми дә утыра кылганнар...
Дала буйлап ишелеп, әүмәкләшеп,
туй уздырып килә еланнар!..

Дала буйлап шуыша хәтәр өер,
бар да гүя фахиш-фахишә:
өегешеп елан явы шуыша,
әүмәкләшеп күмәк бау ишә!..

Өеренә килеп керә яздым,
әле ярый Ходай саклады!..
Сабак алдым кабат: и гомернең,
була шундый хәтәр чаклары!..

...Капыл искә төште Синең туең, —
бер кинәдер гомерем буена:
тәрәзәңдә аллы-гөлле утлар,
бәхетле пар нурда коена!..
Тәрәзәңнән туең күзләрмен, дип
килмәде лә һич тә уема...
Рәхмәт инде шундый «сыеңа»!..
Син туеңа мине чакырмадың,
эләктем вәт Елан туена!..
«Пары» җитәр гомер буена...

*2002*

* * *

Уйлана табигать узган Җәй хакында,
и җәйге тупыллар шаулавы якында!
Төнге урманда таланган кыз сыман,
чал чәчле ападай, сеңелдәй үз сыман
ялангач көз тора тәрәзәм артында.
И җәйге тупыллар шаулавы якында!..

Көз берни сорамый, күкләргә ул баккан.
Әремнәр шаулатып, җил исә төньяктан...
Сагынулар күңелдән мөлдерәп түгелде.
Иң соңгы яфрактай җилкетеп күңелне,
ут-песнәк сикерә куакта!..
Әремнәр шаулатып исә җил төньяктан...

Кыштырдый көзге җил саргайган кыякта.
Көз берни сорамый, уйларга чумган ул.
Агыла офыкка болытлар олавы...
Шыгырдый тәгәрмәч, бу — көзнең елавы. —
Көз китәр төялеп үзе дә еракка!..
Кыштырдый көзге җил саргайган кыякта.

Көз берни сорамый, сораудан узган ул:
«бәгыренә боз каткан и күксел тугайның!..»
Бу узган Җәемне мин Сиңа охшатам,
бер янып, бер көеп, күңелемне бушатам:
«Син килеп чыгарсың, мөгаен...
Син килеп чыгарсың шикелле бер чаттан...
Әлегә боз каткан
бәгыренә
тугайның...»

*2002*

# Чыгыр

*(Этнографик циклга)*

## I

Гаҗәпләнмәс әле беркем,
Кем сөйли дип кем турында.
Вөҗдан белән сөйләшәмен,
Җавап бирәм ыруыма.

Аратаңда юк алашаң,
Ашлыгың юк ындырыңда...
Көчкә тотынып торасың
Буыннарың чылбырында!

Нәселемнең ир затларын
Сугыш йотты бит барын да...
Тегермән тартмый — канатсыз,
Орлык такыр амбарында!
(Эленеп тора сыңар канат
Буыннарым чылбырында!..)

Сарыга сарылган җиңги, —
Җырлыйм дисә, моңы беткән.
Кунасында камыр җәйми,
Җилпучында оны беткән...
Җете төсләрен җил алган,
Уңасылар уңып беткән...

Кузгалмый да тәрәш-каба, —
Эрлим дисә — йоны беткән.
Урак — кыршау, гармун — иске,
Күрегенең тыны беткән!

Оябызга ниләр булды,
Тузгыттымы шайтан-мәләк?
Әнкәй, сине оныткандыр
Аралыкта сырлы бәләк?

Әнкәй, синең уйларыңны
Аңласа, бары ул аңлар, —
Безнең гомерне шаулатып,
Агы беткән ак самавар!..

Матча өрлеге искергән:
«Он тарталар» кырмыскалар...
Карт тупылым тәсбих тарта:
«Гомерең калган бер мыскалга...»

Бер Ходайдан игелек сорап,
Сузылган кул-тармаклары:
«Оҗмахыңнан урын алсын
Бу нигезнең әрвахлары!..»

...Онытылган иске кое,
Чиләге юк чыгырында...
Әллә мин дә соңгы божра
Буыннарым чылбырында?!

## II

Булмый болай!.. Ничек итеп
Уятырга бу Нигезне?
Ауганнарын торгызабыз,
Җыелышып сиплибезме?..

Әйтерсең лә нидер көтә, —
Ишегалды тора тып-тын...
Януларын төштә күрә
Ягылмаган иске утын?..

Мин дә менәниләр көтәм,
Уй-киңәшчем юктыр бүтән?..
Ни әйтсен соң —
балта «ашап»
Гомер иткән
Иске Бүкән?!

Тормышны тергезим дисәң,
Карама гомер үткәнгә,
Иң беренче җиңең сызган,
Балтаңны чап, дим,
Бүкәнгә!

Морҗабыздан чыксын төтен,
Ут кабызыйм учагыма.
Шулчак узган безнең гомер
Кайтсын кабат
бу чагыма!

...Кайный казан,
Кайта гомер,
Төшә күмер
учагыма!..
Җанланамсың, Иске Нигез,
Килче, алыйм кочагыма!
Тәрәзәмне ачып куям, —
Җилләтәм мин сине,
Дөньям!..

*14 июнь, 2003*

# Ак Байталым

...Ак Байталым таугa менә иде,
Чыгышлыкның ерып ташларын...
Атым үргә менә, ә мин менә,
Менгән саен...
төшә
башладым!
Чытырдатып ялга ябышсам да, —
Ат сыртында гүя йомычка...
Койрыгыннан калган бер учма кыл,
Йодрыгымда калган бер учма!..
Уч төпләрен кискән бер учма кыл,
Егылыр булсаң, олан, булышма!

Күз алдымда уйнап кына тора
Байталымның ап-ак бәкәле!
Койрык буйлап
җиргә
шуып төштем.
И, бәхеткә...
Маңгаема... тояк ләкмәде!..

Тоягы да әллә акыллымы? —
Хет аркылы егыл юлына,
Ә ул сине ипләп атлап үтәр,
Җил тидермәс
Кеше улына!..
И пошкыра минем Ак Байталым,
Чыккан чакта еллар күперен!
Ул пошкыра — калка егылган гөл,
Тояк эзләрендә күпереп!

Ак Байталым һаман үргә менә,
Күзләрендә агыла ак болыт...
Балачагым шулай төшкә керә

Ак Байталлы
                туган як булып!..
Кызыл Китапларга кереп бара
Шул малкайлар, байтал кебекләр...
Шыгыр-шыгыр бара тәгәрмәчләр,
Арышларны буяп дегеткә!..
Ат күрмәгән димәс миңа Тормыш, —
Бер атланган идем, егетләр!

Мактаналмыйм, әйе, кулларымда
Тузганы юк җизле йөгәннәр.
Ныклап тотып Тормыш дилбегәсен,
Үргә таба этеп,
                үр төшкәндә
Булды җәяү-утырып йөргәннәр...
...Инде менә Шигъри Тулпарымда
Кайтып киләм гомерем утарына,
Күнми йөрәк арып туктарына, —
Кулда әле, шөкер,
                йөгәннәр!..

*2003*

## Песнәк

И Песнәгем, өзелеп сайрый, сайрый!..
Әйтерсең лә күк томаннар артында...
Әллә көмеш игәү белән нидер кайрый,
Сызгырына Химиклар паркында!..

Бер алхимик булдың инде, кошкай,
Яз ясады кыштан синең аваз!
Бик бирелеп шулай чакыра торгач,
Җәйләре дә аның килми калмас!

Бер шаман күк булды инде, ихлас,
Җилгә каршы кешнәп куйган сыман!
Әллә чакыра февраль салкыннарын,
Иң гүзәл бер аен җуйган сыман?!

Җирдә апрель, мае чират тора, —
Пыр-пыр оча, сайрап күңел ача!
Балконымнан кереп, гөлемә кунгач,
Минем кулга ләккән идең ләса!..

«Кош тоткандай булдым» гына түгел,
Учымда бит кошкай, сары йомгак!
И тырпылдый! И чукыган була...
Бер учымда гүя алар — унлап!..

Тиямме соң?! Сайравыңны тыңлыйм, —
Каян килгән яңгыравык тамак?
Ул авазы, җүләр! Учларыңнан
Көмеш суы булып җиргә таммак!..

Алтын или апрель бакчасында!
Сайраулары ялкын, чыңлый салмак...
Язгы дәрттән кабынып хәбәрләшә,
Чытырманны
Пайтәхеткә санап!
Балконымнан атылып кермәс, бәгырь,
Гомерлеккә бугай алды сабак!..

*Апрель, 2003*

## Ә Табигать яши...

Туган төбәк, көзге урман, сезне,
Соңлап булсын, сагынып кайттым мин!
Туйралыгың кайда, ләбентеләр,
Алтын кишәнкеләр?
Тапмыйм мин.

Ул Пүчинкә өсте — күксел рәшә,
Тәрбелиең нигә боеккан?..
Таулар сабыр, утырып чүгә таулар,
Сагыш тама
такта кыектан!..

Ә Табигать — яши...
Тау битендә йомран яшәп ята,
Бәбиләре әле сукырлар...
Оясыннан ак дөньяга чыккач,
Табигатькә
рәхмәт укырлар!..

Балачакның учак урыннары —
Кемнәр өчен —
иске чокырлар?!

Торналарның бер авазы өчен
Җаны белән түләр бу кырлар!..

Басу-кырлар — гамәл дәфтәредәй, —
Ни чәчкәнең чыга тишелеп!
Яши-яши нәфесе арта гына, —
Картаямы шулай
Кешелек?!
Бәхеткә дә батып үлә мокыт,
Дулкын булып килсә ишелеп!
Яңа токым шаулап үсә монда,
Яшәргәннәр күрше-күләннәр!..
Дәвам итә нәсел: орлыкларын
Күздән чәчеп кала
үләннәр!..
...Чалбарыңнан тез башларың чыккан,
И балачак, ниләр чәчәсең?..
Картлыкнымы?
Күптән ашадың шул
Яшьлегеңнең
соңгы
көлчәсен...
Инде хәзер,
Кайтып алтын чакка,
Минутыңда
еллар кичәсең!..
Ә Табигать... яши!
Нишләсен?!

*Июнь, 2003*

* * *

Сөрелгән кыр буйлап кайтып килеш,
Сиртмә Койрык* йөгерә алдымнан...
Эзләремне төрән каплаткандыр,
Шул елларны йөрәк сагынган!..

Юл өстемдә кемнәр утыра, дисәм,
Учак ягып, киенеп комачтан,
Төрән калаклары яна икән
Баешына барган Кояштан!..

Шул сукмактан яшьли киткән идем,
Зур дөньяга тәүге юл башлап,
Кайтып киләм бүген, бабай булып, —
Юллар, гомер — бергә тоташкан...
Ай өсләре кебек сөрелгән кыр,
Хатирәләр яна тоташтан!..

*2003*

* Сиртмә Койрык — кош.

# Күк вагоннарыдай еллар

Бар да уза…
Ян-якларга
кагылып кына,
күк дулкындай
агылып кына…
Бар да уза
янәшәдән,
яннан гына,
газиз җанга
кагылып кына!..
Очып,
йөзеп,
йөгереп үтә янәшәңнән, —
кул сузымы гына!..
Үзе белән алып,
талап, төяп китә, —
ә калганы…
Ни кызыгы гына?!
Күк вагоннарыдай еллар
очып үтә,
ераклашып якынлаша
Җан Сызыгына…
Бар да уза
ак болыттай
агылып кына,
агылып кына,
агылып… тына…

*Июнь, 2003*

# Түрә кулы

Гүяки без аның белән
Малын бүлешкән идек…
Кул биргәч, куйды искәртеп:
«Без бер күрешкән идек!..»

«Шулаймы, кайчан?
Арбадан
Мин яңа төштем генә.
Төшү белән, якташым, дип,
Килеп күрештем менә?!

Ялгышсам, гафу! Көненә
Кулны бер бирү тиеш!
Алайса, кире ал, кустым, —
Кайтарам…
тулы килеш!

Дөньяда күпме кул алып,
Әллә мин оныткан мы, —
Сездәй түрәләр…
бирәләр
Граммлап кына
аны!»

Тәкәббер генә сайлыйдыр
Кулларны Түрә кулы:
Баш иеп кулын биргәннәр
Әйтерсең аның колы!..
Түрә кулы салкын, саллы, —
Әйтерсең көрәк инде…
Миңа, кустым, электәге
Үз кулың кирәк иде…
Шатлыгым артты шуңа да,
Дөньямны «бәхет басты»!..

Тик моннан соң
бирмә кулың,
Кисмә юлым,
албасты!..

*21 июль, 2003*

## Көзге җыр

Тоткарлыйсы иде Көзне,
көз шул кузгалган инде...
Аерып та булмас безне:
син бит күзалмам инде лә,
син бит күзалмам инде!..
Бәгыремне бер сүз өзде:
«Синсез түзалмам инде лә,
синсез түзалмам инде!..»
Көзләр куенына сеңеп,
мин сине яраттым ла!..
Шул сүзләрем очты кебек
кыр казы канатында шул,
кыр казы канатында...
Булмас инде һичбер чаклар
безнең ул чаклар сыман!
Кызыл-комач бу яфраклар
көзге учаклар сыман ла,
көзге учаклар сыман!..
Сине миннән көзләр алыр,
ятлар кочаклар сыман, аһ,
ятлар кочаклар сыман!..
Көз каршында берьялгызым
дөрлим учаклар сыман ла,
дөрлим учаклар сыман!..
Сезнең якларга очалмыйм...
инде ул яклар... томан...

*5 октябрь, 2003*

# *Тере Поэма*

Бер поэмам Синдә яши минем,
Шул поэмам ия тылсымга…
Табындым мин тере Поэмага,
Шул поэмам
            Синдә булсынга!..
Югары ул гади мәхәббәттән,
Һәм соңлаган гыйшык-гашрәдән…
Төче мактаулардан,
            татлы сүздән,
Юхалыктан, юк-бар нәрсәдән!..

Мин кәгазьгә төшерә алмыйм утны, —
Талантыңнан кабыныр ялкыны…
Соңлап килгән илһам,
            соңгы күкрәү,
Соңгы Поэмамдай балкыдың —
Чәч дулкының ташлап иңнәреңә,
Узып киттең…
            йөрәк аркылы!..
Төнлегемдә йолдыз сакта хәзер,
Баш очымда… тып-тын фәрештәм…
Бер Поэмам Синдә кала минем,
Яшәп йөри…
            Синең
                  рәвештә!..

*Сентябрь, 2003*

## Биектә

Көньягында булган иде бу хәл,
Уйлап куям бүген аптырап:
Бәхәсләшеп
кыя-таугa мендем...
Түбәсендә торам «ялтырап!..»

Аһ, түбәндә миңа төбәлгәннәр
Авыз ачып, ярым калтырап!..
Эһ тә итми карап тора куркып...
Ак болытлар тынган түбәмдә.
Аваз салсам, —
җиргә барып җитмәс,
Таш
озаклап
оча
түбәнгә!..

Таш ярыла, очып тузан була,
җилләр сынаганы,
сирәге...
Ташланырга моннан ничек түзә
Ярылмыйча кошлар йөрәге?!

Шул упкынга очты гүя йөрәк, —
Аяк асларымнан
таш
очты!
Упкын төпләрендә аһ! иттеләр, —
Кемнәргәдер...
минем
баш очты!
Мендең икән,
кара гел биеккә! —
Аска карау хәтта куркыныч...

Синең изгелектән канат ярам, —
Теләктәшем,
          җирдә
                    бул тыныч!..
Теләктәшләр, рәхмәт, ышандыгыз,
Сезнең теләк илтте югары…
Болытларга башың тияр өчен
Бер җылы сүз
          җиткән
                    нибары!..

*Сентябрь, 2003*

## *Сонет*

*Л…гә*

Шаһит булып торсын Төнге Сирень —
Төнге вокзалларда түгел,
Диңгез ярларын да көтми күңел,
Җанны баскан йөкне бушатыйк та,
Бер яшьлектә кебек, бер картлыкта
Йөрәгеңдә очрашыйк без Синең,
Шаһит булып торсын Төнге Сирень!..

Күңелнең бер аулак почмагында,
Сыенып хатирәләр кочагына,
Кайтыйк әле Язның шул чагына, —
Утырыйк бер. Үкенеч калмасын…
Яшәрсеннәр, яңарсыннар еллар,
Бу мизгелне, шатлыгыннан елап,
Һәм, алкышлап, Сирень шауласын!..

*Сентябрь, 2003*

## *Яу башы*

*(Сәргаскәр)*

...Сурәтләрен кемнәр ясамады,
Нинди позаларда төшмәде!..
Гаскәр итеп янда дуслар йөртте,
Суда батып,
утта пешмәде!..

Һәр кыяга исемен яздырды ул
Җиңеп барган җайга.
Дан йолдызын муенына элде,
Бер нөсхәсен — Айга!..

«Гомеремнең бер мыскалын да
Бирмәм үкенечкә,
Кыялар баш иеп сынар
Безнең гайрәт-көчкә!..» —

Дигән кеше...
как сәкедә...
Сулап ята... көчкә...
Аяк чолгауларын...
Байрак итеп
Күрә инде...
төштә!..

*Август, 2003*

## *Авылыма*

**1**

...Төн пәрдәсен тартты салкынча җил,
Күкләр тулып йолдыз кабынды.
Әйтерсең лә Космос шәһәрендә —
Кич җитүгә,
утлар алынды!..

Кинәт шунда искә төштең, авылым,
Үр астында таныш йортларың...
Урман авызыннан үзенә дәшеп,
Тонык кына алда җемелдәшеп
Ерак калган...
якын утларың!..

**2**

Кыйтгаларны ничек якынайтыйм, —
Дүрт кул түгел миндә,
бер йөрәк...
Гомерен дә әйтим: ашыгып уза,
Узган саен
йөгерәдер тизрәк...
Бәхет эзләп синнән киткән идем,
Җилләр җигеп килеп ал әле...
Йөрәгемне барыбер алып китмәм, —
Кичералсаң,
алып
кал әле!..

*Октябрь, 2003*

## *Сихри моңнар*

*(Арфа)*

Авылым кырларында ишеттем мин
Иң беренче моңын арфаның:
Арыш сабакларын чиртте җилләр,
Чеңләделәр
Көмеш кылларында арпаның!

Басуларда диңгез шаулагандай,
Шул дулкыннар кушылып дулкынга...
Торна кузаклары шартладылар,
Түзалмыйча
сихри шул моңга!..

*8 октябрь, 2003*

## *Әманәт*

*(Шаяру катыш)*

Балык Бистәсенең бер тупылын
Тамгалаган идем гомергә!
Ул тупылны, корып, кискәннәрме
Йә калгандыр, бәгырь, күмергә!..

Җил мәңгелек фани бу дөньяда
Кем тупылны уйлап маташа?
Җил-сайтка язам әманәтне,
Кампитрга бирсен — хат аша.

Җилгә язам, җил-тасмага язам,
Калмасын тик талга бәйләнеп…
Яратуым ишеттерсен сезгә, —
Йөз еллардан
кабат әйләнеп!..

*Сентябрь, 2003*

## Үлемсез Чебен

Бер тамгалы Чебен оча миндә,
Комачаулап
шигырь язганда.
Ничәнче кат инде сугылды Ул,
Кыш кышлады...
Ашка төште,
пеште... казанда!..
Кашык белән элеп аттык үзен...
Кагынды да...
оча һаман да!
Ни гаҗәп бу: халык кырылып ята
Чебен үлмәс
бөек заманда?!
Гөлдән гөлгә куна үлмәс Чебен, —
Йолдыз инде!
Бал кортлары...
колдай
бал ташый...
Ә бу... Яши!
Тик безелди белә,
Оча-куна,
бал да май ашый!..
...Бусагада — кыш! дип ут йотабыз...
Ни хәсрәте моның,
ни уе?!
Шагыйрь дустым,
шушы түгел микән
Без эзләгән
Заман Герое?!

*22 октябрь, 2003*

## Кинэ

Аймы, синме төнге тәрәзәмдә, —
Уйларымнан, ахры, уелам?..
Яндым синең кайнар утларыңда...
Янулардан инде тыелам...
Таш иркәли хәзер:
Аркам туңса,
туңган саен,
ташка сыенам!..

## Шигърият

Халыкларның күңел очышларын
Сыйдырган ул тирән Шигърият.
Күңел океаннары ургый анда,
Максат итеп куйган
зур ният!

Кызыктырып чакыра сайрар кошлар,
Ахыр-чиксез кара урман күк...
Баш-аягың белән суырып ала,
Йота сине...
буар елан күк!..

*2003*

## Шагыйрьләр

Шагыйрь булып кылтайдыкмы,
юк-бар даннан купайдык,
иртәрәкме муртайдык?..
Дөрес түгел әмма: безнең
байлык түгел бер айлык! —
Тукайдан калган әманәт,
Тукайдан калган байлык...
Бу да байлык — чалымнарда
Булса бераз...
Тукайлык!..

## Суда үскән гөл

Бил тиңентен торам суларда,
И, болыннар җитми суларга!

Кемнәр, кайчан моннан алырлар,
Җирне тоймый үсә тамырлар?!

Чын яшәүгә әле еракмы? —
Төшләремдә күрәм... туфракны!..

# *Яшьлек парахуты*

...Кама яры. Төнге пристаньда
Ай яктысы әле...
Беләгемдә ята минем
Марҗа кызы... Валя.

Парахут әле килмәгән,
Ә төн... узып бара...
Беләктә — кыз,
                    йөрәктә — ут, —
Янмый түзеп кара!..

Кирәкмәгән чакта янга
Айны нигә дәштек?
Ике җанда бергә тибә
Йөрәк тулы яшьлек!..

Күкрәгемдә, и сулкылдап,
Һаман дөрли уты!..
Көттермәде,
                    бик тиз китте.
Яшьлек парахуты!..

Ул төннән соң инде калыккандыр
Меңләп таң йолдызы...
Кая киттең, кая, хыянәтче
Яшьлек —
                    марҗа кызы?!

*Август, 2003*

# Татар бугазы

Татар бугазында
яңа циклон өлгерә…

*Радиолар*

…Бәхет дигән изге тәгамнең ул
Олы итеп алды бик азын да…
Барын йотты эчкә…
Йотты көчкә…
Нәмә булмас
Татар бугазында?!

Безгә ишелеп килгән газапларның
Йота алмас алар
бик азын да…
Утлар йоттык,
уттан янып чыктык…
кычкырылмаган
төер калды
татар бугазында.
Йотылмый да шуннан,
сытылмый да,
тора һаман…
татар бугазында!
Империя бездән кол ясады,
Ютәлләдек тынчу Ил базында…
Янартаудай атылыр Хаклык сүзе
бер шеш кебек…
татар бугазында!..
Татар җаны, ап-ак җилкән булып,
Йөзә һаман Өмет кыйбласына;
Туып килә яңа циклон булып —
Кайнап тора аның
бугазында.
Сабырлыгы
җиткән
бугазына!..

*Декабрь, 2003*

## *Нух көймәсе*

*(Экспрессия)*

...Ярсыз дәрья булып ташты туфан,
— Коткар! — диеп үтенә бар да Нухтан...
— Алчы безне, зинһар, көймәңә! — дип...
— Болай да бит кырын төялә бик!..
— Кырын төяү килә харам малдан,
Без харамнар түгел, килдек алдан...
Кем утырмак була блат белән,
Муенын чапчы шуның булат белән!
Тормышта да булды алар алда,
Яшәделәр хәрам ашап, алдап...
Үрчеде ул кауме олигарх, —
Дума тулган иде, булдык гарык!..
Дәүләт башында да — алар иде,
Без фәкыйрьне алар алдар иде!..
Коткармады, упкыннарда калды —
Комсызланып җыйган дөнья малы!..
Мутант кавем азды җырлап-биеп,
Җиз быргылар өреп, утлар чөеп...
Күрдек кемнең канга каныкканын!
Көтте Хаклык туфан калыкканын...
Килде менә Бөек Хисап Көне,
Бер әлфирак, мең әлмисак төне!..
— Хак пәйгамбәр, калсаңчы коткарып!
— И инсаннар, көймәм мисле ярык...
...Дәрья төпләренә этәдер җил,
И гөнаһлы инсан, и бозык Ил,
Соң булса да, барыбер тәүбәңә кил!
Яшәү көткәндә дә — тәүбәңә кил,
Төпкә киткәндә дә — тәүбәңә кил!..

*2003*

## *Бу кышта...*

Карлар Җирне ак юргандай япты,
Туң туфракны гүя кызганып...
Карлар килгән күк түренә чаклы,
Җир очкандай булды кузгалып!

Әрәмәне көмеш ука сарды,
Атылып төште былбыл атлы кош...
Тауларына ак чыбылдык тартып,
Үзәннәргә төшеп ятты кыш...

Ныклы ятты, тормас Язга чаклы, —
Ак җилләре йөгерер йомышка...
Бер төнендә... Яңа елын тапты,
Фатихасын биреп Тормышка!..

Агыйнешем тәрәзәсен япты,
Кызлар уйган ай-бәкеләр катты,
Ай... күгенә батты... бу кышта...
Ак ялкыны капты сулышка!..

*11 декабрь, 2003*

## Өмет

Өмет белән таңда уянасың,—
Хыялларга киңлек
                    тар кебек.
Килә, килә... килеп җитәр менә! —
Тау артында бәхетең бар кебек,—
Үзе... яшьлек, сөйгән яр кебек!..

Ак сөт тулышып торган күкрәк сыман
Болытларда өмет бар кебек...
Ә чынлыкта...
                    ап-ак ул өметләр...
Сабый өргән куык-шар кебек,
Юеш җиргә
            төшкән
                    кар кебек!..

*12 декабрь, 2003*

## Инкыйраз

Ауган диварлар астында калды,
Шәһре Казан утларында янды
Ыруымнан килгән зур мирас...
Милләтемнең тамырына төште,
Мәгъриблрдән кыргый җилләр исте,
Язмышларны кисте инкыйраз.
Булсаң да син, халкым, Хаклык колы,
Синең юлың — киек кошлар юлы,
Синең Тарих — тоташ инкыйраз!..

*11 гыйнвар, 2003*

## *Шәрык шагыйрьләренә тәкълид*

Җитәрменме максатыма,
                    эчтән сыктап яна күңел:
Алда меңләп көмеш чишмә — хөр кизләүләр, —
Барысы да бер эчелгән — яңа түгел.
Алда күпме юллар ята — юл өстенә юл эзләүләр, —
Барысы да бер кичелгән — яңа түгел!..

*11 гыйнвар, 2003*

# *ТӨРЛЕ ЕЛЛАР*



* * *

— Бүләгем! — дип,
                    миңа гөләп суздың,
— Сау бул! — диеп, серле елмайдың.
Ак җилкәнең күмгән томан аша
Елмаюың күреп моңайдым...

Авыр сулап диңгез ыргый иде,
Сине күреп ул да басылды:
Синең белән ул бәхетле инде,—
Кырыс йөзе көлеп ачылды!

Каршыларсың ерак дулкыннарда
Сөю белән тулы иртәңне...
Җилфердәтә бара диңгез җиле
Хыялымдай
        ерак
            җилкәнне!..

*Гурзуф*
*1957*

* * *

Болытлар суда йөзә,
Күл буен баскан камыш...
Күңелдә — сагыну-сагыш...
Җуелмас өмет исә
Ерак шатлыгын сизә,
Болытлар суда йөзә...
Алланды шәфәкъ тагын,
Кичке җил шаулый талгын,
Талгын, ямансу булып.
Судагы алсу болыт —
Яулыгы сыман аның...
Алланды шәфәкъ тагын!..

*Әстерхан*
*1959*

## *Кыз хаты*

Син кайтмаска киттең Иделеңә, —
Сагынгандыр анда бер сылу?..
Алып киттең ак шомыртлы язны,
Йөрәгемдә калды борчылу!..

Идел ерак, беләм, күренми ул
Даугавадан...
Офык күгелҗем...
Күзләремдә тулы сагынуларым
Ярларыңа барып түгелсен!..

Җил йоклатмый мине туган якта,
Күзләремдә яна офыклар...
Кем өчен соң алма коела шаулап,
Кем өчен соң
сыгыла
шомыртлар?!

*Балдоне*

*1963*

* * *

Ымладың да миңа, үзең качтың,
Тик белмәдем киткән ягыңны.
Йокым качты, ялгыз газапланып,
Җилләр белән бүлешеп кайгымны!

Тәрәзәмә көлеп чиртә яңгыр,
Җил үчекләп төнгә сыена.
Гөрләвекләр янып сөюемнән
Шаркылдавың булып тоела!..

Кемне тагын анда «кызгандың» син,
Кем язмышы өчен «сызландың»?..
Кемнәр белән анда тап саласың
Антларына
безнең
узганның?!

*1958*

* * *

Ерак җирләр, якты дулкын, зәңгәр агым сулкылдый.
Җылы җилләр — минем холкым, сине сагынып уфылдый.

Сүндер әле утларыңны, юл куйма аһ-зарларга.
Синең утлар чакыра мине: «Кайт,— дип,— рәхәт ярларга!»

Томан сарган ул ярларны — кайтмам дулкын тынмыйча,
Синнән алган яраларны дулкыннарда юмыйча!

*1960*

## Көзге диалог

Көз капкага сары тубын кертте.
Эндәшмибез.
Карашларда — сорау.

Соңгы тапкыр
бөкләп утырасың
ак тезләрең
яшел үләндә.

Елмаясың.
Күзләр серле карый:
«Нәрсә көтә миннән
бу бәндә?»

Синең күзләр — алар сүзсез сүзләр,
каеннарга борыла оялып...
Алкышлана яфрак шавы белән
безнең сүзсез көзге диалог.

— Гашыйкларга нәрсә кирәк?
— Бер пар кул.
Аулак урыннар,
көзге теплоходлар,
                    парклар,
халык ташлап киткән утыргычлар.
— Җәй вакытлы,
барын алып кал.
— Утызынчы көзең.
Син — оясыз.

Парк шаулап көзне озата.
Чал өрәңге кая чыгып киткән? —

Уч-уч булып
сары эз ята.
Парк китә кышка. Озын юлга.
Ак пар каен утыра көзге уйда.

Куллар кулда безнең,
куллар кулда…

Без — кешеләр.
Без — җәяүле кошлар.
Алда — эшләр безнең.
Алда — кышлар…

*1966*

## Шәһәр язы

Ул,
таулар, үзәннәр үтеп,
Иделне кичте эңгердә.
Аннан
сокланып озак карап торды
йокылы шәһәргә…

Бу — Яз иде.
Әле йоклый иде сабыйлар тәгәрәшеп
бишекләрдә,
эленмәгән иде чөнки ишекләргә
белдерүләр:
«Гражданнар,
бүген
төнге икедә
шәһәргә Яз керә!»

...Ишек төбендә
нәфис туфлиләр белән
кирза итекләр йоклый.
Капрон яулык өстенә
киң каеш салынган.

Бөтен этажларда — йокы...

Сөт елгасы сыман,
таң чайкалып ага урамнардан...
Тупыл кәүсәсенә кемдер
йөрәк уйган.

Ә ул бүртеп зурайган...

Шәһәр түренә узды Яз.
Тәрәзәдән Буратино карап калды көлеп.
Уенчыклар кибетендә,
Язны күреп,
курчаклар көлештеләр
чырык-чырык!

Пыялага төшкән
таң зәңгәре аша
җитен чәчле таш сылулар елмайдылар
язгы витриналарда.

Витриналарда — диңгез мәрҗәннәре,
хрусталь бөҗәкләр,
иннекләрнең төрле сорты,
кызыл читекләр...
(Бар да — кызлар хыялы!)

Ничаклы яңалык:
«Гашыйклар паркы»,

«Мәхәббәт мәйданы»,
«Бәхет туктальшы»...
Бар да әзер.
Инде хәзер
башларга да була
Язны!..

Тупылларның нәзек кылларына
җилләр сызды!..
Башланды
шәһәр читендә
язгы тамчылар
капелласы!

Бүген
шәһәр читендә
бер бик дәртле песнәк
бар дөньяга: «Яз килә!» — дип
чыркылдаудан
курыкмады.

*1972*

## Фотограф белән сөйләшү

*Нацистлар җинаятен «мәңгеләштергән» фоторәсемнәрне карагач*

Чал генерал көлеп тәре тага
япь-яшь штурмфюрер түшенә:
— Зер гуд, зер гуд, майн штурмфюрер, —
үтерү фәнен белә бишлегә!
Фотограф, яхшы чыккан рәсем!
Талантлы син, әйбәт төшергән!
Мундирлар да, килеш-килбәтләр дә...
әйбәт сурәт, бара — бишлегә!
Алар «эшләсеннәр»! Ә син — төшер
төрле позаларда аларны:
бармагында роза тотсын алар,
перчатка һәм... балта — аннары!
Күңеле үсеп, кара кнопкага
үрелсен ул, шушы чакта син
төшереп кара инде:
соңгы кабат
уран эшләр
«бөек» фотосын!..
Менә сиңа —
атом фотограф
алып калган соңгы кадрлар:
бер секундлык уран чаткысында
тормыш негативы чагылган.
Тукта, Тормыш,
тукта бер мизгелгә.
Бер секундка әгәр туктасаң, —
мәңгелеккә шуннан!..
Ләкин кемне гаепләрсең
яхшы чыкмаса?
...Бөреләр туктап кала — ярты юлда,

кыр казлары болыт астында асылынып кала,
канатлары — төрле тәртиптә;
кояш туктап кала тонык шардай
һәм кызара!..
Ачык ишектән
аякларның берсе — тышка атлый,
икенчесе инде — кичеккән...
Бер-берсенә сузылып ике нык кул,
күрешергә генә дигәндә,
туктап кала. Шунда юлын чикли
үсүеннән япь-яшь үләннәр!
Туктап кала Тизлек:
атылган туп
һәм... ташбака!..
Маятниклар туктый,
аяклар, —
барында да бер үк «тизлек» хәзер,
юнәлешләр генә — як-якка!..
Ниндидер бер малай типкән күн туп
тәрәзәмдә, кара кояштай,
эленеп тора инде ничә ел!..
Җиргә килә иде көмеш яңгыр,
аерылып зәңгәр болыттан, —
асылынып тора чук шикелле,
авырлыгын гүя онытткан!..

Болыт белән җир күрешми кала...
ничәнче ел сусый Җир-Ана,
ничәнче ел инде җир яна!
...Болыннарда гөлләр тибри иде
искән җилдә; яңгыр алдыннан
төклетура өенә ашыга иде.
(Ал гөлләрнең алтын тузанына
баткан, үзе күпме кагынган!..)
Тик бер секунд әфсенләнде гүя:
ничә еллар нокта төсендә

ул шул якка карап оча,
оча! —
Эленеп тора
болын өстендә!..
...Сабый кулы сузылып тынып калган:
ничәнче ел инде һаман да
ул әнисе сузган алманы
алалмыйча йөди! Ә ана
шатландыра алмый баласын, —
бирә алмый аңа алмасын...
Фотографлар!
Төшерегез җирнең портретын,
зәңгәр портретын — югартын!
Төшерегез — анфас, профильгә.
Төшерегез уйчан, елмайтып!..
Төшерегез барысын,
калсын, калсын истәлеккә,
атом төймәсенә басканны да онытмагыз! —
Тормыш фонында
шул кулларның хуҗасын да
төшерегез, —
баш тартмаслык булсын соңыннан!..
Төшерегез,
объективка
туры каратып,
кулы белән күзен капламасын, —
төшерегез
Тарих каршында!

*1966*

## *Күктән репортаж*

*(Кояш блокноты)*

Очабыз, җитте!
Алыгыз трапны
кояштан!

Моторларны сынап карап иң башта,
бетон юлдан җилгә каршы йөгердек.
Артка таба туры сызык булып
　　　　　　　　акты бар да...

Аннан,
тыгыз һава кагылды да канатларга,
култыклады ике яктан
һәм күтәрде!
Җир, булышып, этеп җибәрде чак кына...

Күтәрелдек кояш этажына!
Курсны алабыз — канатларны кыйгачлап кына.
Хушыгыз, тәгәрмәчләр,
　　　　　　　　шассилар,
　　　　　　　　　　　　кассалар!
Хуш, өстәл, каләм,
　　　　　　　　квитанцияләр —
　　　　　　　　　　　　барчагыз!
Хушыгыз,
мине тәүлек буена тарткан корымлы шайтаннар,
товар вагоннары,
самокатлар!..
Хуш, домуправ,
берничә сәгать кенә булса да
мин һава гражданины:
минем пропискам — болытлардан өстә.

Кояш — минем яңа күршем, якты күршем.
Юк, бу фантазия түгел инде.
(Тик бирелдем бугай әзрәк хискә...)
Ышанмасаң,
тот болытны ап-ак сакалыннан, сөйрә...
Без очабыз, әйе. Җиргә бәйсез.
Сезгә бәйсез,
җир кортлары, әй, сез!..

Без бәрәбез турыдан! Таулар ярып,
чәч юлыдай ачып урманнарын...
Күк юлы бар.
Тик ул җирдән уза
монда да. Җир,
синең чакыруларың.
Канатларны бераз кыйгачлатып,
кояшлырак якка юнәләбез.

Арттан калмый, «эт кояшы» сыман,
кырлар буйлап чаба күләгәбез...
Кичер, һава, синең үз кануның,
тигезрәк тот безнең канатларны.
Биеклектә
бер уйласын бәндәң
җирдә алган кайбер
сабакларны!..

*1972*

## Кышкы бакча

Кар астында
зәңгәр гөлләр йоклый,
апрель йоклый татлы йокыда.
Ак куаклар суза яшь яфрагын
төшләрендә
кояш утына!

Кышкы бакча минем күңелем кебек:
шатлык та бар анда, сагыш та;
салкынча да, бәйрәмчә дә үзе, —
бар да сыйган безнең язмышка.

Син йоклама, күңел,
жыен язга,
карамачы шәрә тирәккә,
каршына бар Язның, —
тугыз баллы
давыллы жыр орсын
йөрәккә!..

Кар астында утлы гөлләр йоклый,
апрель йоклый зәңгәр йокыда.
Ак куаклар суза яшь яфрагын
төшләрендә
Кояш
утына!..

*1966*

## *Галәм хисапчысы*

*(Яңа йортка күчү)*

Иң беренче булып Сәгать керде,
Вакыт керде безнең бусагадан.
Телен бордык. Вакыт йөреп китте!
Үз исәбен башлап өр-яңадан.

Сәгать... атлап китте... Хәерле юл!
Ул керешге төгәл үз эшенә.
Галәм хисапчысы! Синнән нинди
Көмеш тияр минем өлешемә?..

Кайчагында Җирне онытсаң да,
Җир сәгате, сине онытмадым.
Галәм хисапчысы! Санап бирче,
Күпме синең яхшы минутларың,
Күпме синең алтын минутларың?!

Ике угың, ике гашыйк сыман,
Берсен-берсе һаман табышып торсын,
Сәгать саен икәү кавышып торсын;
Ике угың икесе бер-бер артлы
Бәхет ягына һаман авышып торсын!

Минутларны уклар сәгать итсен,
Кирәк икән — берсен унга ярсын.
Үз юлында, сәгать укларыдай,
Эшләребез һаман уңга барсын!..

Вакыт — безнең кулда. Алып кердек
Иптәш итеп, Сәгать, бары сине...

Тик бәхетле парлар гына ясый
Телләреңнән
Бәхет каруселе!

Фәкать алар әмере белән бит син
Бәхет Сәгатенә әйләнәсең...
«Тормыш түгәрәк!» — дип,
ике угың
Чабып йөри
Кояш әйләнәсен!..

*1964*

* * *

Алып чыктыңмы син Яңа елга
күкрәгеңә мине яшереп?
Бусагада әллә калдырдыңмы,
яңа тойгы белән мәш килеп?..
Ә шулай да карлар — синең бүләк,
бөтерелә ап-ак бәхет теләп.
Тәрәзәгә кунган ал төсләр —
сәламеңдәй килгән балкышлар!..
Котлыйм синең аккош мамыгы яуган
балкыш төсле зәңгәр кичеңне.
Йолдызларга йолдыз чәкәштереп,
күтәрәм мин синең исемне!

*1974*

* * *

Әйтерсең мәңге бу җирдә
тын зәңгәр көннәр генә...
Җил галәм үзәннәрендә
шаяра гөлләр белән...

Кошларның кичке көтүе,
кыйгачлап шәфәкъ ягын,
әйләнә дә эңгерлеккә
югала кереп тагын...

Күтәрелә төн эченнән
Мәңгелек тавышлары:
кемнәрнең бәхеттән елап
йә көлеп кавышканы!..

Үткән сагыштан, тып! итеп,
яшь тама мендәремә...
Әйтерсең язгы бу җирдә
бәхетле өннәр генә...

Йолдызлар күз кыса гүя,
галәмгә илткән юлдан:
Хыял утларының гигант
Идарә пульты
сыман!..

*1972*

* * *

Тирәкләрдән,
җилдә бөтерелеп,
сары кошлар
төшә
инешкә...
Аланнарда комач флагчыклар,
күтәрде Көз соңгы финишка!
...Ә кайдадыр
җырлый Төклетура,
җырлап кайта, батып гөлләрнең
Алтын тузанына!..
Ширбәт эчеп,
ул исәбен җуйган көннәрнең...
гизеп йөри көзге болыннарда,
сентябрьгә калган тавышы;
август аны ташлаган да киткән,
Кояш бара кичкә авышып...
Өметләре аның — үзеннән зур:
Алтын Сарай салыр кәраздән!
...Гомер узган...
Җиргә әңгер төшкән.
Мин
башымны алдым
кәгазьдән...

*1974*

* * *

Карамачы шулай күзләремә,
карагандай кара торбадан...
Югалттым да сине, озак бардым,
исемеңне сорап еллардан!

Карамачы, миндә нинди гаеп? —
мин һаман да шул ук, шул һаман.
Шөкер, безнең уртак ул язларны
саклап кала алдым еллардан!

Күзләреңне төбәп син елларга
кара шулай. Сора еллардан!
Ерак калган инде сарутларның
кочагына ауган тын алан!..

Эзләмә син минем күзләремнән
яшьлегеңне! Сиңа кайтаралмам...
«Мин — һаман шул!» сүзен аңла шулай:
синең өчен мин, дип, шул һаман!

Карамачы, төбәп җаным төбенә, —
мин ташмыни?
Әмма ярылырмын күк
йөрәгемне кыскан моңнардан!

Карамачы, сискәнмичә очсын
күзләремдә ап-ак торналар!..

*1974*

# *Мәхәббәтнең соңы*

*(Монолог)*

«Гомерлеккә син — минеке!» — дигән идең,
хәтереңдәме?
Инде сиңа шушы хакта
тау артыннан әйтергәме?
Инде бүген
үткән-сүткән укып китә —
белдерү бар урам тактасында:
«Бүленешәбез. Кирәк безгә
аерым-аерым ике бүлмә.
Аерым булса, үзем риза барысына...»

Безнең оя насыйп булыр икән кемгә:
бер бүлмәсе — ундүрт адым (буш бүлмәдә,
читлектәге җәнлек кебек, көн дә
арлы-бирле йөреп үлчәдем мин ялгыз),
суы ага, уты яна — җылытмый җанны...
(Һич югында, хатирәләр утын кабыз!)

Ак диварда — экрандагы сыман —
гел үткән көннәр...
Көне кыска, төне озын — һич атмый таңы!
Йөреп тора ике чыгыр ике якта —
яшьлек вагоннары тавышы колакта!
Бөтен шарты килгән: йөрисе юк тышка,
утын ягасы юк кышка,
чүпләрен дә түгәсе юк еракка.
(Ә без генә юк-бар сүзне
чыгардык шул тышка!)
Элек ничек серле идек!
Яшерә идек,
горур идек җиде ят каршында.

Дустым,
шундый көнгә калдык:
безнең уртак язмыш
эленеп тора инде
Каргыш тактасында!

Яңгырларда, карда
бар галәм каршында
җилферди! Елый! Чакыра!
Хәзер инде безнең тик бер максат:
икебезгә аерым-аерым ике бүлмә...

Ике йөрәк,
бер-беренә сыенып,
баралмады Кыш каршына бергә...
«Ике җирдән —
аерым-аерым ике бүлмә...»
Гомер бакый —
Икебез
барып кергәнгә чаклы
аерым-аерым
ике гүргә!..
...Инангандай
уртак ул көннәрнең
мәңгелеккә инде кайтмасына,
кадаклап куйдылар безне...
Үкенечләр тактасына.

Чат башына!..

*1985*

* * *

Бу төбәктә, бу төбәктә бары
Шат көннәрнең тәүге авазы.
Юлларыма бурап яуган кары,
Уйларыма биек һавасы!

Тыңлап туялмаслык әкиятләре,
Чишмәләре ургый таш ярып;
Буыннарның гореф-гадәтләре
Бу төбәктән китә башланып.

Бу төбәктә безгә дигәннәре
Тора балкып кояш утыннан.
Шаулый җилдә татар имәннәре,
Шаулый илдә якташ тупыллар!..

Көрәш шавы тулы заманнарда
Шунда туып гомер кичелгән;
Язмышыбыз шунда ялганган да
Кендегебез шунда киселгән.

*1984*

* * *

Чал иmәннәр яфрак коя,
гүя
җәйге диңгез шаулый еракларда.
Көзге җилдә
алтын сандугачлар
очып киткән төсле
куаклардан.

Җәйге моңнар әле эзләп йөри,
үз сукмагын даулап, үткән юлын.
Кемне сагынып, синдә
тып-тын үкси
яшь көннәрем минем, яшел болын?

Кемне сагына болын уртасында,
гөлләр арасында балачагым?
Белмәгән ул,
аерылып миннән,
болыннарда
аунап
калачагын!..

*1985*

* * *

Кама өсләрендә күк күкрәде,
сөю антын Җиргә биргәндәй.
Агачларны җилләр барлап йөрде:
«Исәннәрме бар да?» — дигәндәй.

Агачларны җилләр барлап йөрде,
мин барладым Сине йөрәктә.
Аһ, бу чакны җылы кулларыңның
кирәклеген тойдым
бигрәк тә!
Бу якларда җилләр — сагыну җыры,
исмәс иде сиңа кирәктә...

Кама өсләрендә яшен яшьни,
күкрәүләре —
минем йөрәктә!

*1958*

## Гипербола

Уйладык та, Тормыш юлларында
бергә куштык ике гомерне.
Моны безгә күкләр үзе әйтте,
моны безгә күкләр иңдерде!

Шуннан бирле уртак безнең җаннар,
пар канатлар бездә, пар йөрәк.
Бу җиһанда тиңдәш пар булырга
бөҗәккә дә хәтта яр кирәк.

Аерып булмас безне. (Археологлар,
бәлки, безне бергә табарлар?)
Гоби чүлендә дә, бер-беренә ябышып,
ташка әйләнгән динозаврлар!

*1984*

* * *

Син — бер океан!
Бөтен күңел тармакларым
сиңа коя!
Синең дөнья!
Анда тик мин генә тойган,
минем йөрәк кенә сизгән
тектоник тетрәүләр,
яшеренеп ята бусагалар,
рифлар —
чәлпәрәмә килер күңел көймәң!..

Тик бар аның сәгадәтле бер чагы! —
Нинди ел фасылы булсын: көздәме,
булса булсын
кышның зәмһәрир чагы —
ике зәңгәр яз карый сиңа балкып:
шартлый бөре,
ачыла...
шигырь
яфрагы!
Китә бозлар ерак зәңгәрлеккә...

Тоела миңа:
шул караштан хәтта туң мамонт
аягына басар иде,
үлән өзеп йөри башлар иде,
мәңгелектән уянып!..

Карашыннан күгәрченнәр
тәгәрәп үлгән,
скептиклар миңа шул чакны
юктыр сыман тоела язгы җирдә.
Ак җилкәндәй җәеп кочакны,
очам,
йөзәм,
яшим куанып!..

*1972*

## *Исем кушу*

Кем дип исем кушарга, дип,
барысы да баш вата...
...Олы дөнья каршысында
исемсез бала ята...

Аласын алыр бу олан,
күрәсен күрер әле.
Аласын алып, бу дөнья
кирәген бирер әле!

Ә хәзергә... исем кирәк,
бирегез аңа исем.
Матурын сайлап кушыгыз, —
Исеме кадерен белсен!

Әле аңа исем кирәк, —
кем дип исем кушарга?
Теләр микән ошбу җисем
исеменә охшарга?..

Кем булыр ул: космонавтмы
йә шагыйрьме, булмаса?
(Кирәкми лә! Әтисе дә
урта кул шигырь яза!..)

Корыч койсын, җир казысын,
тау җимереп, таш ярсын.
Яшәү мәгънәсен эзләсен,
хаклык эзләп баш ярсын.

Каш ясыйм дип, күз чыгарып
яшәмәсен дөньяда,
үзеннән зур сүз чыгарып
кеше корган ояда!

Юллар аңа әзер — чапсын,
Һималай күк — бусага!
Дөреслекне эзләп тапсын
җир читеннән булса да...

Шунда гына лаек исем —
нинди исем, дисеңме? —
шунда аңа бирер Тормыш
КЕШЕ дигән исемне!

*1984*

## Тукайны озату

Ул киткәндә, шундый
матур яз торгандыр,
яңа орлык көтеп яткан туфраклар...
Бөреләре шартлап ярылыр булсалар да,
күрми калган Аны
язгы
яфраклар...
Янып калган баш очында галәм Шәме,
нур туфанын бар җиһанга таратып.
Үзе киткән җеназада
ил өстеннән,
йолдызларга тугарган да Пар атын...
Карап калган Аңа барлык тәрәзәләр,
пәрдәләргә сагыш җиле кагылган.
Өй кыегы,
капка,
агач башларыннан
соңгы юлга озаткан кошлар, сабыйлар...

Күтәрелгән ак пәрдәләр өлгеләрдә,
карап калган билгесез бер мәэюс кыз.
Гөрләвекләр коеп, җирдә Апрель елый:
«Моңлы сазың … уйнадың соң…
ник бик аз?..»
Ник елмаймый Илнең
барлык маңкортлары,
мөтадаhи, мөтәшагыйрь — барысы да?
Бара Шагыйрь Ил йөрәге уртасыннан
яңа көннәр, яңа чорлар каршына!..
Ломовойлар узып китә Проломныйдан*,
җигүле ат менә Кырлай үреннән…
Ничек Җырны кара гүргә салмак кирәк
йолкып алып халык күңеле түреннән?!
…Күтәрделәр — кулдан-кулга
соңгы юлга,
ак сөлгене салдылар да иңбашка…
Ак Җеназа йөзеп китте Ил өстеннән,
пакь җырлары күтәрелде — Кояшка!..

*1976*

* Бауман урамының элеккеге исеме.

## *Җил тегермәннәре*

### I

Күңелемдә сызылып бик еш кына
ага башлый тоныкк кына инеш...
Тау битенә яккан учаклар
мин кайтканны көтеп яна, имеш.

Баш очымнан, ак болытлар сыман,
еллар агыла, агыла еллар!..
Су буенда — тургай көтүләре!
Кырда — томан:
вак яңгырлар, сары камыллар...

Су буенда тургай көтүләре
таудан тауга оча, таудан тауга...
Бу яңгырлы-җилле көзге таңда
ямансурак язны көтүләре!..

Су буенда тургай көтүләре
таудан тауга оча — чыр да чу!
Күлмәк ябыша тәнгә... Мин — бер чәчәк!
Көзге болыннарым — манма су!

Ә тегермән көзге яңгырларда,
гигант тургай төсле кагынып,
җилгә каршы тора! Камылларны,
көзне көтеп алган сагынып!..

Җил булмаса, безгә тегермәнче
сызгырырга кушты бергәләп.
И сызгырдык! Чыгыр әйләндердек,
салам чөйдек, җилне билгеләп!..

## II

Агач коштай син талпындың озак
яңгырларда, карап еракка
очып киткән кошлар артыннан...
Тынып торды агач канатларың
алсуланып шәфәкъ-ялкында.

Талпындың син, агач күкрәгендә
дүрт йөрәктәй типте дүрт ташың!
Талпынасың! Очып китмисең тик...
Ятим итәрмен дип куркамсың
бу кырларны — дөнья уртасын?!

Алтын көздә сине аяз күккә
чакырып очты биек аккошлар...
Очтың — җирдә! Вакыт буйлап очтың,
көздән очтың! Кичтең — ак кышлар...

Очтың — җирдә! Очтың — заман буйлап!
Кар-яңгырлар кичеп — елларга!
Шушы кырда яңа чорга очтың,
җырга очтың! Легендаларга!

Сугыш янгыннары аша очтың,
какты сине афәт давылы...
Бар көчеңә — дүрт канатка очтың!
Калдырмадың ләкин авылны!..

Минем бабам уйлап тапкан сине,
мәңгелекнең бөек чыгырын!
Гомер двигателе! Якташларны
яздан көзгә имин чыгарып,

син... кузгалдың беркөн... Очып киттең!
Тарихыңны җиргә багышлап,
очтың җирдән... Сине якты җырга
ияртteләр бугай аккошлар!..

Безнең якның урманнары сагына,
иңри әле имән, өрәңге:
шул урманнан иде канатларың!
Сагына таулар: шуннан — йөрәгең...

Төштә күрәм: һаман әйләнәсең,
канат шәүләләрең — сукмакта...
Казык йолдыз яннарыннан кайчак
чыгыр тавышың килә колакка!

Алып менсен синең истәлекне
галәмнәргә очкан кораблар.
Төшләремдә күрәм: әйләнәләр
Ай җилендә синең канатлар!..

## III

Күңелемдә никтер бик еш кына
әйләнәләр агач тегермәннәр,
җирнең канатлары шикелле
талпыналар җирдән күккә,
күктән — җиргә!

Шәүләләре — басу сукмагында,
шәүләләре — минем йөздә...
Әйләнәләр иске тегермәннәр —
күңелемдә...

Ерак көздә!..

*1972*

# Торналар оча

## I

Көньягына,
        көмеш чылбыр булып,
берсен-берсе әйдәп алгы көнгә,
күк гөмбәзе буйлап
үтте алар...
Кулын сузып калды шул төркемгә
һәр куагы җирнең. Канатлылар!..
Көзге җиргә иңә торна моңы.
Җәем янды.
Көзем ялкынлана,
көле булып оча
яфраклары...

Иделем тонык. Күгем Идел төсле.
Үксемәгез, һава бурлаклары!
Җәем янды монда...
Көзем дөрли...
Көле булып тузгый яфраклары.
Уз офыкка, кояш быргычысы,
биеклеккә чакыр Җир-Ананы.
Кош гаскәре, күк дәрьясы буйлап,
язгы якка тартсын
хыялларны!..

## II

Тезелешеп күк юлында
җилфердәшеп очкан чакта,
таралдылар торналарым,
таралдылар төрле якка...

«Санадылар», — диде берәү,
таралдылар ялгыз-ялгыз...
Бураზналар арасында
тора малай — ачык авыз.

Тора малай — сихерләнгән,
кымшанмый да — кызык аңа...
Иң беренче таң калгандай
үзе ачкан могҗизага!..

Таянып көрәк сабына,
кара җирдә, язып билен,
күк юлына төбәлгән дә
онытылган ялгыз килен;
онытылган...
иңенә шуган
яулыгын да тоймый сыман;
туган җирнең алтын чыңын
онытылып тыңлый сыман...

«Җирдә — әбиләр чуагы,
без бу җәйдә бары кунак...»
Торна тавышы кагылса да,
яфрак коя алтын куак!..

Гүя дөнья уртасында
тора агай бүреген салып...
Илемнең бөтен иңендә
тыңлый бүген барлык
халык кошлар тавышын.
Урманнар һәм
таш урамнар арасыннан
Туган илдә төрле телдә
мең-мең күзләр карашыннан

килә аваз: «Санасыннар!..
Таралмагыз! Санасыннар!..
Безне бик күп санадылар,
тик таратып карасыннар!
Са-на-сын-нар!..»

Иделемдә, Енисейда,
Даугавада, Днестрда
шул ук теләк, аваз тора...

Планетага ята яфрак,
Кошлар юлы аяз тора.

*1967*

## «Ә», «Мә», «Бир»

Җәйге болын буйлап,
таянып таякларына,
кая китеп бара өч карчык?
Җәй белән саубуллашкандай,
җил-җил килә
башларында чуар бөркәнчек...

Атлыйлар янәшә, серләшәләр,
ишетмиләр ләкин бер-берсен.
Бергә алар, әмма аерым-аерым —
һәркайсының үз бөкересе!..

Күтәргәннәр бөгелеп гомер йөген:
кайсы азрак, кайсы күбрәк,—
һәркемнең дә «йөге» тигез түгел:
дөньялыкта
        кемгәдер күбрәк кирәк!

Бергә алар.
Әмма япа-ялгыз һәркайсы.
(Шулдыр картлыкның иң төп фаҗигасе!)
Өчесе дә сөйли берьюлы,
бер-берсен ишетмиләр:
берсе: «Ә»,— ди,
икенчесе: «Мә»,— ди,
өченчесе: «Бир»...

Исемнәре кайтаваздай килә арттан:
Хәерниса, Фәхерниса, Шәмсениса...
Җил-давылга каршы баргандай,
баралар Мәңгелеккә каршы...
Авылымнан өч карчык...

*1976*

## *Йокласын агачлар...*

Йокласын агачлар җил тынганда,
йокласын —
тынлык тәмен тойганда.
Изге бер тынлык тора
урамда...
йокласыннар
язга чаклы!..
Тынганнар
мәйдан читләрендә
кыш керфеге — ап-ак куаклар.
Иртәгә аларга, бәлки,
башка кошлар кунаклар?..

Җил
шәһәрне ташлап киткән еракка...

Иртәгә нинди булыр һава, прогноз?
Бәлки, урар җирне томан йә кар...

Таң күтәрер безне, таш яуса да
көн каршына
без бит барыбер торабыз!

Төн үтәр.
Мәйданнар яңа кар көтәр.
Әйтерсең
җепкә тезелеп
төшәр күкнең ак яфраклары,
бер-бер артлы
өзелеп...
Әле тып-тын.
Кеше тыныч йокласын дип
торалар биек-биек баганалар,
манаралар,

күк гөмбәзен терәп.
Төн шундый тын!
Баш — мендәрдә.
Тик төнката
оча
        кызыл орбитада
йөрәк!

Тынлык.
Җиһанга да ял кирәк.

*1972*

* * *

Ни көтәсең, Җирем,
яңгырлармы?
Әллә йомшак кулларның
назлап кагылганын?

Тыңлыйсыңмы, йөзеңә тиеп,
җылы җилләр агылганын?
Сулап ята, ак пар бөркеп,
                калкулыклар...

Ни көтәсең, Җирем,
талгын гына?

Сутлы туфрагыңда шыта
яңа уңыш тамырлары...
Әле Җир-Ананың, муллык көтеп,
йоккә узган чагы гына.

*1972*

* * *

Өрә җил, тулгана карлар.
Җил юлында — ак кирмәндәй
ап-ак ярлар.

Агыйнешләр — ак тозакта...
Җилдерә Кыш акбүз атта!

*1972*

* * *

Ут-дәрьяда кайнап Кояш туган,
Җир өсләрен юган тоташ туфан,
тулып ташкан Тарих ярлары...
Ә биредә, диңгез җилләрендә,
бүген генә килгән төсле Җиргә,
язны көтә
Вавилон таллары!..

*1971*



## *Кабан*

Ярында шәрә тирәкләр —
кара коридор сыман.
Кабанны тыңлый тирәкләр,
Кабанда инде томан...

Төн буе сугышып Кыш белән
дулкыннар инде тынган.
Таң белән күрде кешеләр:
Кабанда ап-ак юрган!

Сарыктай бөдрә болытлар
килделәр кышкы юлдан.
Төн җилләре, сузып-сузып,
җеп эрли ап-ак йоннан...

Ярында шәрә тирәкләр —
кара коридор сыман...
Таллар, аяк очына басып,
Язны карыйдыр сыман!..

*1971*

* * *

Инде кич. Тирәкләр җил көтә, коймага сөялеп.
Җыена болытлар дөньядан — көймәгә төялеп.

Эшлисе эшләнгән, инде тын күкләр гарнизоны.
Бетте ут! Инде буш куыкны атып карыйсыңмы?

Инде кич. Коймага сөялеп, тирәкләр җил көтә.
Коега чиләк төшкәндәй, эңгергә Җир китә...

*1971*

* * *

Өстәлемдә ята ап-ак кәгазь,
көтеп яңа фикерләрне, сүзне...
Шундый якты, пакь кәгазь,
әйтерсең лә көзге!

Кагылырга кыймыйм аның пакьлегенә,
төшәр диеп йөзенә ят күләгә,
буш вәгазь...

Кыймыйм —
шул кәгазьнең көзгедәй аклыгында
күрермен дип үземнең...
сагышлы йөзне!..

*1974*

## *Заман ахыры*

Күкләр чиксез вә догалы:
Фәрештәләр мадригалы!

Мәшрикъ яктан исә җилләр,
Пыскып ята янган илләр...

И Исрафил өрде сурын:
Җәһәннәмдә сезнең урын!..

Җанда өмет: килә Идрис.*
«Бу — мин!» — диеп көлә Иблис...

Илерә адәм утлы ярда...
Чаба
        кешнәп
                атсыз
                        арба!..

*1999*

* Идрис — фәрештә.

* * *

Озата бара безне ак диварлар;
озатып ява, озатып исә
җилләр, яңгырлар...

Актан-ак күңелемдә ничә
кара кәрван кичә,
уйный ак давыллар?!
Мәңгелекнең бер кызыдай Сине
туктап назлыйм әле
шунда, сөйгән яр!..

Безне озатып ак үрләргә менә
ел артыннан ел...

...Кар артыннан кар...

*1973*

* * *

Туган җиргә сүрән карамачы,
якма учак йолдыз катында!
Мин бит сине, үпкәләтеп җиргә,
калдырмадым гомер чатында.

Йолдыз җыры булып кагыл җиргә,
йә җил сулышы, йә бул кайтаваз!
Яфрак булып дөрли дә бер, янә
яшел ефәк булып кайта Яз.

Кайта да ул, таллар шау ут була,
кайный сулар шампан шикелле...
Тагын бер кыш. Буран арасыннан
аккош тавышың гүя ишетелде!..

*1974*

* * *

Су кызыдай каян калкып чыктың,
гомерем сиңа ничек юлыкты?
Егерменче язда күкрәп туган
тойгыларга сәбәп булыпмы?

Хәтерләтеп сихри тау елгасын,
чәч дулкының коя җилкәңә.
Мин бик азны өмет итәм синнән —
бер карашың белән иркәлә!

Тик бик азны өмет итәм синнән,
көнләштерми мине үткәнең —
ай нурыдай сарылып иңнәренә,
елап-көлеп ятны үпкәнең!

Тарихыңны инде еллар юган,
мин үзем дә сөйдем тилереп.
Синең утлы карашыңнан бүген
җаным тора сусап, тилмереп...

Су кызыдай каян калкып чыктың,
гомерем сиңа ничек юлыкты?!
Егерменче язда күкрәп туган
тойгыларга сәбәп булыпмы?

*1957*

## *Карлы тәрәзәләр*

### 1

Тәрәзәмдә кардан ап-ак челтәр,
яшел гөлләр кая үрмәләр?
Тәрәзәмдә ап-ак тропиклар,
тәрәзәмдә ап-ак хөрмәләр!

А, тойгылар! Җылы дулкын булып,
йөрәгемдә кабат терелгән.
Чирек гасыр шушы тәрәзәдән
алтын кояш миңа күренгән.

Рәсемнәрне карыйм: таныш йөзләр,
истәлекләр җанны җилкетә.
Мәхәббәтем, якты еллар язы,
Килерсеңме, йә, кил, мин көтәм!..

Йә, кил инде! Мөлдерәмә күзләр,
җиңел чәчең йөзгә кагылсын.
Күрсәт әле миңа язлар ямен,
бокалларда шәфәкъ чагылсын!

Суыта алмас кышлар; синең хакта
тирән итеп уйдым хисемне.
Карлы тәрәзәләр... Салкын карга
бармак белән яздым исемеңне!

### 2

Әйтерсең без әле кавышу таңын
тау артында көткән ике кош;
арабызда безнең ике яз бар,
иң кимендә әле — ике кыш...

Карлы тәрәзәләр гомермени —
кояш агызыр салкын яшьләрен.
Өй түремдә, ике теләк сыман,
ике тирәк торыр яшәреп!

Икебездә безнең ике ут бар,
ике сагыну, ләкин — бер бәхет.
Без мәңгелекмени? Тынса йөрәк,
икебезгә булсын — бер ләхет!

*1958*

* * *

Авылым —
Арышым,
син минем Парижым!
Үрләр аша миңа үреләсең,
солы кырларыннан карыйсың.
Карабодай тулы төклетура,
бәбәкләре зеңли ясмыкның.

Шул уйларда ничә көзгә кердем,
шул хис белән ничә яз чыктым!
Каенстан!
Урман башыннан ук күренәсең —
йөрәгемә матур утырган!
Әнә синең яңгыр басмаларың,
урамнарың —
минем Нотр-дам!

Әнә зәңгәр инешең, шатлыгыннан
ташларына чаклы яктырган!
Авылым,

күтәреп куй хәтер пәрдәләрен, —
сагыну җиле иссен үрләрдән...
Алып китә мине еллар синнән,
суларыңда кала күләгәм...

Инешеңә иелеп, кояш белән
чәчен юа синең талларың.
Еллар аша күренә: шундый биек
күтәрелер икән таңнарың!..
Еллар аша күрәм кояшыңның
камылларда чәчрәп янганын.

...Тау артыннан ишетәм туган якта
әрекмәнгә
тамчы
тамганын!

*1966*

## *Тупыллар җилгә каршы...*

### 1

Таң алдыннан тәрәзәмдә
тупылның таныш шавы:
имин икән җилләр, кошлар,
ерак йолдызлар — бары!..

Таң алдыннан өй түрендә
бер торып шаулап ала:
әйтерсең яфраклар аша
гомерләр шаулап ага...

Җил исеп куя да кинәт
таң киләсе яклардан,
өй түремдә хәтер ява,
моң түгелә яфраклардан.

Моң түгелә яфраклардан...

### 2

Әйләнде безнең гаиләгә,
башыннан кичте бар да...
сыенды безнең кыекка
күкрәүле яңгырлар да...

Тәрәзәдән карап торды
туган йортның мичено;
мөнәҗәт әйтеп керде ул
төнге җилләр эченә...

Тора ул, шаулап тора ул
елларда,
еракларда...

Туган өйнең тәрәзеннән
ут төшкән яфракларга!..

### 3

Калды яшен божраларда,
түземлегең — давылларда,
сурәтең калды яшеннәрдә,
истәлегең — елларда;
сулышың калды яңгырларда,
шавың калды җилләрдә,
яшьлегең — тамырларда.

### 4

Без, тупылым, бергә!
Йолдыз яңгырлары астында
кичеп чиксез еллар дәрьясын,
кешеләр һәм тупыллар барысы —
яланаяк, яланбаш, —
һәрчак
баралар — җилгә каршы,
күк утлары,
зилзиләләр уты аша,
кулга-кул тотынышып,
кушылып зур төркемгә,
баралар...
Гомерләр һәм туфрак иркендә.

*1980*

# Тургай җыры

Тагын да яз.
Кояш җир йөзенә
алтын керфекләрен сирпеде.
Җирне ялый кояш,
җир парлана
яңа туган бозау шикелле!..

Тагын да яз.
Тургай, үрли-үрли,
биеклеккә менә тырпылдап.
И, кистерә!..
А, Паганини —
өздерә бит бары бер кылда!..
Иң югары авазларны ала:
турр-турррр,
колоратур
сопрано!
Иң югары авазларны ала:
ноталары
кояш нурларына язылган...
Минем кебек ул да илһамланган
туып үскән җирнең языннан.
Биеклеккә димли игеннәрне,
бодайлар, дип, биек үрләсен,
Танкларны үлән басып китсен,
сугышларны тынлык җирләсен!
Җирне күтәрәсең, тургай!
Үзең
сайрый торган нокта нибары!..
Җырла, әйдә! Язып алсын сине
гигант магнитофон — Җир шары!
Һәм тыңласын еллар,
сине язсын

сугыш авазлары өстенә.
Тургай кебек,
кояш нотасына
Җир җырласын
яңа көч белән!

*1970*

## *Иделдә җәй*

Ятам ярда. Тыныч дәүләт сыман.
Баш очымда шаулый тупыллар.
Баш очымда Идел әкият сөйли.
Йөрәгемне юа дулкыннар!

Якты. Тыныч. Иркен! Әйтерсең лә
дөньяның бу кыл бер уртасы.
Кочагыңа ал да эрет мине,
Җил һәм Кояш Республикасы!

Киңлекләрдә җәй патшалык итә,
Иделемдә — җәйге аккордлар.
Гомерем җәе. Тугыз баллы кояш
җирнең йөзен ничек балкыткан!..

Шырпы сызам, ярда учак ягам,
көнгә кушам учак яктысын.
Утлар бии алтын елан кебек,
офыкларга сузыла яктысы.

Чикерткәләр һәм бөҗәкләр шыла
үләннәргә. Дөрли җир уты!..
Кабатланмас мизгел. Гасырның бу
бер күз ачып йомган минуты.

Истәлектән сары һуннар калка,
үрә тора Чыңгыз атлары…
Кояш шаһит! Өзәңгесен тартып,
ишетелә кешнәп чапканы…

Китә бар да учак уты белән,
кайта бар да иске урынына.
Кояш карый тугыз баллы белән,
Идел җиле йөзгә борыла.

Шул учакны кыйныйм таяк белән
һәм чик куям шунда мин утка!
Чалкан төшеп җирнең җилкәсенә,
тынычланып йөзәм офыкка.

Мин үземә-үзем тыныч дәүләт;
сугыш ачмыйм, утлар дөрләтмим.
Һәр пунктка ашыгып имза куймыйм
һәм танымыйм һәрбер дәүләтне!

Җир өстендә тора изге сәгать,
күкләр тып-тын. Гадел минутлар!
Һәм, кыйбласын онытып, офыгында
тугарылып ята болытлар…

Әйтерсең лә җирдә тәмуглар юк,
кыерсытмый кешене кешеләр;
сагыш та юк, кара каргыш та юк,
бар кешеләр — бер үк төслеләр…

Син дә мине күптән кичергәнсең,
онытылган бөтен ваклыклар…
Иделдә җәй.
Җирнең яртысында —
җәй патшалык иткән вакытлар!

*1966*



# *ДИҢГЕЗ РИТМНАРЫ*

## *Эчке аваз*

Ярсый диңгез! Ташлы ярларына
суүсемнәр, ефәк, йолдыз өя, —
гомере буе җыйган бар бирнәсен
ачуланып бәрә карт кыз гүя!..

Күбекләнгән дулкын сыртларына
тозлы җилдә текәп карый халык:
кем ул анда? Упкын кочагына
бата-чума йөзә, колач салып?

Кайсы башсыз шушы гарасатта? —
Аның өчен аһ! итәләр кешеләр...
Кемнәрдәдер кызыксыну уты
яна бугай: «Егет нишләр, нишләр?»

Бата. Калка! Ә яр — бер урында!
«Шулай укмы мине йотар диңгез?..»
Ул елмайган була ярга карап,
тик күзләре дәшә: «Коткарыгыз!»

Кычкыралар күзләр: «Кот-ка-ры-гыз!..»
Горур күңел әйтә: «Язма һуштан,—
Ялварулы сүзне дустан бигрәк
ишетүчән була элек дошман!..»

Кычкыралар күзләр көпә-көндез!
Як-ягында диңгез актарыла.
Бата. Калка тотынып... дулкыннарга,
ябышкандай ап-ак ат ялына.

...Талпынды да соң кат, ярга чыкты
кайнап торган упкын арасыннан.
Һәлакәтнең нинди зур буласын
күрде бары кешеләр карашыннан.

Калды диңгез шашып...
Тирәнлектән
кычкыралмый калган Эчке аваз
күтәрелде, дулкын белән чыкты:
«Коткарыгыз!
Кот-ка-ры-гыз!..»

Кабатлады таулар: «Коткарыгыз!»
Иң хәтәре җирдә — эчке аваз.
Таулар саклый моны, саклый ярлар,
упкын кырыенда үскән агач...

Хәвефлесе аның — эчке аваз,
иң хәтәре аның — соңлаганы;
кан тавышы,

вөждан кычкырганы,
сулык-сулык
намус елаганы!..

Җансызмы соң, —
яши һәр үләндә,
һәр яфракта яши Эчке аваз...

...Диңгез тынган иде.
Пар шикелле
чыгып тора бер сүз:
«Кот-ка-ры-гы-ы-з!..»

*1968*

* * *

Таң сәгате. Чал диңгезгә баш идем.
Диңгез ап-ак, анда ярсый Посейдон!*

Даулы киңлек, шау көрәш набатлары,
айга сикерә ап-ак яллы атлары!..

Ярга килә дулкын-дулкын яу кебек,
җилә кешнәп, яллар төбе чал күбек...

*1974*

---

* Посейдон — мифик диңгез алласы.

## Хуш, диңгезем!

Прощай, свободная стихия!

*А.С.Пушкин*

Бөек мизгел, тукта! Шушы килеш
күзләремә тулып кал син мәңге!
Алып китим сине мөлдерәтеп,
и Табигать, шаулы диңгез яме!..

Алып китим гомерем буйларына,
озата барсын мине зәңгәр балкыш,
озата барсын ерак юлларыма
зәңгәр күзләр, таулар кызы, йә, хуш!

Хуш, диңгезем! Бөек күкрәк сыман
талгын гына сулап, тыныч калдың.
Сиңа кушылып үзем дулкынландым, —
йөрәгемдә синең дулкыннарың...

Хуш, диңгезем! Тыныч култыкларың,
давылларны кичкән кыяларың!
Тын чакларың, шашкан минутларың,
якты өмет эчкән хыялларым!

Хуш, тирәнлек! Упкын гарасаты,
көчле рухны сөйгән иркенлекләр!
Карашыңны болыт-җилкән иткән
тавыш адашырлык хөр киңлекләр!

Бер шатлыкны бишкә бүлгән чаклар,
узган җәйнең имин тавышлары!
Диңгез урамында яшел чатлар,
хыял белән бәхет кавышканы!..

Озын җәем уты, ялкын-учак,
киңлекләргә баккан алтын чаган!
Көзләр буе хаттай кочак-кочак
Яфрак очар бездән сезгә табан!..

*1968*

# *Кара диңгез*

*

...Бармагымны
диңгез
ялый...
Күренә моннан
Төркия
өстендәге
болытлар!..

*

Диңгез — офыктан офыкка!
Хәрәкәт — дулкыннан дулкынга,
сулышы — җилләрдән җилләргә,
тирәнлек — упкыннан упкынга,
тавышы — ярлардан ярларга,
калгышы — таңнардан таңнарга,
юллары — ерактан еракка,
моңнары — йөрәктән йөрәккә!..

*1971*

* * *

Өлкән диңгез,
шаулап күрсәт әйдә,
ярларыңда илә ташларны;
ак күбеккә батсын төпсез упкын!
Тамчыларың
тозлы яшьләрме?..

И җиһанның бөек тагарагы,
бар дөньясын юып ташла әле!
Гөнаһлардан азмы тапланган Җир,
Каралган ич
Кәгъбә
ташлары?!

*1972*

* * *

Иртән, әле син йоклаган чакта,
күкрәгенә тартып ак юрганны,
дөнья рәхәтләнеп мунча керде,
яңгыр коендырды газоннарны.

Җир парлана,
җирдә — яфрак исе.
Иделемнән диңгезләргә чаклы
Җир чабынды Кояш ләүкәсендә,
җилкәсеннән гөрләвекләр акты!

Йөрде күкрәү июнь күге буйлап,
күкрәп йөрде түбән регистрда,
офыкларга китеп башланды,
сөю булып керде минем җырга.

Тәрәзә ачтым — ак болытлар оча,
өй түремдә җил дә, юкә шавы…
Җир шундый яшь! Җирдә июнь тора.
Мәхәббәтен чатта көткән чагы!..

*1966*

## Йоклама

Йоклама, җан,
син йоклый дип әллә кайчан,
күренмәгән ишекләрдән,
ярыклардан-тишекләрдән
коелалар — мөтәдаһи, бөтен гайбәт...
Син йокласаң,
алар — әйбәт!

Үрмәлиләр кетер-кетер
намустай ак кәгазьләргә,
керешәләр, чи-чи килеп,
буш нотык һәм вәгазьләргә.
Баса алар син укыйсы
ап-ак китап өсләренә!..
(Сиңа хөкем чыгаралар
җыелып үз өстәлеңә!)
Йоклама, җан,
син йокласаң,
баш түбәңдә йөрер биеп,
көлә-көлә гайбәт чөеп:
син — кечкенә...
алар — бөек!

Йоклама, җан,
оема, җан,
син йоклый дип әллә кайчан,
баш калкыта җаһил гакыл,
һәм уяна
мәләк шайтан!
Йоклама, җан!

*1974*

## Туган йортта сентябрь

Узып китте август, көлтә төяп,
капчык төяп үтте ындырлардан.
Камылларны чиртеп исә җилләр,
алтын гөслә зеңли киң кырларда!
Кай җирләргә әле кул тимәгән,
сабагында тора иген басып...
Күңелемдә шулай оеп тора
урылмаган җырлар полосасы...
Ашыгырга иде: кайчан гына
юлда тузан иде — коры дары,
инде хәзер һәр сабактан сибелә
сентябрьнең салкын йолдызлары,
түбәләргә сибелә учлап-учлап,
йә шыбырдый кабак яфрагына!..
Син уяндың. Бусагада — Заман.
Туган йорттан кабат чакыра юлга.
Бар да әзер, ана хәстәрләгән,
энә-җебен хәтта онытмаган.
Ул озайтыр иде сентябрен,
Арчыр иде күген болытлардан,
синең хакта (үзен уйламый да),
якты булсын өчен синең юлың;
уган керен куеп озата чыга,
алъяпкычка сөртеп юеш кулын...
Усакларым дөрли аягүрә,
үч иткәндәй көзге яңгырларга...
Ә мин карыйм яшереп әниемнең
чәчендәге көмеш чалымнарга:
сентябре кергән! Түбәсендә
сызылып ята Киек Казлар Юлы...
Суык дулкын, сары яфрак түгел,
күзләрендә —
туар язлар моңы!..

*1968*



## Гомер тирәге

Пәһлевандай, башы күккә ашкан,
утыра бөек Кояш утында
тып-тын гына балкып! Ерактан
еракларга сузыла күләгәсе.

Яфраклары — еллар. Якты эчкән
тармаклары — гомер шәҗәрәсе.

И шаулый ул заман җилләрендә,
шавы кушыла еллар шавына!
Түшәләләр алтын яфраклары
охшап якты йолдыз тавына...

Ни көтә ул галәм асларында,
нинди максат җирдә терәге?
Тормыш дигән тауда — бөек, мәгърур —
балкып утыра
Гомер тирәге!

*1974*

* * *

— Нигә уйчан? — диләр.—
Тыңлыйм
гомер шаулап акканын.
Хәтер елгаларын кичеп,
хатирәләр кайтканын;

баш очында Кояш җырын,
моңын бөек Заманның;
бик тирәндә — Вөждан тавышын,
намус сулкылдаганын;

бүгенгедән киләчәккә
очып барган хатларның
сәламнәрен...
                Җилпенешен
мәңгелек канатларның...

— Нигә уйчан? — диләр.—
Тыңлыйм
Вакыт шаулап акканын!

*1984*

## Урманчега — соңлаган багышлау

…Олы юл ул — бик күп халыкларның олаулары, ямщиклары йөри торган, гасырлар буе үскән каеннар утырган баганалы юл. Ул юл озын, озак…

*Бакый Урманче*

Ул юл озын, озак — ай-һай, түзәр микән
арбаң тәгәрмәче?
Юл читендә шайтан таяклары, әрем,
убыр табагачы…
Уза ул юл соргылт тузан тузган
айлы кырлар аша,
даңгыр-доңгыр — гомер олаулары
сузыла чорлар аша…
Карурманнар шаулап каршы ала,
атлар өрки куркып.
Юлаучылар алдан бара, атның
тезгененнән тотып.
Сикереп төшеп, бураннарда төнен
юл катысын таптың.
Әйдәдең син, ак башыннан тотып
Тормыш дигән атның.
Тәвәккәлләр юлы бу олы юл.
Һәлакәтләр тулы…
Бара торгач, килеп коя аңа
Киек Казлар Юлы.
Йолдызлар аша үтә юл —
ул юл озын, озак…
Мин — бер юлчың. Каршыладың, Тормыш,
фатихаң бир, озат!

*1985*

# Туфан уты

…Әле берничә ел Аккош
күлендә иҗат итәсе бар.
Туфанның утсыз
тәрәзәсенә карап.

*Сибгат Хәким*

Төн эченә кереп китте янып,
башкайлары якты сүсән уты…
Ак таңнарга килеп чыга иде
ут кабызган килеш Туфан йорты!..
Караларга каләм мангандамы,
кай арада гына сүнгән уты?..
Кай арада җәй йөгереп үткән,
кунган көзнең көмеш кырпаклары,
күл комына кергән соңгы сазан?
Үбә ярны зирек яфраклары…
Кайчан гына, абагалар ерып,
тургай гөлен эзләп йөргән чаклар?
Тәлгәшләргә тезгән ноталардай,
сагыну көен җырлый ул яфраклар!
Давылгамы шаулый, кояшкамы,
әллә безнең башка бу усаклар?!
Кышларгадыр,— килә яңа фасыл —
килә җилдән, килә кар исләре!
Туфан утын эзләп килгән сыман,
коела кышның ап-ак варислары!..
Төнге сәгать. Борылып туктагандай,
аның йорты калгый тып-тын гына,
кораб сыман, кабызып бар утларын,
Шигъриятнең зәңгәр култыгында…

*2000*

* * *

Айга карап өрә этләр,
бүреләр улый Айга;
кабарта сыртын дулкыннар
диңгез-океаннарда.

Ай белән Җир тартылышы
ике тамчы судай...
Мин дә сине искә алдым
шул Ай яктысында.

Ай тотыла: Җир шәүләсе
Айның ак төсендә.
Мин тотылам, синең шәүләң
җаным яртысында!

*1986*

## *Җәяүле Күбәләк*

Безнең сагыну шундый —
ашкынабыз җир үзәге булган төбәккә,
йөрәгебез
болытларга тигәләп!
Ә түбәндә
таулар, урманнар артына,
чакрымнар аша
җилне җиңеп, җилфер-җилфер килеп,
кайта
бер күбәләк!
Кайта! Болытлар астыннан,
давыл сукмагыннан,
каршысына урманнардан
сибелә сары яфрак, —
сары күбәләкләр күч-күч
ятып кала кырда.
Ә бу — кайта! —
Җанлы сары яфрак төсле
җил-җил килеп,
калтырап!
Колакларда саубуллашу җыры,
әллә инде кыска җәен эзләп,
ашыккан кешедәй очына-талпына
кайта!
Җәйге болыннарның җаны —
Җәяүле Күбәләк.

*1974*

## *Яшел тупылга мәдхия*

А, йөзьяшәр тупыл, миллион яфрак —
җиләс йортым, яшел июнем!
Кояр идем сине туграм итеп, —
шулдыр сиңа кайнар сөюем!
Яшел генератор!
                    Җирдән бәргән
моң фонтаны, яшел моң шавы!
Кемгә тиңлим сине?
                    Шау яшьлекнең
мөмкин бары сиңа охшавы!..

Яфракларын, шаулы туйда кайнап,
алкышлыйлар сыман галәмне.
Туфрагыма буең аша уза
йолдызларның ерак сәламе!..

Баш очыңа килеп куера да
тынып тора гашыйк яшь болыт...
Яшел кочагыңа сыенып, Җирдә
калыр идем мәңге яшь булып!

А яшел җил... яшел яктылык!

*1975*

## Элегия

Бу оядан очты кошлар. Таралды йорт.
Тик мәңгелек туфрак аның нигезендә.
Сугар сәгать. Кара туфрак, синең кебек
мәңгелеккә әйләнермен үзем дә...

Мәңгелек тә өмет итмим, туган туфрак,
шуны гына сорыйм бары бу җырда:
соңгы йортым, моңлы йортым түбәсенә
җылы яңгыр булып кына шыбырда!

*1974*

* * *

*Илһамга*

— Минутларны ник санныйсың,
вакытың бик тар мәллә?
Тәрәзәдән ник карыйсың,
җиккән атың бар мәллә?
Әллә иркә басып кына
сөйгән ярың көтәме?
Әллә синнән качып кына
яшьлек гомерең үтәме?
— Минутларым — якты дулкын —
агыла да агыла...
Дәшә җанны өмет утым
алгы көннәр ягына.
Ярым да бар, аргамак та,
көч тә кайный йөрәктә...
Тынгысызлый бик еракта
ирешелмәгән теләкләр!..

## Кечкенә кешеләр йорты

Җыелалар —
бар да кечкенәләр бу йортка.
Табалар да югалталар,
зурлык даулашалар
тормыштан.

(Чыга хөкем!..)

— Без — дәүләр! — дип, үз-үзләрен юаталар,
зур сүз чыгаралар.

Һәм... яңадан
кечерәеп таралалар...
(Кала төтен!..)

*1985*

* * *

Каеннарны үт тә сугыл миңа.
Күңелем әле утсыз йорт сыман.
Анда бар да синең җыр шикелле
исемеңне көтә, юксына.
Син кер анда. Калдыр бусагада
икеләнү тулы уйларны.
Син кер анда. Ут ал күзләремә,
уз,
тәртипкә китер дөньямны!
Анда бар да синең кулны көтә.
Үз итеп йөр. Үз ит, тарсынма.
Утлар кабыз. Чыгар гөлләреңне
коеп яуган яңгыр астына.
Бар да синең якты эзне саклый,
син кагылган әйбер — кузгалмый!
Ак мендәрдә синең җылың тора,
гөлләреңнең төсен көз алмый.
Бусагада синең адымнарың,
тоткаларда — җиңел кул эзе.
Шәүләң йөри! Саклый пыялалар
еллар җуймас ике йолдызны!..
Күңелем — бер йорт. Калдырып кер,
йөртмә
икеләнү тулы уйларны.
Син йөр анда, ут ал күзләремә,
уз,
тәртипкә китер дөньямны!

*1966*

## *Сиңа*

*(Биш мәрҗән)*

### I

Озак бардым... кайнар чүлләр,
хыял-мираж аша,
калыр бары тик шул исемдә:
Сиңа килеп җитеп,
ял иттем мин
күзләреңнең оазисында!..

### II

Мин — өметле байгыш, нарасый җан,
Яши идем очар моң булып...
Мине атты сагыш!
Күк түреннән
Синең алга төштем егылып.

### III

Күк түреннән тибри-тибри төшкән
кош каурыен алдым учыма.
Җылы әле — кемнәр харап иткән,
ниләр булган күңел кошыма?

Күк түреннән төшкән җылы каурый
нигә икән шундый кадерле?
Кемнәр идең, кемнәр юлыңа төште,
бу, җанкаем, Синнән хәбәрме?

### IV

Тузганаклар инде очты тузгып,
Җәй уза, дип мөмкин моңаю.

Шау урамда, кемнең иренендәдер
Узып китте Синең елмаю.

## V

Үтте дә китте,
китте, ераклашты…
Быелгы җәй яфракларын
сагыш җиле үпте.
Сарыларын элде ул
җаным түрләренә;
и җилферди, өзелә
бәгырьләрем лә!
Җәй үтте, күрмәдем
аның эзләрен дә…
Сыкранып җан бирде, бәгърем,
Синең тезләреңдә!

*1989*

* * *

Үткән төндә сине төштә күрдем:
мин каршыңа, имеш, чабамын.
Кыска гына төшемә ничләр кердең?
Бик күрәсем,
бик күрәсем килә дәвамын!

Болын буйлап каршы килә идең,
кулым сузып сиңа үрелдем.
Арабызга төште ташкын сулар...
Син тауларга,
син тауларга китеп күмелдең.

Тау артыннан килә синең җырың, —
ерагая бара, үткәнгә.
Мин кузгалмый шунда басып торам,
сабырлыклар,
сабырлыклар бирсен көткәнгә!

Үткән төндә сине төштә күрдем:
мин каршыңа, имеш, чабамын.
Кыска гына төшемә ничләр кердең?
Бер күрермен,
бер күрермен микән дәвамын?..

*1986*

# *Чал платан төбендә*

Чал платан төбендә дә — кояш.
Искә төшә
иген кырлары,
иртәнге җырлар,
яшел таулардагы җил,
ак карлар!
Су кебек шаулап ага җил
яфрак арасыннан,
яфраклары — яшел карлыгачлар.
Ишетелә сыман тормыш агышы,
алтын башаклар шавы, җигүле атлар...

Шау кояшта утыра агачлар!..

Чал платан төбендә дә — күз.
Утыра шунда бер карт — нәкъ Мәрҗани!
Биредә гүя гыйлем мәгарәсе.
Чал платан — манма кояш!
Җиһан каршысында
алтын таҗын киеп шаулап тора,
һәр яфрагы —
гомер шәҗәрәсе!
Чал платан төбендә дә — җил...
Чал платан төбендә дә — туфрак.

Чал платан төбендә дә — Ил!

*1974*

## *Иҗатка мәдхия*

Син — минем күңел байрагым,
булганым, булачагым.
Син — яз һәм кыш, рәхмәт, каргыш,
яшьлегем, балачагым!

Үткәннәрем, киләчәгем,
рәшәле офыкларым,
нурлы төнем, кара көнем,
кояшлы болытларым;

гомер буе җыйган малым,
аласым-бирәчәгем,
җир җәннәтем, кыямәтем,
күрәсе күрәчәгем;

ашыйсы аш, яшисе яшь,
сызылган ызаннарым,
ярыласы яфракларым,
тузасы тузаннарым;

куанасы куанычым,
юаныч, күз яшьләрем,
сөйгән ярым, көндәшләрем,
каләмдәш, илдәшләрем;
абынасы ялгышларым,
таянасы тауларым,
и, хыялый язмышларым,
и, тынгысыз таңнарым!..

*1996*

## *Сәхнәдән киту*

Сәхнәдән
җиңел киту рецепты юк
(мөмкин аннан егылып төшү дә!).
Уйнадыңмы, йә, хуш, юлыңда бул, —
Тормыш та уйнады җитәрлек!

Инде хикмәт —
вакытыңны, дәрәҗәңне белеп,
сабырлыкка күчүдә.

Бик беләсең,
елмайганда бүген сиңа яшьләр,
син аларның түгел күптән кумиры.
Кабул ит тә, бәхиллә син —
бары шулай, —
тик шыңшыма!
Мәңге түгел кояшның да гомере!

...Сәхнәдән киту, дустым,
ташлап авыр перчаткаларын
рингтан киткән боксер кебек,
чүгеп, йолдызларга табынган,
яшь көчләргә сәҗдә кылган,
тулган айга мөкиббән булып
утырган
дәрвиш сыман...

Хәерле юл!
Юлларыңа — ак эскәтер!

Тик бер теләк, онытылган:
бәхил, туган.
Кайт яңадан, диеп сиңа
кайсы әйтер?

*1988*

# Киттем

Җитми безгә, җитми бар да, —
Безгә дөньясы тар.
Шуның өчен дөнья безне
беркөн тотып сытар.

Җирне туфан басканда да
су җитмәс бер йотар.
Гомер-гомердән бер-берсен
ник ашый бу татар?

Киттем — киңәйдеме дөньяң?
Җитми — шунда хикмәт.
Җитми безгә бер саплам җеп,
бер кабасы икмәк.

Җитми вакыт, җитми чират,
җитми кәррә хәмер.
Дуска — бер тәгам җылы сүз —
моңа юктыр әмер!

Җитми буй, көч-куәт, вөҗдан,
шырпы, тоз һәм күмер...
Бер яшәрлек тәмәке һәм...
Бер төрерлек гомер.

*1998*

## *Төп йорт*

Төп йортым син, төп йортым,
адым белән үлчәнгән
яшел кәсле төп йортым —
түмгәкләр һәм билчәннәр
телен белгән төп йортым…
Төп йортым син, төп йортым,
тургайлы түбәләрем!
Тәрәзәңдә кемнең бу
Ак җаны — күбәләге?
Төп йортым бу, төп йортым,
бабамнар сөйләшкән җир!
Чит җирдән бүреге белән
кайтырга киңәшкән җир…
Бәхетле кеше генә,
ятып үз түшәгенә,
багып үз түшәменә,
суың эчкән бер йотым…

Туган илем — Идел-йорт,
Татарстан — төп йортым!

*1974*

* * *

*Л...гә*

Сиңа карыйм да күңелдән
язларның сурәтен ясыйм.
Кызганма, борчылма,
  дөньяда
тагын бер сурәтең калсын.

Минем күк сөеп чәчеңнән
язгы давыллар тарасын.
Соңыннан,
сагынып исемеңне,
рәсемеңә еллар карасын!..

Беләсең, бик гадел булмадык,
бик тигез салмадык эзне дә.
Без дә бит бу җирнең баласы,
еллар юксыныр безне дә.

*1965*

## Югалган бер көн хакында

Бүген мине таптап узды көнем,
тик үземнән эзлим сәбәпләр.
Көн югалды! Планеталар юлын
билгеләгән чакта — сәгатьләр!..

Төбәгәндә Заман капкасына,
ул туп булып читкә сикерде:
кагылмыйча үтте йөрәгемә,
«сөткә» киткән пуля шикелле!

*1963*

# Күгәрчен очып туймас көн

Күгәрчен очып туймас көн,
һич сулап туймас һава!
Мәйданнар буйлап килә Көн, —
беркем чик куймас аңа.

Көн керә тыныч өйләргә,
нурлары әле кыйгач.
Көндәгечә, соңламыйча
төшлеккә килә Кояш.

Көн белә ич үз вакытын —
өрсеннәр, янасыннар...
Өрсеннәр дә бу Кояшны
сүндереп карасыннар!..

Туктатсыннар йә Җир шарын, —
ник гел алга бара ул?!
Йолдыз яңгырлары аша
үзенә юл яра ул!

Мәйданнар буйлап килә Көн,
ниятен яхшы беләм:
күгәрчен очып туймас көн
расланды Кояш белән!

*1958*

* * *

Сине нинди җилләрдән сакларга,
аралларга давыллардан,
якларга нинди кайгылардан,
ут-күздән, кыен сүздән?

Бу ояда сиңа да
канат чыгар тиздән.

Сине ничек сакларга
тидермичә ятлардан?
Китәсең кереп күк асларына —
тере нокта!
Ничек сине сакларга
шушы олы дөньяда?

Син — бөҗәк түгел,
керергә яфрак астына,
син — балык түгел,
посарга
дулкын арасына,
син — киек түгел,
күмелергә урманнарга.

Син — кояш астында!
Заманага — туры!

Ничек кенә сакларга
Җырлы йөрәгеңне
Кыраулардан,
Нәни кешем?!

*1975*

* * *

Бу төбәктә, бу төбәктә бары
шат көннәрнең тәүге авазы.
Юлларыма бурап яуган кары,
уйларыма биек һавасы!

Тыңлап туялмаслык әкиятләре,
чишмәләре ургый таш ярып;
буыннарның гореф-гадәтләре
бу төбәктән китә башланып.

Бу төбәктә безгә дигәннәре
тора балкып кояш утыннан.
Шаулый җирдә татар имәннәре,
шаулый илдә якташ тупыллар!

Көрәш шавы тулы заманнарда
шунда туып гомер кичелгән,
язмышыбыз шунда ялганган да
кендегебез шунда киселгән.

*1984*

# *Лирик әкият*

Тарак ташлады — карурман үсте,
Көзге ташлады — күл булды.

*Халык әкиятеннән*

Ә син гүя горур болан кызы,
йөгереп уздың язгы юлларны;
минем гомер җилә синең эздән,
ерып чыга ташкын суларны!

Мин бу ярда торам. Син, яз кичеп,
җәйгә кердең. Кошлар иленә.
Җәйгә керәм. Анда гөлләр яна,
иркәләнеп синең җилеңә!

Коя анда синең яңгырларың,
ак болытлар коена күлләрдә.
Ул күлләрдән миңа йотым су юк
сиңа зарыгып янган көннәрдә.

Җитеп булмый сиңа! Толымыңнан
ыргытуга алып тарагың.
Эзләрендә шаулап урман калка,
карурманнар каплый араны!..

Кызыл тарак төсле юл өстендә
янып тора көзге урманнар.
Көзгә керсәм — инде көзне уздың:
арада — кыш.
Аера бураннар!

Язга керәм. Җиттем, дигән чакта,
әйтерсең лә көзге ташладың:

ялкынланды кинәт язгы күлләр,
елгаларның ярдан ашканы
юлны бүлде...
Тагын килеп җиттем
әфсенләгән утлы сызыкка...

Еллар аша сине эзләп барган
чакыру тавышым җәелә офыкка!

*1967*

* * *

Яз башында күкрәп килгән яшен,
яшеллеккә старт биргәндәй,
атыла күктә. Җылы җәй каршына
дулкынланып йөгерә үләннәр.

Тик бер күкрәү! Җир кабара шуннан,
сандугачның теленә җыр кайта,
төнге таулар язның япь-яшь гөлен
итәгенә алып йоклата!..

Хәтерләмим, кайсы яздадыр ул
тәүге яшен атылып янганы...
Ләкин истә: җылы күкрәү тулы
карашыңнан старт алганым...
Мәхәббәттән телсез калганым!

*1963*

## Хушлашу көзе

Без хушлашкан көзне, томан төшеп,
каплады, пәрдә сыман, ерагайтты араларны.
Киттең.
Күз яшьләре сыман,
көзге богылларны чылатты октябрь яңгыры...
Киттең — көз аркылы, көзге сусәргән
үләннәрне таптап;
сүзсез генә сагындым мин
әле яңа гына ераклашып күмелгән сыныңны,
болын уртасында
әкрен генә ярларны иркәләп аккан
көмеш инешкә карап...

Көзге болыннарда сулган чәчәк,
юеш җилләр сыйпый талларны.
Күксел томан инде
каплады, каплады,
ерагайтты араларны.

Болын өстен сыек томан сарган;
мин яңадан килер идем
болын томаннары таралганда —
язгы иңкүлектә,
агыйнешнең аръягында,
ап-ак шомырт булып,
тып-тын гына балкып
син торсаң анда.
Дәваларга иске яраларны!..
Кичер мине!
Җилферди аклы күлмәгең үрләрдә...
Кемнәр табар сагынуга дәваларны?!

*1987*

* * *

Аерасың, бөек Вакыт галиҗәнап!
Агып, ургып, тирән упкын ясап,
аналар һәм балалар
гомер дәрьясының
төрле ярларында калалар;
аерасың,
Тормыш ярын ашап...

Аерасың —
ераклаша аралар,
китеп ерак юллар томанына...
Бер сүз калды минем теге ярда!..

*1978*

* * *

Сез дә картаясыз, таллар,
үзгәрәсез көз алдында.
Күз алдында
Әнкәй утырып байый
(төшә кояш)!
Сеңелем ап-ак яка кайый
көзге алдында.
Кояш төшә үлән арасына,
сулар менә ярга.
Җилләр китә күчеп тау артына,
кошлар төшә ялга...
Сез дә картаясыз, таллар,
үзгәрәсез күз алдында...
Заманның купшы кызы —
көзге алдында!..

*1977*

## *Кешегә җылы сүз*

Чәбәләнгән күзгә диңгез сыман,
бер кузгала өмет, бер тына.
Күтәрелә кошлар, кагыла сулар
табигатьнең яшел бортына.

Китә еллар. Бар да Кешегә кала.
Кешегә кала яхшы-яманы!
Юып бетми, көйдереп-тишеп ала
изүеңә яшьнең тамганы!..

Китә кеше...
Кемгә алыштырыйм
урынын аның кемгә, бүтәнгә?
Китә кеше, канын холестерин
агулапмы китә ул бәндә?..

Белми беркем...
Кояш белән торып,
мин әйтмәдем аңа җылы сүз.
Вөҗданыңа инде арка борып,
үзең уйла хәзер, үзең түз!

Калды ул сүз эчтә...
Алмый тын да,
мин саклаган идем сиңа дип...
Саклап калдым аны — синнән соң да.
Йөрим саклап —
гүя динамит!..

*1974*

## *Күңел догасы*

Күк арбасы узды болытлардан,
койды яңгыр — кырлар канәгать!
Ал дугасы гына эленеп калды,
Узган яңгырлардан — салават!

Күкрәде җан офыкларга тулып,
җир сөтләре менде каләмгә!
Йөрәгемне дер селкетеп узган
якты күкрәүләргә — салават!

Күкрәдек бер, ташып чыкты ярдан,
яшьлек дәрте бер дә галәмәт!
Моң калдырып ярларына кайткан
тонык елгаларга — салават!

Җир гүзәле, бергә гомерлеккә
антлар эчкән идек — мең кабат!
Күксел төтен булып җилгә очкан
антларыңа, сылу — салават!

Тапмагандыр әле туганнарны:
ярты юлда — олы әманәт...
Әманәткә ясап мең хыянәт,
киткән дусларга да — салават!..

Көн күзендә калсын якты өмет,
янсын гомер! Намус — сәламәт!
Ак болыттай, баштан сыйпап кына,
Үткән гомерләргә — салават!

*1974*

* * *

— Саумысыз, картлар, ни хәлдә?
Җиңел үтәме картлык?
Яхшымы бу яссылыкта
бераз бөгелеп йөрүләр,
заманына абруй белән
иелеп сәлам бирүләр!

— Картлык — түгел шул шатлык!
Яшәлде, шөкер, яшәлде.
Шәүлә булып йөрегәнче,
ахры, киткәнең артык...

Ачысы да, төчесе дә
тигән безнең йөрәккә.
Йөрелсә дә, дөньягызда
йөрелгәндер кирәккә...

Йолдыз тот шәрә кул белән,
кабалан, өскә үрел...
Алмаганмы кысыр хыял
гомернең өчтән берен?..

«Яшьлек!» диеп масаймагыз, —
барыгыз кыйблагызга...
Көлгән идек без дә, валлаһ,
Төш кебек дөньягызда!..

*1972*

* * *

Юк, берни дә аермаган безне,
төнге ачык тәрәзәдән
ерак шәһәрләрнең тавышы килә,
йолдызлары яна җемелдәшеп,
әйтерсең лә
галәм ярына яккан учаклар!..

Юк берни дә аермаган безне, —
бал исләре аңкып торган көзне,
алмагачның яшел итәгенә
яшереп башларын,
черем итә балалары,
бәгырь алмалары!..
Яфрак җыры иңли безнең араларны.

Юк, берни дә аермаган безне,
капламаган таш диварлар,
йолдыз астындагы этажлар...
Юк, берни дә аермаган. (Без бит
шушы җир һәм
искән җилләр аша тоташлар!)

Чакрымнар аша искә алдың —
рәхәт булып китте, җилкендем,
аякларым тоймый җирне!
Менә син оныттың, — күңелем буш,
ташлап чыккан
йорт шикелле!..

Юк, берни дә аермаган безне, —
кагыла бар да: иткән изгелегең.
(«Хыянәтең булса — бигрәк тә!»)

Тотам сине — синең кыска дулкын
Бәгыремә кагыла, йөрәккә...

Юк, берни дә аермаган безне —
мәкер-ялган кабырчыкларына
әкәм-төкәм булып керсәк тә,
башны яшереп мендәр асларына,
аллы-гөлле төшләр күрсәк тә —
юк, берни дә аермаган безне...

Чынбарлыктан аермаган!..

*1976*

* * *

Табигатьтә бар да шулай төгәл! —
Гашыйкларга бүлеп бирелгән:
күзләр күзгә тәңгәл,
сүзләр — сүзгә,
иңнәр — иңгә,
иреннәр — иренгә...

Шулдыр аның иң камил төгәллеге:
и җанның — җанга,
канның канга тәңгәллеге!

## *Романс*

Кич,
шәүләләр озынайгач,
нәни шигем,
баганадай, юлга ята.

Икеләнү-упкын тора
йөрәгемнең яртысында...
Килер юлың — тып-тын гына
ак каеннар яктысында...

Бүгенге кич — безнең өчен
мәңгелектән безгә килгән.
Сагынуларым ташкынына
көймә булып кер син, иркәм.

Йолдыз булып төш син аңа
йә йөзеп йөр яфрак булып.
Давыллармын — җилем тимәс,
яратырмын саграк булып...

Ак каеннар яктысында
килер юлың тып-тын гына.

Әй, сөекле сының тора
икеләнү упкынында!..

*1970*

* * *

И, безнең беренче язлар,
якты сагышларында!..
Уяндык бәхет көенә,
тургай тавышларына!

Әй ул өй түрендә дөп-дөп
алма коелган таңнар!
Безне күреп (бәхетле пар!),
күккә егылды таллар!

Кара мәче чыкса, кире
китәйде кереп кенә.
Киссә кисә иде юлны
тик ап-ак өмет кенә.

Без чыгасын аларга соң
кем белдерергә тиеш, —
очрый иде пар чиләкләр
гел мөлдерәмә килеш!

Күренергә базмаганмы
әллә моңлы-зарлылар,
очрый иде каршыга гел
шат, бәхетле парлылар!

Ачык иде бар ишекләр,
балкыган тәрәзәләр...
Шулай булгандыр, Мәхәббәт,
безнең дә
дәрәҗәләр!

*1986*

## Йокла, инешем!

Йокла, минем елгам, агыйнешем,
ерак әле язга.
Ап-ак юрганыңа кызыл тәпи белән
кошлар шигырь язган!

Йокла әле, көмеш башыңны куй
тугай комнарына,
төштә күреп җәйне; ерак әле
тургай моңнарына...

Йокла әле, газиз инешем минем,
көмеш канлы сабыем.
Йокла инде! Бу ак киңлекләрдән сиңа
җәйне каян табыйм?!

Йокла, инешем, тиздән туар бит ул
Зур бәйрәм безнең дә:
гөлләр белән бергә минем йөзем
тирбәлер көзгеңдә...

Үги ана яфраклары сиңа
сузар сары утын...
Йокла инде, — кыскарт минем сине
юксыну минутын!..

Йокла, инешем, язга чаклы гына...
Җилләр әкият сөйләр...
Минем дә бит җанда калгып тора
оеп җәйге көйләр!..

*1980*

* * *

Җәяүле бураннар!
Җәяүле чакырымнар!
И ява юлыма
яшьлеккә чакырулар!

Чакырулар бар анда,
син сылу яр анда...
Адаштым шуңа мин
җәяүле буранда.

Адаштым мин, теләп,
ак давыл эчендә.
Адаштым, җан дустым,
мин синең өчен дә...

Илтәме тавышымны
яшьлекнең саф җиле?
Сагынсаң, минем күк,
син эзләп тап мине!

Юлларым, алиһәм,
Буранга уралган.
Югалыр төсле юл,
чыксам ул бураннан...

Сагынсаң, тап мине
Ак давыл эчендә.
Йә адаш (минем күк!)
син минем өчен дә.

*1988*

* * *

Мәхәббәтсез, утсыз һәм сөюсез
үткән көннәр — кысыр хыяллар...
Салам белән суга язган антлар,
китек бәхет — бәллүр-пыяла;

зәңгәр мираж, алтын пәрәвезләр,
чибәр гарип,
җәннәт төрмәсе,
татлы сагыз,
канатсыз җыр, өмет...
Тормыш-туйның чүпрәк бирнәсе.

Ком өстенә салган идеал-сарай,
шәрә табын,
көләч дивана,
муляж алма,
йолдыз күләгәсе...
Үрелеп кара, яле, син аңа!..

Барына да бүген хисап бирәм,
гомернең нәкъ исәп вакыты.
Сөю китер миңа! Кызыктырмый
фиргавеннең алтын табуты!

*1985*

* * *

Көзге кара төндә, мин — мосафир,
үзем белән калгач бергә-бер,
төн эченнән тавыш бирде бер кош:
«Сәлам!» — диде гүя кемгәдер...

Шомлы җилдә шаулап куйды әрем,
җылымса җил урман куеныннан
абагалар исен алып килде,
мезозойлар чоры ягыннан...

Төн түренә очып барышы иде, —
юл сорадым иптәш коңгыздан.
Карадым мин шунда нәкъ түбәмдә
чаткыланып янган йолдызга.

Таныйсыңмы әллә, Сириус, мине?
Мәңгелекнең якты мизгеле
тып-тын гына балкый, ә күңелгә
кычкырып ла янган шикелле ул,
еракта гы Максат шикелле!..

Галәм коесында талир таңкә
өмет бирде сүнгән күңелгә:
йөргән чакта шушы яссылыкта,
юк, ялгыз түгел,
ялгыз түгел кеше бу Җирдә!

*1987*

## Узды бәйрәм

Килде бәйрәм,
узды бәйрәм,
ду килеп,
тәрәзәдән йолдызларга җыр акты!
Дуслар бар да кояш иде табында,
стаканнар биетте дә җырлатты...

Төтен йөзә — зәңгәр томан бүлмәмдә,
төпкә чаклы ачык калды ишегем;
эреле-ваклы эзләр калды идәндә —
бәйрәмчәрәк автографы кешенең...

Узды бәйрәм,
узды шаулап, буранлап,
узды парад, дер селкетеп яшьлекне.
Җир хәстәре айнытты бит дусларны:
ничек, имеш, сөрдекме дә чәчтекме?

Булмадыкмы кысыр чәчәк түтәлдә,
җирдә яшәп, ни алдың да ни бирдең?
Кисәтми дә, искәртми дә ичмасам, —
урак өсте килеп җитте гомернең!

Узды бәйрәм.
Кояш бара төшлеккә.
Үстердекме,
нәрсәбез бар урырлык?
Җир әҗәтен кайтарырбыз тик шунда:
күтәрелсә бер орлыктан мең орлык!

*1965*

## Даһилар чишмәсе

Гёте эчкән чишмәләрдән эчәм…
*Сибгат Хәким*

Бу якларда сулар кайнап чыга,
Гёте эчкән… җиткән һәркемгә.
Үзе тапкан чишмәләрдән ятып
эчкән Сибгат, эчкән хакимнәр…

Мин Лермонтов чишмәсеннән эчәм,
Эчәм ятып, кемнәр эчмәсен?..
Тимер Суда* кайнар сулар эчтем,
искә алып Хәким чишмәсен,
хәтерләдем «Фазыл чишмәсе»н…

Гёте эчкән — киткән,
Лермонтов та…
Киткән алар. Ә без — ятимнәр.
Соңгы йотым ятимнәргә булсын,
диеп әйткән
Сибгат Хәкимнәр.
Көмеш сала суга ятимнәр…

*15 февраль, 1991*

* Тимер Су — Железноводск, анда Лермонтов эчкән чыганак бар.

* * *

Һавалар кәнсәләрендә
планерка бара.
Торып баса шунда рәис:
«Ходам, үзең кара —
йә яудырчы яңгырыңны,
йә күр шундый чара —
киптермә җирне,
адәмне
бер йотым судан да
аерма, кылчы игелек, —
аһлар чиктән ашты!..»
...Кабул булды теләк: шунда
җирне... туфан басты!..

*1992*



* * *

Яфрак шавы озата барды җәйне,
инде шул сызыктан ары — көз.
Үзәннәрдән, таудан бергә җыелып,
күч-күч булып яна сары төс.

Арыш исе аңкып торган яктан
ачыграк күренә кыр юлы.
Учарланып таллар калка чаттан —
башкайлары гына җыр тулы!

Август шавы! Күкләр биек, төпсез,
төсләр ачык, җете, мәгънәле,
язларымның аңа өмете чиксез —
ышанычлы аем, вәгъдәле!

Йолдызлары якты, дәшә күкләр —
каурыйларга һава тулган чак.
Көз күзенә карап, соңгы гөлләр
бар төсенә яна торган чак!

*

Күкләр биек, хыялларның
канатлары болыт яра!..
Узган җәйнең, киек каздай,
тавышы калган болыннарда.

*1971*

* * *

Юрый алмыйм синең киләчәкне,
әүлиялармыни без генә?
Җәең озын, кышың кыска синең,
бәхетле син! Тик көз... көз генә...

Хәтерләтә сине, тау артыннан
килгән төсле кояш сәламе!
Саубуллашу җыры булып, җанда
шаулый көзнең сары әләме...

Уйчанланып бакма көзгеләргә,
иел тонык көзге суларга.
Үтеп барган көзне сагын әле,
чыгып бергә үткән юлларга!

Мин үзем дә, көздәй яфрак коеп,
Үтеп барам сары эз белән...
Онытасы иде, көздән качып,
сукмагы шул аның —
без белгән!

*1988*

## *Аргы якка!*

Уелып-уелып аккан елга аша
дер калтырап торган тар басма.
Җилфер-җилфер әби килде ярга,
ялвару бар сүнгән караштa...

И чабаклар сикерә, әйтерсең лә
шаулы җәйне күреп калырга!..
«Аргы якка чыгар әле, улым!»
Чыктым аны каршы алырга.

«Аргы якка чыгыйм, аргы якка,
калсын бу яр сагынып сөйләргә...»
Шаулый июль, сары мәтрүшкәләр,
җырлый үзән бөтен көйләргә!

«Аргы якка, улым, аргы якка,
бирге якта бүтән моңлансын...»
Тар басмадан икәү, дер калтырап,
кичтек гүя Әҗәл елгасын.

Чыгып җиттек менә, күңеле булды...
Арык кулын куеп кашына,
карап тора инде аргы якка,
колак салып гомер агышына.

И ул яклар гүзәл! Дәшә тагын,
туеп булмас анда мең яшәп!
Очынып сайрый анда сандугачлар,
ул шомыртлар анда! Шау чәчәк!..

Яз мәхшәре кабат ул якларда.
Кирәк туя күреп калырга!
Яшьлеге дә теге ярда.
Тагын
кемнәр килсен чыгып алырга?!

Язлар гына кабатлана икән,
уртаклаштым ана сагышын...
Минем дә бит җилләр,
еллар аша
аргы якка чыгып барышым.

*1987*

# Мәхәббәт үләне

Җәй патшалык иткән чакта безнең бу якларда,
унҗиде сәгате суккач, үләннең шифасы күчә
тамыр, кыякларга...
Меңъяфраклар, утчәчәкләр күтәрелгән балкып,
дулкынлый дару гөлләре, тора бөтен кигълекләрдә
бал исләре аңкып!
Гөлбадраннар, татлы тамыр, сөтле чәчәк, чабыр...
Басу-болын — сихәтханә! Әҗәленә даруын да
кеше монда табар!
Чиксез кигълекләргә китеп, күк җиргә тоташа,
кем ул килә шул яклардан, айкап килә тирә-юньне,
килә офык аша?
Кигълекләрне иңли җыры, һаваларга аша.
Чибәр сеңел икән үзе, гүя күкләр фәрештәсе
Җиргә якынлаша!
Чәчәкләрне ерып килә, тик берсен дә өзми.
Үлән төпләренә иелә, нидер эзли тирә-юньнән,
сорадым мин түзми...
Ә ул әйтте:
«Тормышны башлар-башламас ташлады сөйгәнем.
Эзлим менә шуннан бирле, сагынуга дәва итеп,
Мәхәббәт үләнен.
Инде күпме җирләр үттем, ничә җәй киләмен...
Табалмыйм, эзләшегезче, эзләшегез әле, кешеләр,
Мәхәббәт үләнен!..»

*1984*

## *Кайталмадым*

*(Чакыру)*

Көттем.
Сары этнең өргәнен,
миңа каршы өрә-өрә йөгергәнен.
Саумы, Сарбай!
Ничәнче ел китте синең яшеңә?
Чишмә йөгереп керә һаман хәтергә!
Тагын бу елның бер яфрагы өзелде.
Тормыш сүрәсенең бер фигыле артты.
Кайталмадым.
Сагындым елларның алдагыларын.
...Матур конфеттилар гына сибеп
китмәдең син, күңелләргә шатлык катыш
сагыш сурәте дә элдең син бу ел!
Карлар ява. Календарьдан ап-ак көннәр
коела...
Кайталмадым. Гомеремнең яшел утарына —
әремнәр,
әрекмәннәр иленә,
тукранбашлы кырларыма, җиләкле
тауларыма,
төклетуралар җиренә, кондызлы күлләргә
бу елда...
Безнең Баллы Күл сазында узган елгы
ялгыз торна
исән микән? Парын тапты микән,
кайтты микән язын?
Кайталмадым.
Килә алмадың каршыма, Туган ягым.

Сагындым кара урманым, сирәгәйгән
туйралыгым, тугайдагы дегет чәчәкләре,

тавык күзе, чыпчык кузгалагы, торна
борчагы, эт эчәгесе, шайтан таякларыңа
хәтле! Гүя чакрымнар артында гына түгел,
вакытның аргы ягында, яланаяк, яланбаш
йолдыз асларында басып торам — синең
уйчан улың, хыял диңгезенең мәрмәр кыяларын,
галәмнең чиксез юлларын күреп
туялмаган бер инсаны, мосафиры җирнең!
Кайталмадым!..
Син дә миңа кайталмыйсың —
басу уртасында кулын болгап
саубуллашкан яшел ябалдашлы чал карама...
Кайталмадым еллар уртасында.
...Сез кайтыгыз — ерак елларның яшь,
сабый хатирәләре, дөньяга чык бөртеге
аша караган чаклар, хыял иртәләре!
Кайтыгыз сез, торна авазлары, иминлек
җыры — шатлык елларының якты сукмагыннан
үтсәк иде бергә — гомерләрдә!..
Кайтыгыз сез, мин кайталмаган
хыяллар, июнь киченең болын җырлары,
сабантуйларының сөю тулы уйчан моңнары,
йөгерек чишмәләрнең сихәте
булып, — безнең Яшьлек булып —
алга, гомерләрне дәвамларга!
Кайтыгыз сез — ата-анам аскан
тәүге бишек сиртмәсенең кабатланмас
иркәләве, Тормышның иң беренче чаңы,
Туу Җыры булып!

*1986*

## Ерак киткән саен...

Шушы көнем булды дисәм ярый
Күккә ашкан көнем,—
Ыру башым — бабам белән озак
саубуллашкан көнем.

Төшенгәндәй уйларының гүя
кырга сыймасына,
арыш дулкыннары килеп егыла, егыла
зират коймасына...

Еллар аның төз гәүдәсен инде
бераз куйган бөгеп.
Киез эшләпәдән, ак сакаллы үзе,
Хозыр Ильяс кебек.

Мин — ирләрчә горур, аңа сыенып
басып торуымда.
— Тап төшермә, улым, зур колаклы
Мачан ыруына.

Күп эшләде, аз яшәде,— ди ул,—
Шундый безнең нәсел,—
шәҗәрәмнең тармаклары кими,
ә яфраклар — яшел...

...Басып калды, күз яшьләре аша
карап кыйбласына.
Ул сөялеп басып калды шулай
зират коймасына...

Арыш юлы буйлап кайтып киттем,
бабам ерагая.
Барган саен кечерәйми үзе,
йөзе гел зурая...

Юл өстендә Шәҗәрә Тирәгем
җилсез шаулап тора, —
кылган гамәлемнең ниндилеген
бабам аңлап тора.

Күңелемә килгән һәрбер сүзем
аңлап тора бабам.
Ерак киткән саен, аңа үзем
якынаям һаман.

*2000*

## *Кышкы сөйләшүләр*

**1**

Өченче елгы карларны, дисең, әнкәй,
бар дип тә белмәгәнмен икән...
Быел менә күмде коймаларны.
Ниткән кыш булды бу, ниткән?!

Болытлар җиргә төштеме?
Кояш чыга гүя кар эченнән,
карга төшеп күмелә.
Дөньяны кар басты, улым,
кыш керде бугай күңелгә...

Ап-ак чәчләремдәй карлар,
алар миңа — ак мәңгелек.
Тавышымны йота киңлек,
бу кыштан сорыйм иминлек!

Төшерсәм иде инешкә
киләсе яз бәбкәләрен...
Чынга ашсын иде, димен,
көздән сиңа әйткәннәрем!

Бусагаларны кар күмгән.
Туган йортның уты һаман,
калтыранып, нигез җылысын
яклап калмак бу кышлардан...

Шартлап яна җәйге утын!
Каны белән җирне җылытып
каламы соң безнең токым,
салкын өреп кыш торганда
уртасында Идел-йортның?
Ап-ак карлар — җиргә түшәк.
Минем җылым кими, улым!..

**2**

Яшә дә, яшәп җылы бир
ягылмаган дөньяга...
Җил дә җил, әни,
минем кан
җилгә елышып ага!..
Юл белән кисешми Хыял, —
язларга якынлаша.
Юлны кисеп чыга Өмет,
Җан кайнар, салкын — кача!
Тоташ аклык җирдә, күктә —
ак океан уртасыннан,
күккә кереп киткәндәй юл —
югалам нокта сыман...
Тормыш океанында, әнкәй,
Юлның юк ансатлары.
Анда да бар — суыра җанны —
Бермуд гарасатлары!..
Хәтәр рифларга сугылам, —
борчыл син, тагын кыйнал:
йөрәгем кыска дулкында
тик сиңа бирә сигнал!

*1980*

## Дөньяга мәдхия

Күз тимәсен, ошбу Матурлыкны
бер Ходаем үзе бар иткән.
Моны белә һәрбер дөнья көткән,
сыңарларны ул бит пар иткән.

И бу җирнең җәннәт алмалары,
күккә тигез гүзәл баглары!
Шаулап калган дөм-дөм урманнары,
табигатьнең сабый чаклары!

И ул җанкисәкнең кайнар сулышы,
җиләк ирене, назлы аһлары,
төн куенында вәгъдә бирешүләр,
и өметле яшьлек чатлары!

И ул садә йөгерек чишмәләре,
ярдан аккан әрлән туфрагы,
туган җирнең әче әремнәре,
кычытканда чыклар ялтыравы!

И ул болын, анда чапкан колын,
дүрт фасылым, Гомер яфрагы!
И ул яшел тауда пешкән җиләк,
гомер юлым бөтен, өр-яңа!
Камыш-керфек аша баккан инеш —
мәдхиядер якты дөньяга!

И туганнар, дуслар, дошман, куштан,
котылган чак авыр бурычтан.
Барысын да кичерә күр син, фани,
тиргәсәң дә ярый берочтан.

Яшәт кенә бездәй бәндәләрең,
киендермә ләкин корычтан.
Язмыш иркендә бу тибрәнсен, дип,
ясама тик берүк йомычка!
Әнкәм-әткәм, туган телле итеп,
биргән безне олуг тормышка.
Дөнья көтә бездән…
Бер яшәвең
        керүдер ул
                бөек Бурычка!

*2000*

## Табигатькә җыр

*(Өзек)*

> …1627 елда соңгы тур сыеры үтерелгән… Лабрадор ярыматавында яшәгән канатсыз кошлар — гагаркалар, кешеләрдән качып, Фарер атауларына күчкәннәр… Сонгы зубр 1927 елда Алаус тавында атылган…
>
> *Табигать хроникасыннан*

Рәхмәт инде, безгә килеп җиткән кошлар,
канатлылар, канатсызлар — һәммәгезгә!
Кичеп ташкүмергә калган урманнарны,
кичеп боз чорларын, кеше куйган тозакларны,
очып-йөгереп, әмма кошлар булып, кош хәлендә
безнең чорга килеп, урман-кырны, күлне ямьләвегезгә!
Рәхмәт сиңа, канатсыз кош — елышып как кыяларга,
Лабрадорның җылы ярларыннан
килеп чыгып Атлантика карларына
гел канатсыз килеш төрле җирдә кышлап-җәйләп,
чакрымнар һәм вакыт буйлап йөгереп, җәяүләп,

омтылгансың безгә — яңа чорның таңнарына!
Ашкынгансыз икәү — калдырырга яңа токым,
җитәкләшеп мәхәббәттә, яшәп томшыкка томшык!
Сыенгансыз җылы эзләп салкын, юеш кыяларга,
карлы киңлекләрдән эзләгәнсез ышык...
Җитәкләшеп мәхәббәттә, гомер буе аерылмыйча...
Һәр адымыгыз сезнең — яшәү өчен тартыш!
Яңа чорның уртасына җитеп егылгансыз —
хушыгыз, башны башка куеп, мәңгелеккә калган пар кош!
Ә шулай да, ис китмичә тарихка һәм еллар узуына,
сезне чорлар алып килгән — Дарвин музеена.

ζ

Еллар томаны аша ишетәм ерак быргы җырын,
таныйм чорлар урманыннан чыккан тур сыерын!
Килә кешеләр каршысына, башын тотып чор җиленә:
япь-яшь курпы исләрен сизәдер борыны!..
Килә туры! Үзәннәр дә, кыя-таш та яшерә алмый —
таудай гәүдә күчеп бара яшел киңлекләрдә!
...Учак яна! Ит кирәк, ит! Ит тавына туры карап,
таш балтасын тотып чыга, күтәрелә бәндә!..
Учак яна... Ил куана: — Муенына кызыл элмәк кигез!
...Сагыныр өчен калыр тарихларда — ике метр мөгез!..
Сурәтенә карый һәркем җирдә соңгы турның.
Музейларда билгеләгән тарих бу турның да урынын!
Зур булу да кыен табигатьтә!
(Көчлеләрнең дошманы да зурдыр...)
...Кичер мине, кеше токымын, кичер... соңгы зубр!
Экспонат булып калдың бөек корбаннарга...
И бозавың үксеп елый сыман ерак урманнарда!..

*1972*

## *Көзге элегияләр*

### 1

Ике алма өзелеп төште таңда,
шушы көзнең соңгы алмалары.
Көзнең чыклы зәңгәр үләнендә
җәйнең саубуллашу тамгалары —

эзләр калган... Анда ике алма,
бер-берენә елышып, көзге таңда
көтеп ята гүя безне: «Тагын
килерләр, дип, икәү безнең янга...»

Бу бакчага кичке эңгер иңгәч,
җанлангандай эзләр сукмакларда.
Пар күләгә йөри таңга чаклы,
сөю сүзе сарыла куакларга...
Кошлар төшә җанга кунакларга.

Ике алма төсле ике йөрәк
аерым-аерым яна безнең көйрәп,
көзләр аша яңа еракларда...

### 2

Агыйнештә каен яфраклары
агып бара җәйдән тын гына.
Тирән качты елтыр чабаклары,
ургып калды төптә ком гына...

Китте җәйнең соңгы күбәләге —
җәйнең җаны — болыт артына.
Түбәнәйде күкнең түбәләре —
күксел пәрдә җиргә тартыла.

Куеланды җанда сагыну моңы,
кошлар моңы анда, сап-сары...
Очып үтә күктән талгын гына
җәйләр рухы, тургай сафлары...
Гомеремнең алтын чаклары!
Зәгъфрандай сары төстә янып

бетсә дә җәй, көтә илһамланып
Шигъриятнең алтын чатлары!

**3**

Бар да монда бакырдан һәм җиздән,
бакыр яфрак оча, җиз яфрак.
Килер вакыт, соңгы яфрак тиздән
очып китәр җилдә ялтырап...

Үрмәкүчләр кояш баскычыннан
көмеш киләп күккә сузганнар.
Карлыкканмы җилдә — баш очында
җиз быргысын өрә козгыннар...
Безнең өлешкә дә — җиз дә бакыр, —
бакырлардан калган өлешең.

Хәзинәнең инде төбе такыр,
өлешеңнән киткәч көмешең.
Шушы синең көздән өлешең...
Тармакларда көләч сазлар тынган,

өмет булып, туар яз артында
яшь яфраклар тора килешеп...

**4**

Туган якның шаулап торган алтын көзе.
Сары ука чугын таккан чаганнар.

Болдином бу! Тиздән анда яшь Онегин
Татьянага соңгы хатын тәмамлар.

Ә хатлары — сары яфрак, почтасы — җил,
килә-китә өй түренә заманнар...

Мин дә инде тәмамлармын көзге җырны,
җил — флейта алып китә моңнарны.
Каләмемне манып көзләр сарысына,
искә алдым онытылган елларны...

Күкрәде дә күктән үтте язгы болыт,
күптән үттек Онегиннар яшеннән,
әллә инде чал анамның назы булып,
сары җилләр сыйпап үтте чәчемнән,
саклагандай мине күкрәү-яшеннән...

Үткәннәрнең якты моңы калган монда,
гомеремнең көзге сары аланында
шат елларым яфрак булып чәчелгән.

**5**

Төшкә керә ап-ак пароходлар,
төнге Кама өстен ярган утлар.

Гудок бирә алар өздереп,
килеп җитүләрен сиздереп.

Үтә һаман туктар турысын,
тукталышын тапмый, борылышын...

Тукталмыйча үтә янымнан, —
яшьлек пристане алынган.

*1982*

* * *

Нинди сагыш сары яланнарда —
дөнья яралганнан
килгән сагышлармы әллә җирдә
бу төшкә җыйналган?

Нинди кошлар сөйләшәләр анда
яшел туйралыкта?
Җитмәде лә вакыт, җыры аша
исемен аерырлык та!

Гүли урман, күксел усаклыклар
ерак хыял сыман...
Шаулап үтте җәем, моңнар төяп,
яшел олау сыман!

Көзге җилләр, урманнарны сыгып,
кая юнәләсез?
Юлларымда — болыт тауларының
җиңел күләгәсе...

Кырлар буйлап оча «эт кояшы» —
соңгы балкыш кына...
Артымнан нидер кычкырды —
бары бер кош кына...

*1980*

## *Мәхәббәт алиһәсе*

Син ерак язда нур кебек
калдың болын фонында...
Күксел күзләр тора көлеп
бәхетле офыгында!..

Барысы да якын иде —
калдымы ятка бары —
ап-ак иңендәге миңе,
бриллиант алкалары?

Төннәрен ялкын сулаган
ул кайнар вәгъдәләре?
Сөюдән сулыгып елаган
ул сылу гәүдәләре?..

Шул елда калдың, яшисең
бары шул чакта гына.
Гүя шаяртып дәшмисең,
күмелеп чатка гына...
Тор әле шунда, кузгалма,
язгы болын фонында.
Күзләрең көлсен, кыз бала,
азатлык офыгында!
Тор әле шунда, шунда тор,
Мәхәббәт алиһәсе!
Җанымның килә җаныңа
сыенып ял итәсе!

*1986*

* * *

Җыр — ул кешенең кан авазы,
рух сурәте.
Чикли алмый аның үтәр юлын
беркем кодрәте.

Кайта җырлар
канлы кырлар аша,
үтеп тимерчыбык киртәләрне,
йозакларны, тозакларны,
овчаркалар-этләр кордонын,
үтеп сакларны,
кара зиндан-лабиринтлар аша
чыга кояшка!

Кешеләр йөрәгенә тоташа.

## Җирән алашага

Нигә, аткай, мәэюс карыйсың син,
аратаңда солың юк мәллә?
Ычкынганда базар бәяләре,
ашамыйча гына тук мәллә?

Нигә, бахбай, мәэюс карыйсың син,
Тагарагың төбе такырмы?
Сабырлыкның төбе — алтын, диеп,
безне кемнәр алга чакырды?

Аердылар хәтфә басулардан,
каердылар Туклык чорыннан...
Киләчәкләр күренмәслек булгач,
китмәс идек сөтле болыннан!

Коммунизм кырларына карап,
Чыбыркылап сине бер гасыр,
тугардык без сине, тау тарттырып,
тәртәләрне кире боргачтын...

Менә, малкай, юллар кирегә таба,
әйдә, бахбай, юырт чак кына.
Солы уртлап алда ял итәрбез,
офыккача җиталсак кына...

Офыкларга, милай, ерак ласа, —
Болыт кача, болыт чигенә!
Максатларны узып, Ходай кушса,
бер җитәрбез дөнья читенә!..

Әйдә, малкай, яшел өметләрне
чабып салыйк арба төбенә.
Ашаган малда өмет бар дигән сүз
моңлы җырдай тора күңелдә...

Ялдан сыйпап кына бушбугазлар
яшәмәсен безнең хисапка,
йә үч итеп, барган хуттан, кереп
китик мәллә Кызыл китапка?!

*1992*

* * *

*«Табигать дәфтәре»ннән*

Күрегезче, кошлар оча белми,
мин гомергә җирдә — очалмыйм.
Очалмаса, кошлар җиргә төшә,
ә мин менә күккә күчалмыйм.
Очкан кошлар, биеклектән карап,
күрә мине — ике аяклы.
Канатым юк,— күктә юллар иркен! —
кошлар — хәтта җирдә канатлы.
Мин, җир кошы, сибәм кошларга җим,
кошлар мине дәшә күкләргә.
Канатлы да алар, аяклы да...
Уйласаң, бу — гыйбрәт күпләргә!
Очканнардан көнли күпләр әнә,
канат очын Җырның кисәләр.
Гаҗәпләнмим, шуышырга туган
елан оча бүген, дисәләр!..
Елан очар анысы, аннан булыр!..
Аптырыйм тик аптеризмга*.
Җырын җырлап бетми җиргә төшкән
очар кошка аптырыйсың да...
Сөю байрагының гербы булып,
җырдан җырга килгәч макталып,
җем-җем түшле әнә бер күгәрчен
трамвайга үлгән тапталып!..

*1990*

*Аптеризм — кошларның очу сәләтен югалтуы.

## Шигырьнең килүе

...Шигырь ул... сөйгән яр кеби
Вакытын белә микән, —
Җиде төн урталарында
Сагынып килә икән!

Аз гына... тидерә иренен, —
Дулкыны кагыла йөзгә,
Керфекләр китә сискәнеп, —
Сулышы аның үзгә!..

...Сикереп торам йокымнан:
«Күңелгә чиртте кемнәр?..»
Уйларны юрган очырды,
Йокымны йотты... мендәр!

Агылды хисләр кәгазьгә, —
Хыялның ак ярына...
Җемелдәп койды инешләр
Күңелем океанына!..

*28 февраль, 2004*

## Бүре аулау

Усаклыкта, кордоннарда очты бәсләр, —
оран салды ау быргысы дөньяга.
— Узган төндә Ак Бәрәнне Бүре буган, —
диде Авыл, — яу чыгабыз без аңа!
Кара инде, — дүрт аяклы мародерны, —
түбә тишеп төшкәннәр бит малларга!
Ит бәһасе кыен чакта — Ак Бәрәнне!.. —
Кирәк иде, явыз, моны аңларга!
Җыелдылар илнең изге бурзайлары,
чыкты ирләр мылтык киеп иңнәргә.
Мөмкин моны Наполеонга яу чыгуга,
Бөек Ватан ызгышына тиңләргә!
Кузгалдылар илнең асыл егетләре, —
кемне кайдан, кемнәр җыеп бетергән!..
Әрәмәдә, тугай, Мирәт өсләрендә
бүреләрнең котын алып Эт өрә!
Яланнарга сибелеп китте эт көтүе,
күктә оча — дүрт канатка! — вертолет!
«Һәр канатлы — фәрештә» дип, үз-үзләрен,
очкан саен үзләреннән үртәлеп!
Яуга чыкты сәнәкләр вә табагачлар,
чормадагы чабагачлар кузгалды:
«Бүре нәселен корыту кирәк!
Бетсен Бүре!»
Ярсулардан томаланды күз алды.
Капкаларын бәреп чыкты сугымчылар,
бу бәйгегә өстәми дә әллә ни, —
кырый йорттан саташыпмы, аң-таң булып,
уклау тотып килеп чыккан бер әби!..
Каян килгән шулкадәрле хөсет кешегә,
Шулкадәр үч бу адәми җаннарга? —
Авылның бар мал-мөлкәтен кырганда да,

төшмәс иде мондый ләгънәт җанварга!
Кырылдылар, сорыкайлар, әрдәләнеп —
олау-олау бүре мәете ташылды...
Бетте Бүре. Тирә-юньдә тынды аваз,
Этләрнең дә ачулары басылды.
Узды олуг чистарту вә агония,
Кешеләр вә Этләр халкы — канәгатьләр.
Кызыл китап битләреннән улый Бүре,
укый Бүре заманына ләгънәтләр.
Тынды дөнья. Җиңү, хаклык тантанасы, —
унлап бүре чыгарылды бер өйдән.
Бар торганы бер Ак Бәрән иде юкса,
үч алулар, нәфес булды — эредән...
Бүре дә юк! Инде гавәм аптырашта —
кешеләрне аера алмый Бүредән.

*1993*

## *Кичке кошлар*

Эңгер төшкәндә,
кичке шәфәкъ фонында,
күмәкләшеп, тезелеп
кайта башлый кичке кошлар төркеме;
кайталар, кайталар...

Бу күренеш гаҗәпсетә соң кемне?

Шундый кичләрдә,
һич югында,
туа җанда шундый сораулар:
кайда куна икән соң алар?
Һәрберсенең үз оясы бармы?
Һәркайсының үз талы?
Төнне кайда үткәрәләр тукталып?

Яңгырлы кичләрдә, эңгер төшкәндә,
күмәк кошлар төркемедәй,
әнә шулай
кайталар минем уйларым...

Әйләнәләр
күк томанлы Ядкяр суы буйларын,
китәләр кереп тагын шәфәкъ сызыгына,
үткәннәрнең офыгына...
Күмелеп югалалар тып-тын гына...

Шулай йөри минем җир өстендә,
чит күк асларында, гизеп җирне,
ерак таулар артында, шәфәкъ батканда
җавап табалмаган сорауларым —
әйләнәләр дөньяларны!

Кичке кошлар төркемедәй
әйләнәләр минем сорауларым.
Кичәләр тагын
кыен вакыт сынауларын...

Мең яшәп тә чигенә чыгалмаслык
бу дөньяга
күп очырдым бугай мин аларны!..
Табалармы кыйблаларын?

Яңгырларда кичке кошлар кайта,
кичке кошлар —
бу тормышка сабый чактан
җыелган сорауларым...

*1973*

## *Иртәнге төш*

Таң алдыннан сызылып төшкә керде
моңлы нигез-оя.
Ак йон эрли, имеш, әни... Түрдә
тупыл мамык коя.

Иске сәгать йөри элеккечә.
Кич. Алынган утлар...
Оясыннан, ябагасын коеп,
чыгып килә Мохтар.

Үзем уйлыйм шунда: өн булсачы.
Бу бит, дип, төш кенә!
Тәгәрәп менеп килә ай
Байтирәк* өстеннән.

Айны зурлап дәшә гүя Яншык,
Укмас укый дога.
Күктә дога, дога... Мине хәтер
аягымнан ега.

Карт эт шунда телгә килә гүя:
«Оныттың ник безне?
Үлеп тә, мин ничә еллар буе
Саклыйм шул нигезне...»

Ак яулыктан утыра моңсу әнкәй,
бүгенгедәй, түрдә:
«Менә кайттым әле, Сезнең яннан
бүтән китмәм бер дә...»

---

* Байтирәк, Яншык, Укмас — Балык Бистәсе районы авыллары.

Орчык эрли әнкәй, мин яшь, имеш,
ак йон, тәрәш, каба...
Әйтерсең ул, эрләп, шул кабадан
ап-ак чәчен сава.

«Оекбашың тузган, улым, — ди ул, —
бирче, бәйлим үкчә.
Кыш та килер, улым, туңарсың бит,
дөнья кышка күчсә.

Оекбашлар бәйләп, сиңа миндәй
кемнәр бирер бүтән?..»
Мин уяндым.

Әнкәй теткән йондай
карлар коела күктән.
Күзләремне йомам.
Күрмәмме дип
кабат шул ук төшне...

Кабатланчы кабат төшләремдә,
иң кадерле Кеше!
...Ак төш сыман карлар килә, килә —
ак мәңгелек төсле!..

*1992*

* * *

Җете иде әле гөлнең таҗы,
яшь йолдызым яшел болында...
Күңелемдә балкып калды назы,
җан җылысы янды кулымда.

Гөлләр белән болын бәхилләшә,
күбәләкләр китә эңгергә.
Шат йолдыздай яшьлек, нурын чәчеп,
китеп барды... бөтен гомергә!

Җиләс җилдә уйнап моңлы сазын,
сусәрделәр инде кылганнар...
Тузганаклар булып очты, язын
чәчәк булып җиргә кунганнар.

*1999*

* * *

Кичке кояш
            уйчан баткан чакта,
бөтен җилләр тына,
кабатланып тора
            изге бер йола:

уйсу җиргә ятып,
үзәннәрдә мүкәләп,
ташлар дога кыла,
ташлар дога кыла:

«Кояш, ташлама,
чык иртәгә, синсез
безнең газиз башлар
көнне ничек башлар?..»
Кызарып баеган кояшка
сәҗдә кылып,
таш гомерләрен,
гомерлек таш тынлыкларын
багышлыйлар ташлар.

Изге ахшам. Кояш сүнә.
Кузгалалар ташлар...

*2000*

* * *

Чал иһрамнар[1] баккан кыйблага, —
Нәрсә көтә чиксез дөньяда?..
Күләгәләр сары комнарда,
Офыклардан кайнар җил ага...
Чал иһрамнар баккан кыйблага.

Нәрсә көтә котсыз дөньяда, —
Яна гөлтләп сахра кояшы...
Сәфәрчегә һәрчак — җил каршы,
Төн кичә дә, таңда уяна, —
Нәрсә көтә котсыз дөньяда?..

Күләгәләр сары комнарда.
Кем кузгатыр өнсез тынлыкны,
Мәңгелеккә иңгән коллыкны? —
Сузылып ята эзсез юлларда,
Күләгәләр сары комнарда...

Офыклардан кайнар җил ага,
Чал сфинкс теле дәшергә:
«И, бер мизгел кайтып яшәргә
Фиргавеннәр исән дөньяга!..»
Офыклардан кайнар җил ага...

Чал иһрамнар баккан кыйблага,
Тынга калган әрвахлар сыман.
Кемнәренме көтәләр юлдан:
«Әлләме, дип, коллар уяна?!»
Чал иһрамнар баккан кыйблага...

*21 март, 2004*

[1] Иһрам — пирамида.

# *Контрастлар*

## I

Үсәләр нәзек кенә гөлләр дә,
имәннәр дә җирдә.
Кабилләр дә, Хаиннәр дә яши —
җир тарсынмый бер дә.

Таулар тау белән кавыша,
сулар ага үргә...
Җирдә агачлар һәм кешеләр
картаялар бергә.

## II

Шуышып үтә җирдән берәүләре,
дөнья кичә кайсы үрмәләп...
Очып, шуышып, йөзеп булса да бит,
һәркем тели алга, түргәрәк!

Бу җиһанның камил бөтенлеген
тотып тора алар бергәләп.
...Яңа балкып Сәвер йолдызлыгы,
дөнья буйлап оча күбәләк!

*1985*

* * *

Ник, каләмем, сөйрәләсең,
«тарта» алмыйсың мәллә?
Тарт инде, оял, каләмем,
ичмасам, мине жәллә!

Мин сиңа ябыштым әле, —
син минем төрән-сука.
Бит әнә сөргәннәр әле
корыч каләмнәр юкта!..

Ябышкан заман агае,
әйтерсең каләмгә ул, —
арык ат белән чыгарган
шигырен галәмгә ул!

Сөйрәлмә, каләм, хак әйтәм, —
сөйрәлмәгән бит агай...
Әнә ничек сөреп бара
безнең Толстой бабай!..

*1988*

# Тукай катламы

«Шигырь» дигән җәүһәр эзләүчеләр,
Тукай катламына төшегез.
Шул бит безнең ярты юлга җитеп
тәмамланмый калган эшебез.

Йә, син дә төш, мөтәшагыйрь, шунда —
Тукай, бәлки, талант өләшер;
Тукай данына коенып яшәүчегә,
исемен атап, бәлки, эндәшер?!

Ерак икән Тукай катламына —
кәйләләргә каты бу катлам!
Айлар-еллар тоташ чапканда да
җитеп булмый, гомер — бер саплам!

Җитми икән көчегез, бау ишегез —
комнан, йоннан, ялган моңнардан...
Кеше киткәч кенә, бушбугазлар
мәдхияләр язып шомарган...

Тирән катламнардан, шахтер сыман,
кем хаклыкны өскә чыгарган?
Янып төшкән тыгыз катламнарга,
туры калып гаярь җисеменә,

туры барган, туры ярган Тукай,
«Туры» булып калган исеме дә.

Без дә төшик Тукай катламына,
(Үземә дә дәшәм бу чакта.)
Шигырь уты кемгә — гел учакта,
ә кемгәдер — җылы кочакта.

Төшегез сез Тукай катламына,
намус катламына төшегез,
дөрләтегез сүнгән шигъри утны,
Гаделлекнең кулын чишегез!

Яшь варислар, сезнең киләчәк бу —
Остазлардан олы әманәт:
җитегез сез Тукай катламына,
җаннарыбыз калсын канәгать!

Шигырь үрүчеләр! Җиргә бөек
Пәйгамбәрне биргән бу айда
күп шаулыйбыз бугай, әллә азмы?
Бирик мәллә сүзне Тукайга?!

*2000*

## *Болдино – Кырлай*

...Тәрәзәдә көзге яңгыр шавы,
өй түрендә сары чаганнар –
Пушкин Болдиносы!
Шигъриятнең шул мизгелен сагынып,
алышына җирдә заманнар!

...Наталиен сагына...
Бер мизгелдә аны күрер өчен
бирер иде инде җанын да!
Пушкинга соң җиңел булган димсең?
Тифлы Арзамаслар артында
сагыш кордоннары,
юллар өзек,
тоткын халатыдай
буй-буй шлагбаумнар төшә юлга,
җаны дөрли зәңгәр ялкында!

Тәрәзәдә – чаган яфраклары,
өлгеләрдә – яңгыр сипкеле.
Тама,
тама,
сызылып агып
төшә,
сагышлы күз яше шикелле!..

Ничәнче кат борыла
Болдинога, –
лабиринтлар ята арада.
Мәхәббәтем, юллар ябык сиңа,
О, Натали, бөек сөю, җанны арала!..

Тарихларда балкыр Иҗат өчен
нинди тылсым биргән бу көзгә?!

...Өстәленә иелә, каләменнән
йөрәк каны савыла кәгазьгә!

...Пушкин Болдиносы!
Үзе мисал
Иҗат дигән бөек хаҗларга!
Шагыйрь булсаң,
Илне сөюеңне
алыштырма алтын таҗларга! —
Шагыйрьләрнең Йөрәк Манифесты,
Тукайларның бөек Иманы!
Үләрсең дә онытылырсың үзең.
Әмма онытылыр дип әйтмә син аны!
Кара төндә үз кыйбласын табу
Тукайларга ансат булганмы?
Бармы, шагыйрь, синең үз Болдиноң?
Бармы, шагыйрь, шигъри Кырлаең?
Кыен заманнарда
үз халкыңа
илһам бирсен
Иҗат сорнаең!

*1988*

# *Кайтаваз*

*Шагыйрь Хәсән Туфан һәм башка*
*репрессия корбаннары ядкяренә*

...Кайтып җитте бугай... Алда — Идел.
Кычкырды ул аргы ярларга.
Тавышы булмаса да, кайтавазы
ишетелер җаны барларга!

«Чәчәк аткан ласа туган ярлар!
Сездән, гөлләр, ерак кителде...»
Ышанмыйча, аң-таң булып торды
бер Фәтхулла хәзрәт шикелле!

Чал чәчләрен сыйпый Идел җиле,
шаулый таллар — аны сагынган!
«Сагыну тулы йөрәгемне, канәт,
алып кайттым Себер ягыннан.

Төштә түгел бугай, сезне уйлап,
далаларда учак якканым?..
Арыдым бугай, яшел чатырыңда
ял иттерче, сеңелем, ак каен!

Ялалардан мине яклый алдың
бер син генә, җирем, син генә!..
И йөгерә җилдә ромашкалар,
акчарлаклар куна иңенә!

Бу төшемме, юк ла, бар иде лә
тайгак кичүләрең, Ватаным!
И Шигърият, зынҗыр кыса җанны,
әмере белән «Бөек ата»ның!

«Гаебең юкмы? Кирәк булса — табылыр!
Гаепле син — илең сөйгәнгә!..»
Баш имәгән күпме пакь җаннарның
каны тамды бетон идәнгә!

Җиңгән кыяфәттә әйтте аңа
Беләкләре йөнтәс абзыйлар:
«Бу шагыйрьләр — ахмак! Каләм белән
үзләренә кабер казыйлар...»

Көчләп кулга каләм тоттырдылар,
бер-бер артлы биреп боерыкны:
— Мин Кировны үтердем, дип яз син,
үтердем, дип яз син, Кировны!

Ә язмагач, янә йодрык белән
суктылар да егып аяктан,
күтәрелгәч, тагын сугып егып,
күтәрделәр кабат бер яктан...

«Нинди вәхшәт! — диеп сыкранды җан,—
социализм җиңгән илдә дә!..»
Кайтыр кошлар... Канат очларыннан
каннар тамар
Черек күлгә дә...
Кар сахрасын үтеп китте шулай,—
җан богаулы,
салкын ятаклар...
Сакласа, тик халык хәтере саклар,—
сыйдыра алмас моны китаплар!..
...Кайтып җитте бугай... Бу — төш түгел!
Кычкырды ул аргы ярларга!..

Идел өсләрендә кайтавазы...
Бу — кисәтү
җаны барларга!..

*1988*

## *Итил-су монологы*

Мин ерактан киләм,
агып ятам, Ватан,
бер үзәнең миннән күпсенмә!
Бер Ходам һәм синең хакка агам, —
акмыйм җирдә вакыт үтсенгә,
күпсенмә!
Бөек еллар аша, бормаланып,
агып керәм
олуг Хәтер булып мин сезгә...
Каршыгызга тугайланып киләм,
тарих юлын
гел тәкрарлап агам мин сезгә!
Илдәшләр дә килде, килмешәкләр дә,
ишкәкләр дә, саллы көпчәкләр дә
кыйнадылар суым — шап та шоп!
Яу-баскыннар төшә исләремә...
Көзге җилдә туңып, өсләремә
күк чатырын
тартам
саташып!
Челтер-челтер йолдызларын коеп,
иңнәремдә күк ефәген тоеп,
убылып агам тирән уйларга.
Буйдин-буйга
Илне иңләп — юлда,
ә бер очым —
әллә... әү капларда!
Сөңгеләр вә уклар,
чуен туплар
тиште, кисте бәгырь суымны!
Ә мин менә
агып яшим әле,

үзгәртмәдем
салган юлымны!
Ак-карага Илне мин бүлмәдем
(беркемне дә кимсетмәдем).
Кемдер әйтте:
«Тот та бүлгәлә!..»
Кемнәр бүлгән — аның
вөҗданы үлгән:
юл башымнан алып —
Хазаргача —
суларымда тәре тирбәлә!
Аккан саен, моңга мөлдерәп тулам,
җилләр җырын тыңлап онытылам,
чишмә башы — гомер кояшым.
Моңнар белән онытылып та куям
суларымны
кай җирләргә илтеп коясым.
Янган чакта күктә Кояш-туграм
Үзәннәрем минем — яшел урам,
мөлдер-мөлдер ярым — агып торам —
һич кенә юк
шушы җирдә агып туясым!

*1993*

* * *

Әйтерсең мин сезгә ләгънәт ташлаган,
түгелмени мәдхия багышлаган?..

Ярый, тәкъсир, ярамадым сезләргә —
насыйб улсын яңаларын эзләргә.

Кудың, ыруым, салкын ташка сөялдем,
бардыр, ахры, бер сөйкемсез сөягем...

Бер әйбәткә мең гайбәте табылды, —
бар ишекләр йөзен чытып ябылды.

Әллә, димен, эчкән суың әрәмме?
Гүя җирнең мин бер ятим бәрәне.

Синең дә бит тотылгандай Ай йөзең —
кырын бастың миңа, сөрмәле күзем!

Бетте бәхеткә ымсынган көннәр дип,
ачы әрем утап йөрим, гөлләр дип...

И фанием, баштан сыйпап кочмасаң,
исеңә ал бу балаңны, ичмасам.

*2000*

## *Юлда*

Юлымда мин. Гомер буе
үр менә атым.
Бардыр, түбән төшкән чакта,
утырыр хаккым?

Ә син, энем, үр төшкәндә
чабасың арттан.
Юк шул синең үргә каршы
җигелеп тарткан!

Ат та арык, үр менгәндә
утырып барма.
Сулаганда да шыгырдый
иске бу арба...

Юл читләре яшел борчак,
өзим кузагын.
Айкый малкай яшел кырны,
борып күз агын...

Ике яклап агылып кала,
и яшел борчак!..
Бездә — корсак... Ә малкайда
дуга, ыңгырчак...

Бушан, камыт, чөелдерек,
бушан, ыңгырчак, —
мин, малкайны сөендереп,
ашатам борчак.

Рәхмәт әйтеп селки башын,
гүя эш кырып,
нәрсә дисең, и җанашым
куя пошкырып...

Шулай, энем, җитте бугай
нокта куяр чак.
Онытма син, авыз иттек
без берчак борчак.

*2000*

## Чигенәбез

...Без әле чигенәбез...
*Индус Таһиров*

Чигенәбез, әйе, чигенәбез,
Җиттек инде упкын чигенә без,
Күперләрне берүк яндырмыйк!
Аргы якка кабат чыгасыдыр,
Өметләрне кабызып калдырыйк...

Тубый[1] төбенә утырып көч җыйнарбыз,
Исән генә булсын Илгенәбез.
Шәһәрләрне ташлап чигенгәндәй,
Кануннарны ташлап чигенәбез...

Шулай, Тукай, «хөр Русияһ!» — диеп,
Телебезне тешләп чигенәбез,
Бер Котдусов[2], ул да безнең дәдәй,
Мәскәүләрен ягып чигенгәндәй,

[1] Тубый агач — борынгы мөнәҗәттән.
[2] Котдусов — Кутузов татар булган дигәнгә ишарә.

Чигенәбез, — өн бу! — чигенәбез...
Мөнбәрләрдән әйтмик ни генә без,
Килеп җиттек... чикнең... чигенә без...
Кереп киттек...
Мәскәү җиңенә без!

Президентка, Сезгә дәшәм, Путин,
Телен киссәң, милләт кала ятим, —
Кай имляда языйм, әллә латин...
(Тел дә сора, инде, мин сиңайтим!)
Каләмемне манып бәгырьгә...
Чигенәбез, — язмыйм хәзергә!..

Җиңеләбез мәллә? Җиңелмәбез! —
Тугарсалар,
кабат җигеләбез!..
Казаннарда күпме кайнасак та,
Без пешмәгән һаман,
чи генә без!..
Җитсәк җиттек чикнең чигенә без,
Артта — упкын...
Хут юк.
Чигенмәбез!

*4 март, 2004.*

* * *

Син дә килдеңме дөньяга,
И, нихәл, энем генәм!
Умырзаялар да котлый
бәхетле көнең белән.
(Бәхетлеме — кем белгән?)

Син дә килдең ич дөньяга!
Мин синнән алдан килдем.
Мин килеп исем алганда,
син, энем, кайда идең?

Айда идеңме син, бүки,
син әллә кайда идең.
Син килгәч, әйдә, бергәләп,
миннән бик калма, дидем.

Калышма, нәнә, бирешмә,
би...и...ик ерак барасы бар.
Көрәшеп, яшәү хакына
дөньясын аласы бар!

*2000*

## *Язгы кызый*

### I

Мыеклы кыз, кара оеклы кыз,
елмаясың нигә?
Сүрән идең. Бүген дәртең ташкан, —
барыбер яз җиңә!

Кичке серле сукмаклардан сиңа
сөю килмәс, димә.
Хәтта туң түмгәкләргә дә
язларын җан иңә!

Барыбер ул сине суырып ала,
ярсып-шашып үбә.
Язгы суттан хәтта каеннарның
ап-ак карыны күбә.

Хыял җилкәнең саф җилләр
яңа юлга бормыш.
Яшерен генә дымлы карынында
бөреләнә Тормыш.

Кар астына төшә дә яз уты,
йөгерә башлый сулар.
Җирдә-күктә назлы көйләү генә
көйли кавышулар!..

Чия иренле кыз, син үзең дә
язгы дәртне тоеп
елмаясың. Хәтта шыткан ласа
сыек кына мыек...

Бәхетле бул, язгы кызый, сиңа
Дөнья сөеп карый.
Табан асларына ятып җырлый
язның соңгы кары!
Син гүзәлнең табаннарын кочып
еласаң да... ярый.

## II

Синең ташкын... Синең соңгы күкрәү
коеп үтте шаулап офыкка...
Калды бары сине сагынып тетрәү —
әфсеннәрем җилсен синең эздән,
догаларым җитсен — болытка!..

* * *

Менә кайда киңлек! Йөз чакрымнар
уч төбендә ята!..
Тау битләрен яңгыр яңа юган,
юллар зәңгәрләнеп калган хәтта.

Шуларның мин берсен сайлыйм, анысы
мине туган якка алып кайта.
Тау битенә ятам. Йөземә иелә кылган,
югалдым ла ак кылганнар арасында.
Җәй өлгерде. Шаулый, җем-җем итә
җиләк чәчәкләре — паласында.

Калыйм шушы җирдә. Кузгалмыйча,
җирем-күгем гомер тату якта.
Табигатьнең елышып күкрәгенә
фани тормыш торсын — теге якта.

Күпме еллар кичеп, шушы тауда
мәдхияләр язып, күпме яшәп,
күз алдыма кайдан калкып чыкты
моңа чаклы бер күрмәгән чәчәк?!

Шул чәчәкне әнкәм каберенә
куйдым. Калдым онытып дөньясын...
Тау астында, Иске Зират итәгендә,
йомран сызгырды.
Әле яңа казыган оясы.
Җир малае! Син дә хәбәр салдың...
Яшисеңме син дә, и якташым?
Иңкү тулып йөгерә сүсән уты,
ак диңгезе уйный акбашның...
Туган җиргә бер орыну хисе,—
тәнең буйлап күчә изге тойгы!
Тамырлары тирән, бик еракта...

Изгеләр өстендә яңгыр койды,
аерылды болытлар ике якка,
гөлдер-гөлдер китте җылы күкрәү.
Юл уңае кайтып килешемә,
тукталдым да Изгеләр чишмәсенә,
уелып аккан Агыйнешемә,
сәҗдә кылдым, күкрәүләргә кушылып:
Изге җирем!
Насыйп булсын
        көмеш салырга
                синең өлешеңә!
Тудык!
Инде яшәргәдер, шөкер.
Күңел буам ерылды. Анда акты кояш.
Күк тирбәлде таллар кочагында.
Ишегалды тып-тын. Чыкмый әнкәй...
Ут тергезәм
        сүнгән учагымда...
Балачагым!
Тәрбели өсләреннән
        ничә еллар
каршы йөгерә миңа!..

*2000*

## Сират

Олы юл бу. Заман төсе:
чатта бөкре карчык.
Юлны кичеп чыгалмыйча
тора, мескен, басып.

Аңа гүя Сират күпере —
бу ташкынны кичү...
Нинди чорга, упкынгамы
бу ашкынып күчү?

Җилдерәләр «сигезле»ләр,
«тугызлы»лар, «туз»лар...
Тоташ ташкын. Машинада
егетләр вә кызлар.

Тәрәзәдә чагылып кала
елмаюлы йөзләр...
Җилдерәләр «тугызлы»лар,
элдертә «сигез»ләр...

Тоташ ташкын. Төялгәннәр
кызлар вә егетләр.
Дөньяны басып алдымы
машина вә ...этләр?!

Як-ягымда мутант кавем, —
ниткән чор бу, ниткән?
Һәр адым — якалаш! Әллә
ахырзаман җиткән?

Ниләр көтәбез соң күктән,
алда ниләр көткән?
Әллә инде без көткәннәр
күптән үтеп киткән?..

Юлны кичеп үтәлмичә,
мескен бөкре карчык,
бүгенгегә һәйкәл сыман,
тора һаман басып...

* * *

Нигә шигырь?
Тормыш шигырьдән дә
катлаулырак икән ләбаса.
Нигә мунча, нигә ләүкә сиңа,
төнлегеңдә йолдыз янмаса?

Нигә яздым шигырь?
Җанны сыгып, —
бу заманга шигырь — ни аңа?
Ходай үзе гарешләрдән сөргән
явыз кавем кайта дөньяга.

Без китәбез,
җырлый шовинистлар,
сатаналар килә —
өр-яңа!

# Эчтәлек

*Автордан* . . . . . 5
«Татар иртәсе»нә кереш . . . . . 6

**Татар иртәсе**

Ак өметләр ява… . . . . . 8
Фараз . . . . . 9
Корсак . . . . . 10
«Ошбу елда…» . . . . . 11
«Гаҗәпләнмим бер дә…» . . . . . 11
Кыш ява… . . . . . 12
«Иртәнге кар якты булып ятты…» . . . . . 13
«Алмагачтан яңа өзгән…» . . . . . 14
«Ялгыз калып: «Рәхмәт, Раббым», — дидем…» . . . . . 15
«Дөньясы аның — салкын мич…» . . . . . 16
«Кайдан кунган…» . . . . . 17
«Урыс яулап алган җирләр…» . . . . . 17
«Шәмемне еккан җилләрнең…» . . . . . 17
«Кара күздә күкрәп коя…» . . . . . 18
«Минем дә шул шигырь язганым бар…» . . . . . 19
«Күз һавасы шундый җиңел…» . . . . . 20
Юату . . . . . 20
Тор, күтәрел, Шигырем! . . . . . 21
Хәтерләр аша . . . . . 24
Иске самавырга . . . . . 26
Карлы мизгел . . . . . 28
Күзге-кичке кояш . . . . . 29
Сәйдәшкә . . . . . 30
Гасырларда яшәр Юксыну . . . . . 32
Салих Батталның китүе . . . . . 33
Китте ул Ак Болыт шикелле . . . . . 35
Мөслим шагыйрьләре . . . . . 36
Җанның сабан туе . . . . . 38
Былбылга мәрсия . . . . . 38
«Киткәнеңә инде ничә еллар…» . . . . . 39
Чорым — иркен! . . . . . 41
Шигъриятне яклап . . . . . 43
Илһамсыз чак . . . . . 44
Соңлап . . . . . 45
Гомер юлы . . . . . 46
«Карадым борылып елларга…» . . . . . 47

Урман аша . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 49
Сирень йолдызлангач . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 51
Төнге яңгыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 53
Килгән идем... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 54
Борынгы көйгә ике җыру . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 56
«Салкынча җил китте...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
«Күрше бакчада...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
«Кай илләрдән килә идең...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 57
Алмагач кызы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 58
Эше беткән... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 60
Ант . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
«Шушында гына кеше мин...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Татар иртәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
Тузга язган хатлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 63
Төнге поезд . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 65
Арбачы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
Сөннең ике яры . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 68
Унике кысыр каләм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
Казанга мәдхия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 72
Әманәт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 73
Азатлыкка кереш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
Чакыру! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
Без — бергә! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 80
Тайгак ватан . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
Ана өмете . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
«Кайсы стансадыр, белмим...» . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
Кузгалдык!.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
Тышаулы ат . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 87
Хәтер көне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
Мөсафир . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 90
«И туган ил...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 91
Дәрвиш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 92
Кинә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Татар дулкыны . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 93
Сиреньгә мәрсия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 94
Юаныч . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 95
Төсле төш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 96
Елан туе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 97
«Уйлана табигать...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 98
Чыгыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 99
Ак Байталым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 102
Песнәк . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 104
Ә Табигать яши... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 105
«Сөрелгән кыр буйлап...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 107

Күк вагоннарыдай еллар . . . 108
Түрә кулы . . . 109
Көзге җыр . . . 110
Тере Поэма . . . 111
Биектә . . . 112
Сонет . . . 113
Яу башы . . . 114
Авылыма . . . 115
Сихри моңнар . . . 116
Әманәт . . . 117
Үлемсез Чебен . . . 118
Кинә . . . 119
Шигърият . . . 119
Шагыйрьләр . . . 120
Суда үскән гөл . . . 120
Яшьлек парахуты . . . 121
Татар бугазы . . . 122
Нух көймәсе . . . 123
Бу кышта . . . 124
Өмет . . . 125
Инкыйраз . . . 125
Шәрык шагыйрьләренә тәкълид . . . 126

***Төрле еллар***

«— Бүләгем! — дип...» . . . 128
«Болытлар суда йөзә...» . . . 128
Кыз хаты . . . 129
«Ымладың да...» . . . 130
«Ерак җирләр...» . . . 130
Көзге диалог . . . 131
Шәһәр язы . . . 132
Фотограф белән сөйләшү . . . 135
Күктән репортаж . . . 138
Кышкы бакча . . . 140
Галәм хисапчысы . . . 141
«Алып чыктыңмы син...» . . . 142
«Әйтерсең мәңге бу җирдә...» . . . 143
«Тирәкләрдән җилдә бөтерелеп...» . . . 144
«Карамачы шулай күзләремә...» . . . 145
Мәхәббәтнең соңы . . . 146
«Бу төбәктә, бу төбәктә бары...» . . . 148
«Чал имәннәр яфрак коя...» . . . 149
«Кама өсләрендә күк күкрәде...» . . . 150

Гипербола . . . . . 151
«Син — бер океан!..» . . . . . 151
Исем кушу . . . . . 153
Тукайны озату . . . . . 154
Җил тегермәннәре . . . . . 156
Торналар оча . . . . . 159
«Ә», «Мә», «Бир» . . . . . 162
Йокласын агачлар... . . . . . 163
«Ни көтәсең, Җирем...» . . . . . 164
«Өрә җил, тулгана карлар...» . . . . . 165
«Ут-дәрьяда кайнап...» . . . . . 165
Кабан . . . . . 167
«Инде кич. Тирәкләр...» . . . . . 168
«Өстәлемдә ята ап-ак кәгазь...» . . . . . 168
Заман ахыры . . . . . 169
«Озата бара безне...» . . . . . 170
«Туган җиргә сүрән карамачы...» . . . . . 171
«Су кызыдай» . . . . . 172
Карлы тәрәзәләр . . . . . 173
«Авылым — Арышым...» . . . . . 174
Тупыллар җилгә каршы... . . . . . 176
Тургай җыры . . . . . 178
Иделдә җәй . . . . . 179
Диңгез ритмнары . . . . . 181
  Эчке аваз . . . . . 181
  «Таң сәгате...» . . . . . 183
  Хуш, диңгезем! . . . . . 184
  Кара диңгез . . . . . 185
  «Өлкән диңгез...» . . . . . 186
«Иртән, әле син йоклаган чакта...» . . . . . 187
Йоклама . . . . . 188
Туган йортта сентябрь . . . . . 189
Гомер тирәге . . . . . 190
«— Нигә уйчан? — диләр...» . . . . . 191
Урманчега — соңлаган багышлау . . . . . 192
Туфан уты . . . . . 193
«Айга карап өрә этләр...» . . . . . 194
Җәяүле күбәләк . . . . . 195
Яшел тупылга мәдхия . . . . . 196
Элегия . . . . . 197
«Минутларны ник саныйсың...» . . . . . 197
Кечкенә кешеләр йорты . . . . . 198
«Каеннарны үт тә...» . . . . . 199
Сиңа . . . . . 200

«Үткән төндә сине төштә күрдем...» . . . . . . . . . . . . . . . . 202
Чал платан төбендә . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 203
Иҗатка мәдхия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 204
Сәхнәдән китү . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 205
Киттем . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 206
Төп йорт . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 207
«Сиңа карыйм да...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 208
Югалган бер көн хакында . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 208
Күгәрчен очып туймас көн . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 209
«Сине нинди җилләрдән сакларга...» . . . . . . . . . . . . . . . 210
«Бу төбәктә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 211
Лирик әкият . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 212
«Яз башында күкрәп...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 213
Хушлашу көзе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 214
«Аерасың, бөек Вакыт...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 215
«Сез дә картаясыз, таллар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 215
Кешегә җылы сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 216
Күңел догасы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 217
«Саумысыз, картлар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 218
«Юк, берни дә аермаган безне...» . . . . . . . . . . . . . . . . 219
«Табигатьтә бар да шулай төгәл!..» . . . . . . . . . . . . . . . 220
Романс . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 221
«И, безнең беренче язлар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 222
Йокла, инешем! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 223
«Җәяүле бураннар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 224
«Мәхәббәтсез, утсыз...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 225
«Көзге кара төндә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 226
Узды бәйрәм . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 227
Даһилар чишмәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 228
«Һавалар кәнсәләрендә...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 229
«Яфрак шавы озата барды...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 230
«Юрый алмыйм синең киләчәкне...» . . . . . . . . . . . . . . 231
Аргы якка! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 232
Мәхәббәт үләне . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 234
Кайталмадым . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 235
Ерак киткән саен... . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 237
Кышкы сөйләшүләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 238
Дөньяга мәдхия . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 240
Табигатькә җыр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 241
Көзге элегияләр . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 243
«Нинди сагыш сары яланнарда...» . . . . . . . . . . . . . . . . 246
Мәхәббәт алиһәсе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 247
«Җыр — ул кешенең кан авазы . . . . . . . . . . . . . . . . . . 248

Җирән алашага . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 248
«Күрегезче, кошлар...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 250
Шигырьнең килүе . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 251
Бүре аулау . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 252
Кечке кошлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 254
Иртәнге төш . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 256
«Җете иде әле гөлнең таҗы...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 258
«Кечке кояш...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 259
«Чал иһрамнар баккан кыйблага...» . . . . . . . . . . . . . . . . 260
Контрастлар . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 261
«Ник, каләмем, сөйрәләсең...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 262
Тукай катламы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 263
Болдино — Кырлай . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 265
Кайтаваз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 267
Итил-су монологы . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 269
«Әйтерсең мин...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 271
Юлда . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 272
Чигенәбез . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 273
«Син дә килдеңме дөньяга...» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 275
Язгы кызый . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 276
«Менә кайда киңлек!..» . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 278
Сират . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 280
Нигә шигырь?.. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 281

Литературно-художественное издание

*Роберт Ахметзян*
*(Ахметзянов Роберт Валеевич)*

# *Утро*

## Стихи

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Рәссамы *Н.С.Петрова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *Н.Н.Мусина*
Корректоры *Г.М.Хабибуллина*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 05.07.2004. Форматы 70×108$^1/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Peterburg» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 12,60+фор.0,18. Шартлы буяу-оттиск 13,65.
Нәшер-хисап табагы 10,71+фор.0,29. Тиражы 2000. Заказ Э-351.

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул.Баумана, 19.

**http://tatkniga.ru**
**e-mail: tki@tatkniga.ru**

«Идел-Пресс» нәшрият-полиграфия комплексы дәүләт унитар предприятиесе.
420066. Казан, Декабристлар ур., 2.